3˚2018

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014 –2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Е.Ф. ЛУКЬЯНЧЕНКО

**БУ САНДА**

**ТЕЛ БЕЛЕМЕ**

*Сөләйманов Җ.Ш., Невзорова О.А., Гатиатуллин А.Р.* «TurkLang» халыкара конференциясе – төрки телләрне эшкәртүче компьютер технологияләрен үстерү даирәсе . . . . . . . . 7
*Кузьмина Х.Х.* Татар теле космонимнарын килеп чыгышы ягыннан төркемләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
*Мирхәев Р.Ф.* Татар халкының дини күзаллаулар системасында кеше образы һәм аның телдә чагылышы . . . . . . . . . . . . . . . . 28
*Булатова М.Р.* Стәрлебаш татарларының тел үзенчәлекләре . . . . 32

**ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ**

*Миңнуллин К.М.* Татар әдәбияты тарихының 8 томлыгын әзерләү тәҗрибәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
*Ханнанова Г.М.* Г. Тукайның башлангыч чор лирикасында матбугат темасы: төп мотивлар һәм жанр төрләре . . . . . . . . . . 46
*Галиева Л.Ш.* Гаяз Исхакый һәм Польша . . . . . . . . . . . . . . 54
*Харрасова Р.Ф.* Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында поэма жанры . . . . 61
*Рафикова Э.Д.* 1960–1980 еллар татар прозасы Ф. Миңнуллин бәяләвендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

**САДРИ МАКСУДИГА – 140**

*Сибгатуллина Ә.Т.* Садри Максудиның әдәби тәҗрибәсе – «Мәгыйшәт» романы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
*Гайнанова М.Р.* Телдә, фикердә, эштә Садри Максуди . . . . . . . . 87

**ХАЛЫК ИҖАТЫ**

*Ямалтдинов И.И.* 1920 елларда татар фольклористикасында проблемалар һәм тикшеренүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
*Хөббитдинова Н.Ә., Юлдыбаева Г.В., Мөхәммәтҗанова Л.Х., Салихов Ә.Г.* Мәдәниятләр кисешкән нокта: Курган өлкәсендә төрки цивилизация (фольклор экспедициясе һәм архив материаллары нигезендә) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

**ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ**

*Сәйфетдинова Э.Г.* Алтын Урда принцессасы Тулынбай эзләре буйлап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
*Зиннәтуллина А.Ә.* XX гасыр башында татар балалары арасында Мәүлид бәйрәме уздыру тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . 113

**МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Мортазина Л.Р.* Мөхәммәтзыя Бәхтияров – дәреслекләр һәм кулъязма китаплар авторы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
*Туктамышов Н.К.* Билингваль уку шартларында студентларда математика өлкәсенә караган сөйләм күнекмәләренең формалашуы . 129

## СӘНГАТЬ

*Шкляева Л.М.* Земфира Бикташеваның рухи моңы . . . . . . . . . 136
*Камалова З.А.* Татарстандагы төзү объектларында татар
милли стилен һәм колоритын торгызу һәм саклап калу . . . . . 140
*Герасимова Н.В.* 1920 елларда Татарстан музейларның сәнгать
коллекцияләре: максаты, формалашу процессы үзенчәлекләре
һәм ирешелгән нәтиҗәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Улемнова О.Л.* Л.Г. Фәттаховның китап графикасы
*(Рәссамның тууына 100 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . *155*

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Гыйрфанзадә.* Дустыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
*Ибраһимов Г.* Казанда татар мәдәнияте йорты ачарга кирәк . . . . 165

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Закирҗанов* Ә.М. Тукай турында яңа китап [Бәяләмә: Габдулла
Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар
(1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчества
Габдуллы Тукая (1886–1907)] . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
*Тимерханов А.Ә.* Гарәп теле – Коръән теле [Бәяләмә: Дини
текстларга гарәпчә-татарча сүзлек / төз. Ринат Сәфәр] . . . . . . 173

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Сулейманов Дж.Ш., Невзорова О.А., Гатиатуллин А.Р.* Международная конференция «TurkLang» – область разработки компьютерных лингвистических приложений для тюркских языков . 7

*Кузьмина Х.Х.* Классификация космонимов татарского языка по происхождению . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17

*Мирхаев Р.Ф.* Образ человека в религиозном мировоззрении татарского народа и его вербализация в языке . . . . . . . . . . . 28

*Булатова М.Р.* Особенности языка старлебашевских татар . . . . 32


### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Миннуллин К.М.* Опыт создания 8-томной истории татарской литературы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39

*Ханнанова Г.М.* Тема периодической печати в раннем творчестве Г. Тукая: основные мотивы и жанры . . . . . . . . . . . . . . . . . 46

*Галиева Л.Ш.* Гаяз Исхаки и Польша . . . . . . . . . . . . . . . . . 54

*Харрасова Р.Ф.* Жанр поэмы в творчестве Рашида Ахметзянова . . 61

*Рафикова Э.Д.* Татарская проза 1960–1980-х годов в оценке Ф. Миннуллина . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74


### САДРИ МАКСУДИ – 140


*Сибгатуллина Ә.Т.* Литературный опыт Садри Максуди – роман «Магишат» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80

*Гайнанова М.Р.* Место Садри Максуди в общественно-политической жизни народа . . . . . . . . . . . . 87


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Ямалтдинов И.И.* Проблемы и исследования в татарской фольклористике 1920-х годов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

*Хуббитдинова Н.А., Юлдыбаева Г.В., Мухаметзянова Л.Х., Салихов А.Г.* Место слияния культур: тюркская цивилизация в Курганской области (на основе экспедиционных и архивных материалов) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Сайфетдинова Э.Г.* По следам золотоордынской принцессы Тулунбай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109

*Зиннатуллина А.А.* Из истории проведения праздника Мавлюд среди татарских детей в начале XX века . . . . . . . . . . . . . 113


### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ


*Муртазина Л.Р.* Мухахамметзия Бахтияров – автор учебников и рукописных книг . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120

*Туктамышов Н.К.* Формирование речевых навыков в области математики у студентов в условиях билингвального образования . 129

**ИСКУССТВО**

*Шкляева Л.М.* Мелодия души Земфиры Бикташевой . . . . . . . 136

*Камалова З.А.* Возрождение и сохранение татарского национального стиля и колорита строительных объектов Татарстана. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

*Герасимова Н.В.* Художественные коллекции в музеях Татарстана в 1920-е годы: цели создания, особенности формирования и достижения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Улемнова О.Л.* Книжная графика Л.Г. Фаттахова *(К 100-летию со дня рождения художника)* . . . . . . . . . . . . 155

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

*Гирфанзаде.* Другу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

*Ибрагимов Г.* Казанда татар мәдәнияте йорты ачарга кирәк . . . . 165

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Закирзянов* А.М. Новая книга о Тукае [Рец. на: Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886–1907)] . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

*Тимерханов А.А.* Арабский язык – язык Корана [Рец. на: Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек / төз. Ринат Сәфәр] . . . . . . . 173

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 81’33

***Җ.Ш. Сөләйманов,***
***О.А. Невзорова,***
***А.Р. Гатиатуллин***

# «TURKLANG» ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ – ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕ ЭШКӘРТҮЧЕ КОМПЬЮТЕР ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН ҮСТЕРҮ ДАИРӘСЕ

Целью международной конференций «TurkLang» является создание пространства совместных компьютерных лингвистических исследований для тюркских языков. На конференции представляются новые результаты, связанные с разработкой компьютерных лингвистических приложений для тюркских языков. Международная конференция «TurkLang» проводится ежегодно с 2013 года (Астана (2013), Стамбул (2014 г.), Казань (2015, 2017), Бишкек (2016)).

**Ключевые слова:** международная конференция, тюркские языки, компьютерная лингвистика, лингвистические модели, лингвистические программы

## Актуальлек

Соңгы вакытта төрки телләрне компьютерда эшкәртү мәсьәләләренә багышланган фәнни-гамәли эшләрнең саны елдан-ел арта бара. Әлеге чаралар кысаларында төрки телләрнең мәгълүмати технологияләр өлкәсендә кулланылуын тәэмин итә торган системалар һәм программалар эшләү дә күз уңында тотыла [Bilkiz; Gulila Adongbieke, Mijit Ablimit; Ilgen, Adali, Tantuğ; Makazhanov, Sultangazina, Makhambetov, Yessenbayev; Nart B. Atalay, Kemal Oflazer and Bilge Say; Oflazer; Oorzhak, Khertek; Orhun, Tantuğ, Adalı; Sharipbayev, Razakhova; Zheltov; Сулейманов, 1996; Сулейманов, 1993; Сулейманов 1994]. Биредә төп игътибар морфологик анализ программаларын төзүгә һәм текстларга морфологик аннотация ясауга бирелә [Orhun, Tantuğ; Sharipbay, Bekmanova, Yergesh, Mukanova; Дыбо, Шеймович; Желтов; Сиразитдинов]. Бу – төрки телләрнең структур үзенчәлекләре һәм төрки телләрдәге текстларны эшкәртүдә морфологиянең зур роль уйнавы белән аңлатыла. Бастырылган мәкаләләр һәм төзелгән программалар санын анализлап карасаң, бу өлкәдә иң актив эшләүчеләр исемлегенә төрек, уйгур, казакъ һәм татар галимнәренең кергәнлеге күренә [Akba, Uçan, Sezer, Sever; Batuer Aisha and Maosong Sun; Çetin, Amasyali; Gulila Altenbek; Iknur Durgar El-Kahlout and Kemal Oazer; Kaya, Fidan, Toroslu; Razieh Ehsani, Muzaffer Ege Alper, Glsen Eryigit and Esref Adali; Tukeyev; Yıldırım, Tantuğ].

Шул ук вакытта, төрки телләрне саклау, өйрәнү, эшкәртү һәм үстерү өчен программалар төзүдә һәм лингвистик ресурслар туплау өлкәсендә кайбер тискәре тенденцияләр дә күзәтелә.

Алар, беренчедән, фәнни-тикшеренү эшләренең аерым-

аерым башкарылуында һәм белгечләр арасында мәгълүмат һәм технологияләр белән уртаклашу, бердәмлек булмауда чагылыш таба. Бу, аеруча, яңа терминнар ясаганда һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә яңа концептлар тудырганда мөһим. Хәзерге вакытта компьютер технологияләрендә милли терминнар, нигездә, инглиз теленнән кабул итеп алына. Яңа төшенчәләр төрле ысуллар белән үзләштерелә: термин чит телдән үзгәрешсез алына (computer – компьютер); тәрҗемә ителә (mouse – тычкан), тел кагыйдәләренә фонетик яктан яраштырыла (cash – кәш) яки, сирәк очракта, кулланылышка яңа термин (keyboard – төймәтакта, төймәсар), яисә неологизм (data base – база данных – тамгасар) кертелә.

Компьютер технологияләре белән бәйле күп кенә бер үк яңа терминнарның төрки телләргә төрле сүзләр белән кереп китүен, бу өлкәнең бик тиз үсеп-үзгәреп торуын һәм төрки телләрнең охшашлыгын истә тотканда, компьютер терминнарының уртак сүзлеген туплау бүгенге көндә дә актуаль мәсьәлә булып кала бирә. Бу сүзлек, һичшиксез, төрки телләрдә мәгълүмат туплау, аны уртак кулланылышка кертү юнәлешендә уңайлыклар тудырачак, эшнең нәтиҗәлелеген арттырачак, мәгълүмат эшкәртү программаларын унификацияләштерүгә китерәчәк.

Икенчедән, төрки телләрне эшкәртүче лингвистик модельләр һәм программалар бер-берсен кабатлыйлар, алар 70–80 процентка барлык төрки телләр өчен дә уртак булган өлешләрдән тора. Әлеге кабатлаулардан котылу, уртак проектларда катнашу һәм программалар белән уртаклашу финанс чыгымнарын һәм сарыф ителгән көчне экономияләргә ярдәм итәчәк. Ә бу исә, белгечләрнең тырышлыгын бүгенге көндә чишелмәгән уртак проблемаларны хәл итүгә юнәлтергә мөмкинлек бирәчәк. Мондый эшчәнлек, үз чиратында, төрки телләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләренә нигезләнгән яңа технологияләр тудырырга ярдәм итәчәк [Suleymanov, p. 210–213].

Хәзерге этапта төрки телләр даирәсендәге нәзари һәм гамәли тикшеренүләрнең төп юнәлешләре билгеләнде һәм белгечләрнең берләшүе, төрки телләрне эшкәртүдә уртак принциплар һәм ысуллар булдыру зарурлыгы ассызыкланды. Уртак проектлар киләчәктә бу өлкәгә караган эзләнүләрнең нәтиҗәлелеген дә арттырачак, текстларны эшкәртүче күптелле системалар төзергә һәм башка фундаменталь һәм гамәли мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итәчәк.

## Үткәрү тарихы

Төрки телләрне компьютер технологияләре ярдәмендә эшкәртү мәсьәләләренә багышланган «TurkLang» халыкара конференциясе 2013 елда – Астанада (Казакъстан) [Труды Первой...], 2014 елда – Истанбулда (Төркия) [Proceedings of the International.., 2014], 2015, 2017 елларда – Казанда (Татарстан, Россия Федерациясе) [Proceedings of the International.., 2015; Пятая Международная...], 2016 елда

Бишкәктә (Кыргызстан) [Материалы 4-ой Международной...] үткәрелде. Ул баштан ук белгечләрнең уртак стандартлар төзү өчен тырышлыкларын берләштерүнең, төрки телләрне өйрәнү белән бәйле мәгълүмати һәм технологик ресурсларны уртак бер мәйданга туплауның эффектив механизмы буларак күзалланды.

Эш барышында пленар утырышлар, түгәрәк өстәлләр, программалар белән танышу каралган иде. Конференция кысаларында төрки телләрнең формаль модельләре, компьютер системаларын төрки телләргә яраштыру һәм терминология, электрон корпуслар төзү, текстларны эшкәртү өчен морфологик һәм синтаксик технологияләр, сөйләмне анализлау һәм синтезлау системалары, текстларны эшкәртү өчен семантик системалар, автоматлашкан тәрҗемә системалары, төрки телләргә өйрәтүче интеллектуаль системалар һәм технологияләр, төрки телләрнең лингвистик онтологияләре белән бәйле мәсьәләләр тикшерелде.

Узган конференцияләрнең эшчәнлегендә дөньяның төрле илләреннән түбәндәге фәнни үзәкләрнең вәкилләре катнашты: Татарстан Фәннәр академиясе (Казан, Татарстан), Казан федераль университеты, М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты (Мәскәү), Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты (Мәскәү), Югары икътисад мәктәбе (Мәскәү), Россия Фәннәр академиясенең Информатика проблемалары институты (Мәскәү), Санкт-Петербург дәүләт университеты (Санкт-Петербург), Новосибирск дәүләт университеты (Новосибирск), Россия Фәннәр академиясенең Уфа фәнни үзәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (Уфа, Башкортстан), М.К. Аммосов исемендәге Төньяк-көнчыгыш федераль университет (Якутск, Саха), И.Н. Ульянов исемендәге Чуваш дәүләт университеты (Чебоксар, Чувашия), Тыва дәүләт университеты (Кызыл, Тыва), В.И. Вернадский исемендәге Кырым федераль университеты (Симферополь, Кырым), Синьцзянь университеты (Ырымчы, Кытай), Цинхуа Университеты (Бейджин, Кытай), Баку Евразия университеты (Баку, Азәрбайҗан), Оксбридж академиясе (Баку, Азәрбайҗан), Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты (Астана, Казакъстан), Назарбаев Университеты (Астана, Казакъстан), әл-Фараби исемендәге Казакъ милли университеты (Алматы, Казакъстан), И. Раззаков исемендәге Кыргыз техник университеты (Бишкәк, Кыргызстан), Кыргызстан милли фәннәр академиясенең Нәзари һәм гамәли математика институты (Бишкәк, Кыргызстан), Н. Исанов исемендәге архитектура, транспорт һәм төзелеш кыргыз дәүләт университеты (Бишкәк, Кыргызстан), Карасаев исемендәге Бишкәк дәүләт университеты (Бишкәк, Кыргызстан), Ош технология университеты (Ош, Кыргызстан), Бөек Витаутас университеты (Каунас, Литва), Истанбул техник университеты (Истанбул, Төркия), Алишер Нәвои исемендәге Үзбәк

теле һәм әдәбияты университеты (Ташкент, Үзбәкстан), Аризона университеты (Тусон, Аризона, АКШ), Суортмор колледжы (Суортмор, Пенсильвания, АКШ).

2018 елда конференцияне Үзбәкстан Республикасының Ташкент шәһәрендә, Алишер Нәвои исемендәге үзбәк теле һәм әдәбияты университетында үткәрү планлаштырыла.

## «UniTurk» семинары

Конференция кысаларында ел саен «UniTurk» семинары оештырыла. Анда төрки телләрдәге текстларга унификацияләнгән морфологик аннотацияләр төзү проблемалары тикшерелә. Анализ күрсәткәнчә, төрки телләр үзләренең структурасы һәм тарихи килеп чыгышы ягыннан нык охшаш булсалар да, аларны аннотацияләүнең уртак принциплары һәм ысуллары юк. Киләчәктә бу хәл телләрне чагыштырып өйрәнү юнәлешендә эзләнүләр үткәргәндә, төрки телләрнең параллель корпусларын төзегәндә яки күп телле эшкәртү системалары төзегәндә шактый гына кыенлыкларга китерергә мөмкин.

Әлеге өлкәдә эшләүче белгечләрнең күбесе аннотацияләү өчен уртак теглар системасының кирәклеген аңлауга карамастан, төрки телләрнең корпусларында лингвистик мәгълүматны билгеләү өчен уртак унификацияләнгән формат һаман да эшләнмәгән. Бер үк морфологик категорияләрне төрки галимнәр төрлечә билгели. Төрки телләрнең корпусларын төзүчеләр, нигездә, башка типтагы телләр өчен төзелгән теглар системасын кулланалар. Беренче чиратта, ул һинд-европа телләре системалары, ә алар күп очракта төрки телләрнең үзенчәлекләрен дөрес күрсәтмиләр. Шуңа күрә бүгенге көндә төрки телләр өчен махсус аннотацияләү системасын төзү аеруча актуаль.

Корпусларны аннотацияләү өчен уртак система булмауның сәбәпләре, бер яктан, объектив фәнни эчтәлекле проблемаларга бәйле булса (тел системасының катлаулылыгы, төрле телләрнең грамматик структураларындагы үзенчәлекләр, морфонологик процессларның аермалылыгы), икенче яктан, оештыру мәсьәләләренә кайтып кала (координацияләүче бер үзәкнең булмавы; корпусларда грамматик һәм семантик аннотацияләр төзүнең стандартлары һәм уртак лингвистик мәгълүмат базаларының юклыгы).

Төрки телләр корпусларының грамматик аннотацияләү системаларын унификацияләүгә багышланган «UniTurk» фәнни-гамәли семинарында катнашучылар, төрки тел белемендә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе итеп, лингвистик мәгълүматны билгеләү өчен шундый стандартлар тудыруны атыйлар. Әлеге стандартлар элекке һәм яңадан төзелүче электрон корпусларны кулланучылар өчен бердәм мәгълүмати даирә итеп коруның ышанычлы нигезе булыр иде.

## Фәнни нәтиҗәләр: уртак грантлар, хезмәттәшлек турындагы килешүләр, яңа катнашучылар

«TurkLang» конференциясе башка төр хезмәттәшлекне үстерүгә дә ярдәм итә. Мәсәлән,

Татарстан Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институты хезмәткәрләре, Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университетының Шәкли фәһем институты, Истанбул техник университетының компьютер инженериясе һәм информатика факультеты, И. Раззаков исемендәге Кыргыз техник университеты хезмәткәрләре һәм Алишер Нәвои исемендәге Үзбәк теле һәм әдәбияты университеты хезмәткәрләре белән берлектә, «Күптелле эзләү системалары өчен төрки телләрнең электрон тезаурусларын төзү» исемле уртак халыкара проектта катнашалар.

Татарстан Фәннәр академиясе соңгы ике ел эчендә И. Раззаков исемендәге Кыргыз дәүләт техник университеты һәм Алишер Нәвои исемендәге Үзбәк теле һәм әдәбияты университеты белән төрки телләрне компьютерлаштыру өлкәсендә инструменталь һәм лингвистик ярдәм күрсәтү буенча хезмәттәшлек турында килешүләр төзеде. Әлеге эшчәнлек кысаларында бердәм мәгълүмати даирә төзү мәсьәләләрен хәл итү дә каралган. Килешүләрне төзүгә конференциядә төрки телләрне компьютерда эшкәртүнең яңа модельләрен һәм технологияләрен күрсәтү этәрде.

Моннан тыш, хәзерге вакытта бердәм мәгълүмати даирә төзү максаты белән бер төркем махсус программалар эшләнә. Алар галимнәргә әлеге өлкәдә уртак эшләр башкару мөмкинлеген тудырачак. Шундый программаларның берсе – Татарстан Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институтында эшләнә торган күпфункцияле һәм күптелле интернет-сервис (1 нче рәс.). Төрки морфема моделе нигезендә төзелгән әлеге интернет-сервис, бер яктан, төрки телләрне компьютерда эшкәртү мөмкинлекләрен биргән программалар каталогын, ә икенче яктан, шул программалар белән эшләү мөмкинлекләрен тудырган веб-сайтны тәшкил итә.

### Оештыру мәсьәләләре

Конференцияне оештыручы төп оешмалар – Татарстан Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты, Истанбул техник университеты, Россиянең Шәкли фәһем




1 нче рәс. Күпфункцияле һәм күптелле интернет-сервисның интерфейс бите

ассоциациясе. Конференциягә кагылышлы актуаль мәгълүмат махсус www.turklang.tatar сайтында даими чагылдырыла (2 нче рәс.). Сайтта конференция кысаларында 5 ел эчендә тупланган барлык мәкаләләр җыентыклары да урнаштырылган.

Сайтта, конференциянең үзе турындагы мәгълүматтан тыш, төрки телләр өчен ясалган компьютер программалары һәм электрон ресурслар турында да мәгълүмат бирелгән (3 нче рәс.).

Конференциянең сайты күптелле итеп эшләнде. Анда инглиз,




2 нче рәс. Конференция сайты




3 нче рәс. Төрки телләрнең электрон корпуслары турындагы сайт бите

татар, казакъ, кыргыз, төрек, үзбәк, саха һәм рус телләрендәге битләр бар. Интерфейс телләре саны һәм сайтта урнаштырылган ресурслар саны даими рәвештә артып барачак.

5 ел эчендә конференциягә бирелгән мәкаләләр һәм авторлар санына анализ ясалды (1 нче таблица). Бу анализ катнашучыларның һәм мәкаләләрдә күрсәтелгән төрки телләр санының әкренләп артуын күрсәтә. Иң күп мәкаләләр саны Казанда үткән конференцияләрдә булган (2015 елда – 49, 2017 елда – 46).

## Нәтиҗә

Оештыручылар һәм катнашучылар «TurkLang» конференциясен төрки телләрне эшкәртү, өйрәнү, үстерү өчен уртак лингвистик ресурслар, системалар һәм технологияләр төзү, уртак лингвистик эзләнүләр башкару даирәсе итеп күрәләр һәм шул юнәлештә эшләүне дәвам итәләр. Конференция сайтын төрки телләрдәге ресурсларны һәм төрки телләрне эшкәртүче программаларны урнаштыру өчен ачык платформага әйләндерү актуаль мәсьәлә булып санала (анда мәгълүмат базалары, терминологик һәм аңлатмалы сүзлекләр, тезауруслар урнаштыру каралган) һәм анда, беренче чиратта, морфологик һәм синтаксик анализаторлар, автоматлашкан тәрҗемә һәм Интернетта мәгълүмат эзләү системалары тупланырга тиеш.

1 нче таблица

| | 2013 | | 2014 | | 2015 | | 2016 | | 2017 | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Телләр | Авт. | Док. | Авт. | Док. | Авт. | Док. | Авт. | Док. | Авт. | Док. |
| Азәрбайҗан | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 1 | 0 | 0 | 2 | 2 |
| Башкорт | 2 | 1 | 1 | 1 | 5 | 2 | 0 | 0 | 4 | 1 |
| Казакъ | 60 | 34 | 18 | 7 | 22 | 12 | 27 | 8 | 26 | 11 |
| Каракалпак | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Кыргыз | 5 | 3 | 0 | 0 | 3 | 1 | 6 | 5 | 9 | 6 |
| Кырым татар | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Татар | 14 | 8 | 11 | 6 | 24 | 11 | 3 | 2 | 14 | 11 |
| Тыва | 0 | 0 | 0 | 0 | 4 | 2 | 0 | 0 | 7 | 2 |
| Төрек | 1 | 1 | 17 | 8 | 8 | 2 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Үзбәк | 9 | 6 | 0 | 0 | 1 | 1 | 1 | 1 | 3 | 4 |
| Уйгур | 0 | 0 | 0 | 0 | 7 | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Хакас | 0 | 0 | 0 | 0 | 3 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Чуваш | 0 | 0 | 0 | 0 | 9 | 5 | 0 | 0 | 6 | 5 |
| Саха (якут) | 0 | 0 | 0 | 0 | 5 | 4 | 0 | 0 | 3 | 2 |
| Гомумтөрки | 0 | 0 | 0 | 0 | 3 | 3 | 2 | 1 | 2 | 2 |
| Барлыгы | 91 | 53 | 47 | 22 | 87 | 49 | 38 | 18 | 77 | 46 |
| Телләр саны | 5 | | 4 | | 15 | | 6 | | 11 | |

**Әдәбият**

*Akba F., Uçan A., Sezer E., Sever H.* Assessment of Feature Selection Metrics for Sentiment Analysis: Turkish Movie Reviews // In 8th European Conference Data Mining. 2014. P. 180–184.

*Batuer Aisha and Maosong Sun.* A Uyghur Morpheme Analysis Method based on Conditional Random Fields, International Journal of Asian Language Processing, 2009, 19(2). P. 69–83.

*Bilkiz.* Uyghur Corpus experimental study of part of speech tagging, Xinjiang fifth Annual Youth Symposium, Xinjiang People's Publishing House in October (in Chinese), 2004.

*Çetin M., Amasyali M.F.* Active Learning for Turkish Sentiment Analysis // In Innovations in Intelligent Systems and Applications (INISTA), IEEE International Symposium, 2013.

*Gulila Adongbieke, Mijit Ablimit.* Research on Uyghur word segmentation, Journal of Chinese information processing, 18(6): 61–65 (in Chinese), 2004.

*Gulila Altenbek.* Automatic Morphological Tagging of Contemporary Uighur Corpus. The IEEE International Conference on Information Reuse and Integration, 2006. P. 557–560.

*Iknur Durgar El-Kahlout and Kemal Oazer.* Initial explorations in English to Turkish statistical machine translation. In Fifth International Conference on Information Technology, Las Vegas, NV, 2008.

*Ilgen B., Adali E., Tantuğ A.C.* A Comparative Study to Determine the Effective Window Size of Turkish Word Sense Disambiguation Systems, 28th International Symposium on Computer and Information Sciences, Paris, France, 2013.

*Kaya M., Fidan G., Toroslu I.* Sentiment Analysis of Turkish Political News // In Web Intelligence and Intelligent Agent Technology (WI-IAT), IEEE/WIC/ACM International Conferences, V. 1. 2012. P. 174–180.

*Makazhanov A., Sultangazina A., Makhambetov O., Yessenbayev Zh.* Syntactic annotation of Kazakh: following the universal dependencies guidelines. A report // Proceedings of the International Conference «Turkic Languages Processing: TurkLang-2015». Kazan: Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan Press, 2015. P. 338–350.

*Nart B. Atalay, Kemal Oflazer and Bilge Say.* The Annotation Process in the Turkish Treebank. In Proceedings of the EACL Workshop on Linguistically Interpreted Corpora. Budapest, 2003.

*Oflazer K.* Two-level Description of Turkish Morphology. Literary and Linguistic Computing. Vol. 9. No 2. 1994.

*Oorzhak B., Khertek A.* Development of semantic mark-up for the corpus of Tuvan language // Proceedings of the International Conference «Turkic Languages Processing: TurkLang-2015». Kazan: Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan Press, 2015. P. 351–362.

*Orhun M., Tantuğ A.C., Adalı E.* Morphological Disambiguation Rules For Uyghur Language // IEEE International Conference on Software Engineering and Service Sciences (ICSESS), Beijing, China, 2010.

Proceedings of the International Conference «Turkic Languages Processing: TurkLang-2015». Kazan: Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan Press, 2015. 488 p.

Proceedings of the International Conference on Turkic Language Processing (TURKLANG-2014). (Istanbul, November 6–7, 2014). Istanbul: Özkaracan Matbaacılık-Bağcılarr, 2014. 135 p.

*Razieh Ehsani, Muza_er Ege Alper, Glsen Eryigit, and Esref Adali.* Disambiguating main POS tags for Turkish // In Proceedings of ROCLING – Conference on Computational Linguistics and Speech Processing. Association for Computational Linguistics and Chinese Language Processing (ACLCLP), Taiwan, 2012.

*Sharipbay A.A., Bekmanova G., Yergesh B., Mukanova A.* Synchronized liner tree for morphological analysis and generation of the Kazakh language. Proceedings of the international conference «Turkic languages processing», TurkLang 2014, Istanbul, P. 113–117.

*Sharipbayev A.A., Razakhova B.Sh.* Mathematical models of syntactical rules of Kazakh language subject to semantics of parts of the sentence // The 4th Congress of the Turkic World Mathematical Society. Baku, 2011. P. 463.

*Suleymanov D.Sh.* Natural Cognitive Mechanisms in the Tatar language // In the Collection of the Vienna Proceedings of the Twentieth European Meeting in Cybernetics and Systems Research. Edited by Robert Trappel. Vienna, Austria, 6–9 April, 2010. P. 210–213.

*Tukeyev U.* Automaton models of the morphology analysis and the completeness of the endings of the Kazakh language // Proceedings of the International Conference «Turkic Languages Processing: TurkLang-2015». Kazan: Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan Press, 2015. P. 91–100p.

*Yıldırım E., Tantuğ A.C.* The feasibility analysis of re-ranking for N-best lists on English-Turkish machine translation, IEEE International Symposium on Innovations in Intelligent Systems and Applications, Albena, Bulgaria, 2013.

*Zheltov P.* Morphological annotation system for the national corpus of the Chuvash language // Proceedings of the International Conference «Turkic Languages Processing: TurkLang-2015». Kazan: Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan Press, 2015. P. 328–330.

*Дыбо А.В., Шеймович А.В.* Автоматический морфологический анализ для корпусов тюркских языков // Филология и культура. 2014. № 2.

*Желтов П.В.* Морфологический анализатор чувашского языка. Материалы Международной конференции студентов и аспирантов по фундаментальным наукам «Ломоносов 2002», М., 2002.

Материалы 4-ой Международной конференции по компьютерной обработке тюркских языков «TurkLang 2016» // Известия кыргызского государственного технического университета им. И.Раззакова, 2016 №2(38), С. 9–130.

*Сиразитдинов З.А.* Алгоритмическая грамматика словоизменения башкирского языка // [Электронный ресурс]. URL: http://mfbl.ru/bashdb/algram/ algram.htm (дата обращения: 19.03.2018).

*Сулейманов Д.Ш.* К описанию татарских падежей через структурно-функциональную модель морфем (статья на англ. яз.) // Proceedings of the LP'96 Conference on Languages Typology (Prague, 22-24 August, 1996). Prague, 1996. P. 388–395.

*Сулейманов Д.Ш.* К разработке эффективной морфологии среднетюркского языка // Сб. трудов межд. конф. Проблемы создания среднетюркского языка Ортатюрк. Ташкент, 1993. С. 85–86.

*Сулейманов Д.Ш.* Регулярность морфологии татарского языка и типы нарушений в языке Серия: Интеллект. Язык. Компьютер. Вып. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1994. С. 77–106.

Труды Первой международной конференции «Компьютерная обработка тюркских языков». Астана: ЕНУ им. Л.Н. Гумилева, 2013. 345с.

Пятая Международная конференция по компьютерной обработке тюркских языков «TurkLang 2017»: Труды конференции: в 2-х томах.– Казань: Издательство Академии наук Республики Татарстан, 2017. Т. 1. 300 с.: Т. 2. 327 с.

***Сөләйманов Җәүдәт Шәукәт улы,***
*техник фәннәр докторы, профессор,*
*Татарстан Фәннәр академиясе академигы*

***Невзорова Ольга Авенировна,***
*техник фәннәр кандидаты, Казан (Идел буе) университетының*
*Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр*
*институты доценты*

***Гатиатуллин Айрат Рафиз улы,***
*техник фәннәр кандидаты, Казан (Идел буе) университетының*
*Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр*
*институты укытучысы*

УДК 811.512.157

***Х.Х. Кузьмина***

# ТАТАР ТЕЛЕ КОСМОНИМНАРЫН КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ЯГЫННАН ТӨРКЕМЛӘҮ

В статье рассматриваются вопросы генетической классификации космонимов татарского языка. Самую малочисленную группу представляют исконно тюрко-татарские космонимы. Вторая группа состоит из космонимов, заимствованных из арабского языка. Третью группу составляют заимствованные из русского языка космонимы латинского происхождения. Лексемы первой группы в основном функционируют в разговорной речи татар, в то время как арабские и латинские названия небесных тел употребляются в научном стиле татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** космонимы, заимствования, татарский язык, ономастика, лексика.

Космонимнарны төркемләү мәсьәләсе тел белемендә бүгенге көнгә кадәр җитәрлек күләмдә эшләнмәгән. Аерым хезмәтләрдә генә бу мәсьәлә яктыртыла һәм, нигездә, сүзлек байлыгын төркемләүдәге тематик классификация файдаланыла. Мәсәлән, К.Г. Ароновның казакъ теле космонимнарын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендә әлеге принципка таянып, җиде төркем аерыла: 1) аерым йолдызларга караган космонимнар; 2) йолдызлыкларга караган космонимнар; 3) йолдыз төркемнәренә караган космонимнар; 4) зодиак йолдызлыкларына караган космонимнар; 5) кояш системасы күк җисемнәренә караган космонимнар; 6) комета һәм метеорларга караган космонимнар; 7) космос һәм галактикага караган космонимнар [Аронов, 1992, с. 7]. Бүленештән күренгәнчә, телдәге космонимик рәт тулы булган очракта, бу классификация универсаль, әмма барлык телләргә дә бер дәрәҗәдә туры килеп бетми, чөнки кайбер төркем космонимнарның атамасы телдә бөтенләй булмаска да мөмкин.

Рус теле белеме һәм ономастика өлкәсендә эзләнүләр алып барган галим Г.Ю. Сызранова космик онимнарны космоним һәм астроним дигән ике төркемгә бүлеп өйрәнергә тәкъдим итә [Сызранова, 2013, с. 171]. Астронимнар – күк йөзендәге аерым планета һәм йолдыз атамалары, калган барлык галәм җисемнәре космоним буларак төркемләнә. Мондый бүленеш шулай ук космонимнарны төрле аспектларда өйрәнүне чикли.

М.Э. Рут (1987), В.А. Никонов (1973), Ю.Г. Карпенко (1981) һ.б.ның хезмәтләрендә космонимнарны төркемләүнең лексик-семантик модельләре яки номинацияләү принциплары буенча төркемләү чагылса да, тулы классификация очрамый.

Космонимнар арасында бик борынгы һәм чагыштырмача яңа

атамаларны аерып карарга мөмкин. Борынгы атамалар, нигездә, телескоп барлыкка килгәнчегә кадәр булган чордагы, ягъни кешенең табигый күз күреме җитәрлек дәрәҗәдә ачык күргән күк җисемнәрен атыйлар. Аларны икенче төрле «халык космонимнары» дип тә йөртәләр. Кешеләр мондый космонимнарга охшату-чагыштыру нигезендә ясалган метафоралар ярдәмендә исем биргәннәр (*Әвернә йолдызлыгы, Чүмеч йолдыз, Акбүзат* һ.б.). Аларның кайберләре, астрономия фәне тарафыннан теркәлеп, фәнни кулланылышка кереп киткән. Яңа барлыкка килгән лексик атамалар арасында күбрәк ай яки планета өслеге белән бәйле атамалар урын ала, йолдыз яки йолдызлык, галактика атамаларын хәзерге астрономия фәнендә хәрефләр һәм идентификацияләү номеры белән күрсәтү гадәткә кергән.

Татар телендә кулланылган астрономик терминнар *килеп чыгышы ягыннан* өч зур төркемгә бүлеп каралырга мөмкин: 1. Төрки-татар чыгышлы космонимнар; 2. Гарәп теленнән кергән алынма космонимнар; 3. Рус теле аша һинд-европа (грек, латин) телләреннән кергән алынма космонимнар.

***1. Төрки-татар чыгышлы космонимнар.***

Алда әйтелгәнчә, күк җисемнәрен, аларның торышын өйрәнү борынгы кешегә суда һәм коры җирдә юнәлеш табарга мөмкинлек биргән. Борынгы космонимнарның эзе гасырлар тирәнлегенә төшеп югала, аларның кайсы гасырда барлыкка килгәнен әйтү шактый кыен. Күп кенә атамаларның башка телләрдән тәрҗемә итеп алынуы да мәгълүм, шуңа күрә, еш кына, космонимнарның генетик чыганагын билгеләгәндә, без бары тик лингвистик аспектны күздә тотабыз, этник-мифологик аңлатмалар бу очракта үз-үзләрен акламый.

Хәзерге татар телендә саф төрки чыгышлы космонимнар сан ягыннан күп түгел. Бу – татарларның шактый күптәннән утрак тормышка күчү сәбәпле, күк җисемнәренең борынгы атамалары телдән югалуы белән аңлатыла булса кирәк. Утрак тормышка соңрак күчкән башка төрки халыкларда (мәсәлән, казакъ, башкортларда) космонимик атамалар шактый яхшы сакланган: «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Лексика» хезмәтендә дә космонимик атамаларның күбесе казакъ теле мисалында бирелгән [Сравнительно..., 2001, с. 50–67]. «Татар теленең зур диалектолик сүзлеге»ндә дә (2006) күк җисеме атамалары сирәк очрый, шулай да без аларны К. Насыйри, Н. Исәнбәт кебек галимнәрнең хезмәтләрендә, алар тарафыннан туплап калдырылган халык авыз иҗаты әсәрләрендә очратабыз.

Төрки космонимнарны өйрәнгән вакытта планета, иярчен яки йолдыз тибындагы аерым җисемне белдермәгән, әмма галәм турында нигез күзаллаулар барлыкка китергән атамаларны да өйрәнү зарур.

Алар арасында *күк/*kök* атамасы игътибарны үзенә җәлеп итә. Шунысын әйтергә кирәк:

хәзерге төрки телләрдә күк *(небо)* төшенчәсен белдергән сигез лексема кулланыла: 1. Көнчыгыш ареалда (алт., тув., хак., шор., уйг. телләрендә) *teŋir* сүзе; 2. Кыпчак-угыз-карлук (тат., башк., каз., ккалп., кырг., ком., ног., азәрб., төрек, төркм., үзб., уйг. телләре) ареалын барлыкка китергән *kök* сүзе; 3. Борынгы төрки язмалардагы *qalyq;* 4. *Ewren* сүзләре; 5. Якут телендәге *xallān* сүзе; 6. Чуваш телендәге *tüpe* (< töbe) сүзе; 7. Тат., каз., ккалп., кырг., төркм., үзб., уйг. иске әдәби телләрендәге *asman/aspan* сүзе; 8. Гарәп теленнән алынган *säma* сүзе [Сравнительно..., 2006, с. 329]. Татар телендә әлеге атамалардан *kök* сүзе «күк йөзе *(небо)»* мәгънәсендә, *täŋre* сүзе «күк *(небо)*» мәгънәсен югалтып, Аллаһ мәгънәсендә кулланыла [Мирхаев, Гумеров, 2017, с. 48–50]; иске татар әдәби телендә һәм диалектларда *asman* сүзе «күк йөзе (небо)» мәгънәсендә сакланган.

*Kök* сүзенең беренчел этимологиясе ачыкланмаган дип карала, әмма бу атаманы һинд-европа телләре белән чагыштырма рәвештә өйрәнү кызыклы нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: төрки телләрдә дә, һинд-европа телләрендәге *sky* (күк) сүзе кебек үк, әлеге тамыр «каплау, ябу, тышчалык» мәгънәсен биргән сүзләрдә очрый. Мәсәлән, *kö-n «тире, күн»* гәүдәне каплап алган тышчалык; *kö-m «күму, каплап кую»; kö-läm «күләм»; kö-bik «күбек»; kö-läŋge «күләгә»* һ.б. Төрки телләрдә шул ук борынгы тамыр *кояш* мәгънәсендә килгән *kön* (*kö-n*) сүзендә дә күзәтелә [Древнетюркский..., 1969, с. 326].

Борынгы төрки синкретизм (бер үк тамырда исем, фигыль, сыйфат мәгънәләре берегү) күренешенә бәйле рәвештә, *kök* атамасында төс белдерү үзенчәлеге дә сакланган. Татар телендә әлеге тамырда зәңгәрсу һәм соры төсләрне белдерү очрый. *Күгелҗем, күксел, күксу, күгәрек* сүзләрендә әлеге төсләр чагылыш тапкан.

Татар поэзиясе телендә *күк* сүзе, күплек санда килеп, Аллаһ, югары көч мәгънәсендә дә кулланыла ала: *Күкләрдән иңгән язмыш* (Р. Юсупова); *Мин күкләрдән сине сорап алдым* (җыр). Әлеге мәгънәдә ул халык авыз иҗатында, борынгы мәкаль-әйтемнәрдә сакланып калган: *Күккә сагурса йүзгә түшүр (Күккә төкерсә, йөзгә төшәр), Күкнең баскычы юк* һ.б.

*Тәңре/*täŋre* сүзе борынгы төрки язмаларда ике мәгънәдә – күк һәм күк Алласы мәгънәсендә кулланылган: 1. Üzä kök täŋri asra yağïz yer qïlïntuqda ikin ara kisi oğlï qïlïnmïs (Күлтәгин язмасы, б.э. 732 ел). *Өскә күк Алласы, аска коңгырт-кара җир кылынганда, ике арага кеше баласы кылынган (барлыкка килгән)*. 2. Jęrni kökni jaraţqan (Мәхмүт Кашгарый, «Диване лөгат-әт-төрк», 1073 ел) *Җирне, күкне яралткан (барлыкка китергән).* Билгеле булганча, әлеге атама Алла сүзенә синоним рәвешендә хәзерге татар телендә дә кулланыла: *Татар иле! Тәңре бүләге син!* (Ф. Низамова). Нәкый ага Исәнбәт туплаган мәкальләр арасында *«Тәңрегә әйткән, кирәмәткә биргән», «Тәкәнең мөгезе Тәңрегә җиткәнен кем күргән?»,*

*«Мечкәй – Тәңренең убыры»* вариантлары очрый [Исәнбәт, 2010, б. 762].

*Асман/*astan* сүзендә борынгы төрки халыкларның күзаллаулары чагылыш тапкан: *as – *җир өстенә асылып куелган; as+ым (синкретик сыйфатлы исем фигыльдән ясалган)+ан (ас(ы)ман – исемләшкән сыйфат фигыль)= асылган* мәгънәсен белдерә. *Асман* сүзе «күк йөзе» мәгънәсендә татар теленең көнбатыш диалектында (тубыл-иртыш сөйләшендә) бүгенге көнгә кадәр актив кулланыла [Татар..., 2009, б. 58], әдәби телдә исә ул, китап сүзе буларак, XX гасырга кадәр актив булган.

*Йолдыз/*juldız* термины гомумтөрки телдән үк килә һәм төрле фонетик вариантларда барлык төрки телләрдә дә диярлек кулланыла. Этимологиясе «ялтырау» мәгънәсенә барып тоташа. Еш кына төрки телләрдә ул, антропоним буларак, хатын-кыз яисә ир-атка бирелгән. Шунысы кызыклы: борынгы чорда халыклар күк йөзе җисемнәрен аерым йолдызлыкларга, галактикаларга *(галактика – бор.грек. γάλα, γάλακτος «сөт», Сөт юлы – «Млечный Путь»)* берләштереп атамаганнар, шуңа күрә йолдызлыклар да, галактикалар да, гомуми рәвештә, «йолдыз» дип аталган.

Шул рәвешле, татар телендә кулланылган *kök, täŋri, asman, joldız* сүзләре борынгы төрки катламнан ук килгән космонимик сүз байлыгын тәшкил итәләр.

Төрки чыгышлы йолдыз һәм йолдызлык атамаларыннан хәзерге татар телендә *Ай, Кояш, Киек Каз юлы, Җидегән (Етегән) йолдыз, Чүмеч йолдыз, Тустаган йолдыз, Тимер Казык йолдыз, Котып йолдыз, Күкбүзат йолдыз, Акбүзат йолдыз, Өлкәр йолдыз, Иләк йолдыз, Көянтә йолдыз, Чулпан йолдыз, Зөһрә йолдыз, Таң йолдызы, Шәфәкъ йолдызы, Кызыл йолдыз* атамалары кулланыла.

*Ай* – Җир планетасының бердәнбер табигый иярченен атау өчен кулланылган лексик берәмлек. *Ай* лексемасы борынгы төрки нигез баба телдән үк килә, рун язулы борынгы текстларда язма рәвештә теркәлеп калган һәм барлык төрки халыклар өчен уртак. 30-31 көнгә тигез булган (һиҗри тәкъвимдәге бер айда 29–30 көн) вакыт берәмлеген атау өчен дә файдаланылган. Матур әдәбият һәм фольклор әсәрләрендә матурлык, гүзәллек символы буларак кулланылган, *ай* лексемасы кергән сурәтләү чаралары телдә бик популяр булган. «Татар халык авыз иҗаты. Мәкаль һәм әйтемнәр» хезмәтендә *Ай* атамасы белән бәйле иллегә якын мәкаль-әйтем, сынамышлар тупланган: *Ай тулса, йолдызлар сыегая; Айга күлмәк киермиләр; Бер күктә ике Ай булмас; Ай утырып туса, аяз була* һ.б. [Татар халык..., 1987, б. 39].

*Кояш* – Җир планетасына иң якын йолдыз атамасы. Аның тирәсендә бу системаның башка объектлары – планеталар һәм аларның иярченнәре, кәрлә планеталар һәм аларның иярченнәре, астероидлар, метеороидлар, кометалар һәм галәми тузан әйләнә. *Кояш* сүзенең борынгы вариантлары *kün, künäş, qujaş* формалары булган дип карала

[Древнетюркский..., 196, с. 326, 327, 464 ]. Борынгы төрки тамырда *көю* (яну – гореть) мәгънәсе ачыклана. Шулай ук төрки-татар язма әдәби истәлекләрендә, борынгы мәкаль-әйтемнәрдә сакланып калган: *Күнгә баксаң, көз камар (Кояшка карасаң, күз камашыр)* һ.б.

Татар әдәбиятының чишмә башы булган «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (Кол Гали, XIII гасыр) *ай* һәм *кояш* лексемалары күк җисеме атамасы буларак та, сурәтләү чарасы буларак та кулланыла: «Дугар күн, тулун ай, онбир йулдуз Дүшим ичрә сәҗдә кыйлды бәңа дүб-дүз» *(Туар кояш, тулган ай, унбер йолдыз Төшемдә сәҗдә кылды миңа тәгаен)*, «Тулун ай дип балкыр иди аның йүзи» *(Тулган ай кебек балкый иде аның йөзе)*, «Биңзе нуры күнәш кеби балкыр имди» *(Йөзенең нуры кояш кебек балкый инде)*.

*Киек Каз (Кыр казы) юлы* атамасы *(рус. Млечный Путь)* космонимик лексемалар арасында иң борынгылардан санала. Шунысы кызыклы: төрле халыклар әлеге галактиканы төрлечә атаганнар, бу атамалар халыкларның көнкүреше, күзаллаулары белән бәйле. Мәсәлән, Идел буенда яшәгән татар, башкорт, мари халыклары телләрендә әлеге галактика мәгънәсе буенча «киек каз юлы» яки «каз юлы» дип аталса, мукшы, эрзя телләрендә «торна юлы» яки «кош юлы» дип исемләнгән. Ханты һәм мансилар исә аңа «чаңгы юлы», Урта Азиядә «салам карагы юлы», Венгриядә яки Молдовиядә «чегән юлы» мәгънәсендә атама биргәннәр [Абдуллина, Гайнуллина, с. 11–41].

*Җидегән* (Етегән) *йолдыз* (рус. *Большая Медведица*) космонимы шулай ук күп кенә төрки халыклар өчен уртак, борынгы атамаларның берсе булып тора. Җирдән караганда, җиде йолдыз роткалы чүмечкә охшаган сурәт барлыкка китерә, шуңа күрә кайбер халыкларда аның бер варианты буларак, *Чүмеч йолдыз* һәм *Тустаган йолдыз* атамалары да кулланыла. Җидегән йолдызлыгы ике өлешкә – Зур һәм Кече Җидегәнгә бүленә.

*Зур Җидегән йолдызлыгы* – гади күзгә яхшы күренгән зур, якты җиде йолдыздан тора. Башка халыкларда бу йолдызлыкны Зур Аю *(лат. Ursa Major; гар. Әддөбб әл-әкбәр, рус. Большая Медведица)* дип атыйлар. Ул Клавдий Птолемейның б.э.ның 140 нчы елларында төзелгән «Альмагест» йолдыз каталогына кертелгән. Әл-Бируни үзенең 1030 елда тәмамланган «Мәсгуд кануны»нда Птолемейның бор. грек. ἄρκτος μεγάλη исемен гарәп теленә «Әддөбб әл-әкбәр» сүзләре белән тәрҗемә иткән. Татар халкы иске төрки-татар әдәби телендә йолдызлыкның *Дөббеләкбәр* гарәп атамасын да кулланган.

*Кече Җидегән йолдызлыгы (Кече Аю; лат. Ursa Minor)* – күк йөзенең төньяк ярымшарындагы котып янында урнашкан йолдызлык. Аңа гади күз белән күренә торган кырыклап йолдыз керә. Кече Җидегән йолдызлыгында Тимерказыктан 1° ераклыкта Җир шарының Төньяк котыбы урнашкан. Кече Җидегән төркеменнән берничә йолдызның төрки-татар чыгышлы атамалары билгеле:

α – *Тимерказык (Котып йолдызы)*. Клавдий Птолемей аны «койрык очындагы йолдыз» *(Аюның койрык очындагы)* дип атаган. Әл-Бируни «койрыкның очы» һәм «җәди әл-кыйбла» – «кыйбланың кәҗә бәтие» дип атый. Хәзерге гарәп телендә «нәҗм әш-шималь» – Төньяк йолдызы дип исемләнә.

β – *Акбүзат* (Кәукәб, гар. *әл-кәукәб әш-шимали* – «төньяк йолдыз»; рус. Кохаб). Б.э.к. 1900 елдан б.э.ның 500 нче елына кадәр бу йолдыз күк йөзенең Төньяк котыбына иң якын йолдыз булган һәм Котып йолдызы сыйфатында йөргән. Бу үзенчәлек аның гарәп исемендә сурәтләнгән.

γ – *Күкбүзат* (гар. *фәркад* – «бозау»; рус. *Феркад*). Клавдий Птолемей аны «киләсе якның төньяк йолдызы» дип биргән. Әл-Бируни «Мәсгуд кануны»нда аны «икедән төньяктагы» дип атый.

*Тимерказык* (Котып йолдызы) төрки халыкларда күккә кагылган «тимер казык» итеп күз алдына китерелгән һәм аның янындагы ике йолдыз шул казыкка бәйләп куелган Акбүзат һәм Күкбүзат дип исемләнгән тайлар буларак күзалланган. Тимерказык хәрәкәт итми һәм һәрвакыт Төньяк котып ягын күрсәтә, шуңа күрә ул бик борынгы заманнардан бирле юл-сәфәр йөрүчеләр өчен ышанычлы табигый ориентир буларак хезмәт иткән. Х. Мәхмүтов тарафыннан китерелгән (Н. Исәнбәттән алынган) бер риваятьтә *Тимерказык, Акбүзат* һәм *Күкбүзат йолдызлары* турында болай диелә: «Акбүзат һәм Күкбүзат – Тимерказык (Котып) йолдызы тирәли әйләнүче ике йолдызның исеме (беренчесе – шактый якты, икенчесе, аның белән чагыштырганда, тоныграк булып күренә). Бер легендада сөйләнгәнчә, берсе ак, икенчесе күк ике атны тимер казыкка бәйләп куйганнар имеш. Шул казык тирәсеннән китә алмыйча утлап йөргәндә, аларны җиде карак (Җидегән йолдыз) урлап китәргә ниятләгән. Болар Акбүзат һәм Күкбүзат артыннан әй чабалар, әй чабалар, әмма куып җитә алмыйлар, ди» [Татар халык..., 1987, б. 525].

*Өлкәр йолдызы* Сәвер *(Үгез-бозау)* йолдызлыгында урнашкан йолдызлыкларның (рус. *Плеяды*) берсе. Ул күп кенә төрки телләрдә таралган борынгы атама булып санала. Өлкәр, башлыча, татар әдәби телендә кулланыла торган атама, халыкның сөйләмә телендә *Иләк йолдыз* термины ешрак очрый. Г.Р. Абдуллина фикеренчә, Өлкәр атамасы «өлкән» мәгънәсен белдерә, башкорт телендә аның *Сыңғы, Сыңға йондоҙ* (бөҗрасыман йолдыз) атамалары бар [Абдуллина, 2016, с. 297]. Безнең карашыбызча, *өлкәр* сүзе кайчандыр телдә ‘иләү’ *(өләк/иләк)* мәгънәсе белән бәйле булырга мөмкин, чөнки әлеге йолдызлыктагы йолдызлар, иләктән сибелгән кебек, таралып урнашканнар. Шулай ук бу сүзнең «тишек» мәгънәсе билгеле.

*Көянтә йолдыз* (рус. *Орион*) иске төрки-татар язма истәлекләрендә гарәп теленнән алынган *Җәуза* һәм *Җәббар* сүзләре белән аталган. Татар телендәге атамасы нигезендә охшашлыкка бәйләнгән метафора ята (әлеге

йолдызлыктагы унбер йолдыз күктә көянтә рәвешендә күренә).

*Чулпан йолдыз, Зөһрә йолдыз, Таң йолдызы, Шәфәкъ йолдызы* – Венера (лат. *Venus*) планетасын атый торган атамалар. Төрки халыкларда әлеге атама белән бәйле легендалар шактый, планета өслегендә күренгән тапларны халык көянтә аскан кызга охшатып, халык авыз иҗаты әсәрләре барлыкка килгән (табышмаклар, әйтем-мәкальләр, үги кыз әкияте, Зөһрә кыз әкияте һ.б.).

*Кызыл йолдыз* – Марс планетасы атамасы. Өслегендә күп булган тимер оксиды Марска кызгылт төсмер бирә, шуңа күрә аны «Кызыл планета», «Кызыл йолдыз» дип атаганнар. Иске төрки-татар язма истәлекләрендә гарәп теленнән алынган *Мәрих* атамасы очрый.

Югарыда язылганнардан чыгып, шуны әйтергә мөмкин: татар телендә төрки чыгышлы космонимнар күп түгел. Бу – татар халкының шактый борынгыдан утрак тормышка күчеп, ориентир өчен әһәмиятле булган йолдыз атамаларының халык хәтереннән әкренләп югалуы белән бәйле булса кирәк. Шуңа карамастан, халык аңында бүгенге көндә дә күк йөзендә күзәтелгән төп космонимик җисемнәрнең атамалары саклана, алар фольклор әсәрләрендә, матур әдәбиятта, халыкның җанлы сөйләмә телендә кулланылуларын дәвам итәләр.

***2. Гарәп теленнән кергән алынма космонимнар.***

Хәзерге вакытта Россия халыклары куллана торган календарь системасы татарларда XIX гасырның икенче яртысында гына ныклап урнаша. Аңа кадәр кулланылган зодиакаль календарь гарәп теленнән алынган йолдызлык исемнәре нигезендә корылган булган. Татарлар «Фәкать игенчелек эшләре өчен, кояш хисабы белән яз башыннан башлап, «хәмәл, сәвер, җәүза, саратан, әсәд, сөнбөлә, мизан, гакъръәб, кавыс, җәди, дәлү, хут» дип, гарәби исемнәр кулланалар», – дип яза Шиһабетдин Мәрҗани «Мостафад-әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар...» әсәрендә (http://kitap.net.ru/marjani1.php). Шушы ук сүзләрне Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыентыгында да күрәбез: «...язма календарьда ай исемнәре түбәндәгечә: 1. Дәлү (чиләк) – гыйнвар; 2. Хут (балык) – февраль; 3. Хәмәл (кузы) – март; 4. Сәвер (Үгез) – апрель; 5. (Җәүза) – май; 6. Сәрәтан (Кысла) – июнь; 7. Әсәд (арыслан) – Июль; 8. Сөнбелә (сөнбел чәчле кыз) – август; 9. Мизан (бизмән) – сентябрь; 10. Гакрәб (Чаян) – октябрь; 11. Кавәс (Җәя) – ноябрь; 12. Җәди (Кәҗә бәрәне, Ылак) – Декабрь» [Исәнбәт, 2010, б. 288]. Шул рәвешле, вакытны санаганда да төрки бабаларыбыз уникe зодиакаль йолдызлык исемнәренә корылган гарәп чыгышлы ай исемнәреннән файдаланган.

Алда әйтелгәнчә, XI–XVI гасырлар Көнчыгыш гарәп илләрендә астрономия фәненең чәчәк ату чоры буларак билгеле, төрки халыклар исә ислам дине аркылы Көнчыгыш мәдәнияте казанышларын үзләренә кабул итеп алганнар. Шул исәптән, фәнни әйләнешкә гарәп теле космонимнары

да үтеп кергән. Идел буенда астрономия буенча язылган фәнни трактатларда, Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани кебек олы галимнәрнең хезмәтләрендә гарәп теле терминнары һәм космонимик берәмлекләр урын алган, шуңа күрә аларны өйрәнү зарур. Гарәп космонимнары төрки халыкларга гына түгел, европа телләренә дә үтеп кергәннәр һәм урнашып калганнар. Дөньяви астрономия фәнендә термин буларак кулланыла торган күп кенә атамаларның нигезендә гарәп сүзләре ята.

Гарәби чыгышлы йолдыз атамалары:

*Зур Җидегән* йолдызлыгындагы җиде йолдызның да гарәпчә исемнәре кулланылган: α йолдызы – *Дубхе* (*дөбб* – «аю», гар. *каһил әд-дөбб* – «аюның аркасы»); β – *Мәрәк* (гар. «корсак»; рус. *Мерак*); γ – *Фәкда* («бот», гар. «аюның боты»); δ – *Мәгъриз* (гар. койрык «баш»ы; рус. *Мегрец*); ε– *Әлҗүн* (гар. «кара ат»; рус. Алиот); ζ– *Мизар* (гар. «алъяпкыч», рус. Мицар); η– *Бәнәтнаш* яки *Әлкаид* (гар. «яслатучылар (кыз елатучылар) башлыгы»).

*Орион* (Көянтә, гар. *Җаббар*) йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы атамалар: α – *Бителҗәүза* (гар. *ибт әл-җәүза* – «Бәйленең култык асты», монда «Бәйле» астында Орион күздә тотыла; рус. *Бетельгейзе*); β – *Риҗел* (гар. ٰ*риҗл әл-җәббар* – «Орионның аягы»; рус. *Ригель*); δ – *Минтака* (гар. *минтака* – «билбау»); ζ – *Әлнитак* (гар.ٰ *ән-нитак* – «кушак»; рус. *Альнитак*); Минтака һәм Әлнитак йолдызлары «Орион Билбавы»н тәшкил итә; ε – *Әлнизам* (гар. *ән-низам* – «энҗе җебе»; рус. *Альнилам*), κ – Сәеф (гар.ٰ *сәеф* – «кылыч», Орионның кылычы күздә тотыла; рус. *Саиф*).

*Мизан* (Үлчәү) йолдызлыгына (гар. «үлчәү»; лат. *Libra*) караган гарәп чыгышлы атамалар: α – *Зөбәнел-Җәнүби* (гар. «көньяк кыскыч»); β – *Зөбәнел-Шимали* (гар. «төньяк кыскыч»); γ – *Зөбәнел-Гакрәп* (гар. «чаян кыскычы»);

*Дәлү* (Сукояр) йолдызлыгы (гар. *әд-дәлү* «чиләк»; лат. *Aquarius*): α – *Сәгыделмәлик* яки *Сәгыделмөлек* (гар.ٰ *сә'д әл-мәлик* – «патшаның бәхетлелеге» яки *сә'д әл-мөлк* «илнең бәхетлелеге»; рус. *Садальмелик*); β – *Сәгыделсогуд* (гар.ٰ *сә'д әл-со'уд* – «бәхетлекнең бәхетлелеге»); δ – *Сак* (гар. *әс-сак* – «балтыр», әл-Бируни бу йолдызны «уң балтырда икенчедән көньяктагы» дип атаган; рус. *Скат*);

*Сәвер* (Үгезбозау) йолдызлыгы (гар. *әҫ-ҫәвр* – «үгез»; лат. *Taurus*): α – *Әлдәбәран* (гар. *әддәбәран* – «иярүче», «Гиадалар артыннан иярүче» күздә тотыла, шулай ук йолдызны Үгезнең Күзе (лат. *Oculus Taurī*) дип тә атаганнар; рус. *Альдебаран*); β – *Әлнәтых* (гар. *ән-нәтх* – «чик», «мөгезләрнең чиге» күздә тотыла);

*Әсәт* (Арыслан) йолдызлыгы (гар. *әл-'әсәд* – «арыслан»; лат. *Leo*), аңа караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: β – *Дәнәбәл* (гар. ٰ*ҙәнәб әл-'әсәд* – «арыслан койрыгы»); γ – *Әлҗәбһә* (гар. *әл-җәбһәһ, җәбһәт әл-'әсәд* – «арыслан маңгае», әмма чынлыкта «Арыслан ялы» булып тора; рус. *Альгиеба*); δ – *Зоһер*

(гар. *зоһер әл-'әсәд* – «арыслан биле», шулай ук Зосма – бор. грек. «билбау»); ε – *Әлҗәнүби* (гар. *рә'с әл-'әсәд әл-җәнүби* – «арыслан башының көньяктагы йолдызы»); ζ – *Әлзафирә* (гар. әз-зәфирәһ); η – *Әл Җәбһә* (гар. *әл-җәбһәһ*); θ – (гар. *әл-хорт*); κ – (гар. *минхир әл-'әсәд* – «арслан борыны»); Әсәт λ – Әлтараф (гар. *әт-тарф* – «күренеш»); μ – *Рәэсәләс* (яки Әлшимали, гар. *рә'с әл-'әсәд әш-шимали* – «арыслан башының төньяктагы йолдызы»).

*Зур эт* (Кәлб-әл-әкбәр) йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: β – *Мирзам* (гар. *мирзам* – «өндәүче» яки *мурзим* – «бәй», рус. *Мирцам*); γ – *Мөхлифәйн* (гар. *мөхлифәйн* «этнең күзе», рус. *Мулифен*); δ – *Вәзен* (гар. *вәзн* – «авырлык», рус. *Везен*); ε – *Газараэ* (гар. *әл-'әҙара'* – «гыйффәтле кызлар», рус. *Адара*); ζ – *Фуруд* (гар. *фуруд* – «ялгыз», «аерылган»); η – *Әлгазраэ* (гар. *әл-'әҙра* – «гыйффәтле кыз», рус. *Алудра*).

*Кефей* йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: α – *Әлзирамин* (гар. *әз-зира'* әл-йәмин – «уң кул»); β – *Әлфирк* (гар. *әл-фирқ, әл-фирқәһ* – «өер»); γ – *Әлрагый* (гар. *әр-ра'и* – «көтүче»); δ – *Әлрәдиф* (гар. *әр-рәдиф* – «ияреп баручы»).

*Персей* йолдызлыгына караган гарәп чыгышлы йолдыз атамалары: α – *Мирфәкъ* (гар. *әл-мирфәқ* – «терсәк», «Персейның терсәге» күздә тотыла; рус. *Мирфак*); β – *Әлгул* (гар. *рә'с әл-гул* – «Горгонаның башы»; рус. *Альголь*).

Гарәби чыгышлы йолдызлык атамалары:

*Әлтаир* йолдызлыгы (гар. *ән-нәср әт-та'ир*) «очучы каракош»; *Җәди* йолдызлыгы (гар. *әл-җәди* «кәҗә бәтие»; шулай ук Кәҗәмөгез йолдызлыгы; лат. *Capricornus*); *Җәүза* йолдызлыгы (гарәп. «бәйле»; шулай ук Игезәкләр йолдызлыгы; лат. *Gemini*); *Гакрәп* йолдызлыгы (гар. *әл-'әкрәб* – «чаян»; шулай ук Чаян йолдызлыгы; лат. *Scorpius*); *Саратан* йолдызлыгы (гар. *әс-сәрәтан* – «кысла»; шулай ук Кысла йолдызлыгы; лат. *Cancer*); *Кавәс* йолдызлыгы (гар. *әл-қәўәс* – «җәя»; шулай ук Укчы йолдызлыгы; лат. *Sagittarius*); *Хут* йолдызлыгы (гар. «зур балык»; шулай ук Балыклар йолдызлыгы; лат. *Pisces*); *Хәмәл* йолдызлыгы (гар. *әл-хәмәл* «бәрән»; шулай ук Кучкар йолдызлыгы; лат. *Aries*); *Сөмбелә* йолдызлыгы (гар. *сөнбелә* – «башак»; шулай ук Кыз йолдызлыгы; лат. *Virgo*); *Әлтаир* (гар. *ән-нәср әт-та'ир* – «очучы каракош»); *Еланлы Кеше* β – Кәлбелрагый (гар. *кәлб әр-ра'и* – «көтүче эте»); *Әл-Газараэ* («Гыйффәтле Кызлар») йолдызлар төркеме.

Шул рәвешле, иске татар теленең фәнни стилендә кулланылган гарәп чыгышлы космонимик атамалар сан ягыннан шактый күп. Алар бүгенге көндә махсус өйрәнүне, системалаштыруны таләп итә.

***3. Рус теле аша һинд-европа (грек, латин) телләреннән кергән алынма космонимнар.***

Хәзерге чорда дөнья телләренең күпчелегендә фәнни стильдә латин теле терминнары

кулланыла, шуңа күрә космонимик атамаларның да шактый өлеше – латин нигезле. Шунысын да ассызыклау мөһим: йолдызлык атамаларының күбесе рус теленә Европа телләреннән тәрҗемә итеп алынганнар, XX гасырда исә, астрономия фәнен мәктәпләрдә татарча укыту ихтыяҗы килеп тугач, бу исемнәр рус теленнән татар теленә тәрҗемә ителгәннәр һәм фәнни әйләнешкә тәрҗемә формада кергәннәр. Мәсәлән, *Почмаклык (*Угольник*), Рәссам (*Живописец*), Вероника чәче* (Волосы Вероники) һ.б. Шул ук вакытта европа телләрендә гарәп теленнән алынган атамалар кулланылган, рус теленә алар фонетик яктан җайлаштырып кабул ителгәннәр, ә татар теленә рус телендә әйтелгәнчә кереп киткән: *Бетельгейзе* – Орион йолдызлыгының α йолдызы, *Мирзам* – Зур Эт йолдызлыгының β йолдызы, *Альдебаран* – Үгезбозау йолдызының сары α йолдызы, *Мицар* – Зур Җидегән йолдызлыгының ζ йолдызы, *Вега* – Лира йолдызлыгының α йолдызы һ.б. Бу атамаларның гарәп теленеке булуы, беренче карашка, сизелми дә (мәсәлән, *Факт* йолдызының исеме гарәп теленең Фахита сүзеннән алынган, *Фомальгаут* – гар. *фум аль хут* (балык авызы) һ.б.).

Шул ук вакытта татар әдәби теленә рус-европа телләре аша *латин нигезле* космонимнар да алынган. Аларның кайберләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин:

*Альциона* – Иләк йолдызлыгындагы γ йолдызы. Йолдызның исеме мифологик Плеядаларның (Иләк йолдызлыгы) берсе – Алкиона (мифологик Атланта һәм Плеона исемле аллаларның кызы, Посейдонның сөеклесе) исеменнән алынган.

*Антарес* – Чаян йолдызлыгының α йолдызы. «Антарес» сүзе грек теленең ανταρης «Ареска (Марска) каршы» мәгънәсендәге сүздән алынган. Бу йолдыз кызыл төстә булуы белән Марс планетасына охшаган. Гарәп телендә исә ул «Чаян йөрәге» мәгънәсендәге «Кальб-аль-Әкраб» исемен йөртә.

*Арктур* – Үгез көтүчесе йолдызлыгындагы α йолдызы. Борынгы грек телендәге Ἀρκτοῦρος < ἄρκτου οὖρος «Аю сакчысы» мәгънәсендәге сүздән алынган. Легенда буенча, Зевс тарафыннан күккә Гера аюга әверелдергән әнисе нимфа Каллистоны сакларга куелган. Гарәп телендә кулланылган «Харис-ас-сама›э» атамасында да «күк сакчысы» мәгънәсе бар.

*Беллатрикс* – Орион йолдызлыгының γ йолдызы. Беллатрикс (лат. Bellātrix) – латин теленә, «сугышчы хатын-кыз», «амазонка» буларак, гарәп теленең «*әл-нәҗид* – яулап алучы» сүзеннән тәрҗемә итеп алынган.

*Капелла* – Йөкче йолдызлыгының α йолдызы. Капелла сүзе латин телендә «кәҗә» дигәнне аңлата. Ул Амалфея исемле кәҗәне гәүдәләндергән. Юпитерны имезеп үстергән бу кәҗәнең мөгезе мифологиядә «муллык мөгезе» («Рог изобилия») буларак танылган.

*Плейона* – Үгезбозау йолдызлыгындагы ϒ йолдызы. Атлант исемле титанның хатыны, алардан җиде гүзәл Плеядалар туган.

*Сириус* – Зур Эт йолдызлыгындагы α йолдызы. Атамасы

грек теленең sirius – Σείριος («якты», «ялтыравыклы») сүзеннән килә. Орион яки Икарий исемле мифологик затларның сакчы эте. Зур Эт йолдызлыгындагы Процион һәм Сириус йолдызларын ике эт итеп күзаллаганнар. Латин телендә дә шул ук атама (Canicula – «кечкенә эт» дигәнне аңлата). Бу йолдыз, җәйге челлә башлангач, күк йөзендә иртәнге якта күренә башлый, шуңа күрә бу вакытны «каникул көннәре» дип атаганнар.

*Целено* (Келенó) – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдызы. Борынгы грек телендәге Κελαινώ – караңгылык, кара мәгънәсендәге сүздән алынган. Атлант һәм Плейонадан туган кыз исеме, Посейдонның тагы бер сөеклесе.

*Центавр* Альфасы – Центавр йолдызлыгы α йолдызы, *Центавр* Проксимасы – Центавр йолдызлыгының α йолдызы. Центáвр яки Кентáвр (лат. *Centaurus*) – Хирон исемле үтә акыллы һәм зирәк мифологик затны (кентаврны), Кронос һәм нимфа Филираның улын гәүдәләндерәләр.

*Электра* – Үгезбозау йолдызлыгындагы α йолдызы. Элéктра (борынгы грек. Ἠλέκτρα) – грек мифологиясендәге Агамемнон һәм Клитемнестраның кызы, грек трагедияләрендәге героиня исеме.

Шунысы кызыклы: космонимнар арасында грек һәм латин нигезле атамалар күп түгел. Күпчелек атамалар, алда әйтелгәнчә, тәрҗемә итеп алынганнар.

**Әдәбият**


*Абдуллина Г.Р., Гайнуллина Г.Д.* Наименования небесных тел (на материале башкирского языка) // Научно-методический электронный журнал «Концепт». 2014. Т. 20. С. 1141–1145. URL: http://e-koncept.ru/2014/54492.htm.

*Аронов К.Г.* Этнолингвистическая природа народных космонимов в казахском языке : автореф. дис. ... канд. филол. наук : 10.02.06. Алма-Ата, 1992. 22 с.

Древнетюркский словарь / авторы-сост.: Т.А. Боровкова, Л.В. Дмитриева и др.; под ред. В.М. Наделяева, Д.М. Насилова и др. Л., 1969. 677 с.

*Исәнбәт Н.С.* Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 799 б.

*Мирхаев Р.Ф., Гумеров И.Г.* Татарская религиозно-языковая картина мира: эволюция культурных и духовно-ценностных ориентиров. Казань: ИЯЛИ, 2017. 120 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика: 2-е изд., доп. М.: Наука, 2001. 822 с.

*Сызранова Г.Ю.* Ономастика: учеб. пособие // Г.Ю. Сызранова. Тольятти : Изд-во ТГУ, 2013. 248 с.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 592 б.



***Кузьмина Халисә Хатыйп кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Р.Ф. Мирхәев***

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ДИНИ КҮЗАЛЛАУЛАР СИСТЕМАСЫНДА КЕШЕ ОБРАЗЫ ҺӘМ АНЫҢ ТЕЛДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

Религиозное мировоззрение татарского народа представляет собой особую систему духовных ценностей и представлений о мире, которая складывалась в течение многих веков под воздействием мусульманской традиции. В то же время в ней прослеживается и следы религии тэнгрианства, которую до принятия ислама исповедовали предки современных татар. Все это нашло свое отражение в татарской религиозно-языковой картины мира. В качестве ее основополагающего ядра выступает концепт «Бог», в тесной взаимосвязи с которым раскрывается содержание других элементов, таких как «Человек». Статья посвящена изучению особенностей его вербализации в татарской лингвокультуре. Исследование проведено на основе материала, извлеченного из старотатарских письменных текстов.

**Ключевые слова:** языковая картина мира, религиозное мировоззрение, религиозная концептосфера, религиозный концепт.

Татар халкының дини күзаллаулар системасын күп гасырлар дәвамында формалашкан рухи кыйммәтләр, гореф-гадәтләр һәм карашлар тәшкил итә. Тарихи планда ул мөселман традициясенең йогынтысы астында формалаша. Шул ук вакытта анда ислам дине кабул ителгәнгә кадәр хәзерге татарларның борынгы бабалары тоткан тәңречелекнең эзләре дә сакланган. Боларның барысы да безнең көннәргә кадәр килеп җиткән иске татар язма чыганакларында чагылыш таба. Бүгенге көндә аларның тел үзенчәлекләре (график, фонетик, морфологик, лексик) өйрәнелеп, күпсанлы фәнни хезмәтләр язылды. Шул ук вакытта текстларның аерылгысыз өлешен тәшкил иткән, үзендә татар халкының дини күзаллаулары һәм аларның телдә чагылышы белән бәйле мәгълүматны туплаган дини лексика игътибардан читтә кала бирә. Аерым тикшеренүләрне исәпкә алмаганда, әлеге төр сүзләр галимнәр тарафыннан, әдәби әсәрләр теленең башка үзенчәлекләре белән бергә, лингвостилистик планда, яисә татар әдәби теле нормаларының формалашу һәм үсү тарихы контекстында карала [Мирхәев, б. 22].

Татар халкының дини күзаллаулар системасы структур яктан күпкырлы һәм катлаулы күренеш тәшкил итә. Ул үз эченә, «Алла», «Пәйгамбәр», «Фәрештә», «Оҗмах», «Тәмуг», «Гөнаһ» концептлары белән бергә, «Кеше» кебек турыдан-туры бу өлкәгә карамаган һәм билгеле бер контекстта гына өстәмә мәгънә төсмерләренә ия булган берәмлекләрне дә ала.

Мөселман традициясендә, кешенең төп атамалары буларак,

гарәп теленең *адәм* (آدم) һәм *инсан* (انسان) сүзләре кулланыла. Мәгълүм тарихи, дини, иҗтимагый һәм мәдәни факторлар тәэсирендә алар татар теленә дә үтеп кергәннәр һәм бүгенге көндә түбәндәге мәгънәләрдә кулланылалар:

*адәм:* 1) Җир йөзендә Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылган беренче кеше; 2) кеше, шәхес; 3) таныш булмаган ир кеше; 4) *кимс.* бәндә; начар, явыз ниятле яки булдыксыз кеше [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, I т., 2015, б. 65];

*инсан*: кеше, адәм [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, II т., 2016, б. 551].

Алардан башка биредә Аллага буйсынган кеше мәгънәсен фарсы теленнән кабул ителгән *бәндә* (بنده) һәм борынгы төрки язма чыганаклардан килә торган *кол* лексемалары да белдерә [Древнетюркский словарь, с. 465; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, I том, 2015, б. 462; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, III том, 2017, б. 314].

Әлеге сүзләрнең татар телендә кулланылышы, нигездә, дини өлкә белән чикләнә, ә төп һәм универсаль атама буларак 1) сөйләшү, фикерләү, корал җитештерү һәм аннан файдалана алу сәләтенә ия булган тере зат, адәм, кемсә; 2) билгеле бер һөнәр, гомумән нинди дә булса эш белән шөгыльләнүче зат; 3) югары әхлак һәм рухи кыйммәтләр гәүдәләнеше буларак шәхес һ.б. мәгънәләрне белдерә торган, килеп чыгышы буенча төрки-татар асыллы *кеше* лексемасы кереп киткән [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, III том, 2017, б. 235–236].

Урта гасыр иске татар әдәбияты әсәрләрендә кеше тулысынча Аллага буйсынган һәм аның ихтыярына бәйле булган җан иясе буларак тасвирлана. Моның өчен авторлар түбәндәге сүзләрне файдаланалар:

*адәми*: *Адәмигә* биңзәмәздер, заһир белең, мөқәррәб фәрештәйә биңзәр имди [Кол Гали, б. 120]; *Адәмидә* күб булур һәм бивафа [Мөхәммәдъяр, б. 67]; Бақты, күрде, ултурур бер *адәми* [Мөхәммәдъяр, б. 67];

*бәшәр*: Җиһан ичрә сәндик *бәшәр* улмыш дәгүл [Кол Гали, б. 124];

*бәндә*: Бу *бәндә* үзрә дәлилем сән улғыл имди [Кол Гали, б. 48]; *Бәндәләр* (уш) бү(йлә) тәшриф булғайлар [Мөхәммәдъяр, б. 55]; Йете иқлим сезгә уш *бәндә* ирүр [Мөхәммәдъяр, б. 176];

*бичара*: Иляһәна, кәрим Хәннан, *бичаралар* өмиди сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, с. 74]; Күңлүм уты йанмақ илә изтираб, қылды мән *бичарәне* әсри хәраб [Мөхәммәдъяр, б. 39]; Мин ирүрмән сезләр ара *бичара* [Мөхәммәдъяр, б. 46];

*зәгиф*: Мәүлем, сәңа сығынурмын мән бер *зәгиф* [Кол Гали, б. 48]; Бән *зәгифи* хикмәт таба сән йандырғыл [Кол Гали, б. 48]; Бу *зәгиф* бу китабы дүзди имди [Кол Гали, б. 294];

*қол*: Тәүфиқ сәндән уманурмын мән зәғиф *қол* [Кол Гали, б. 48]; Йарлықағыл, йа рәхим, бән ғаси *қоли* [Кол Гали, б. 293]; Йазуқлуқ *қолуң* мән гөнаһкяр [Мөхәммәдъяр, б. 170];

*мәзлум*: *Мәзлумләрең* доғасындан қурқың имди [Кол Гали, б. 84]; Мөдам өмид дута

сәңа җөмлә *мәзлум* [Кол Гали, б. 104];

*фәқир*: Мән ирүрмән бу шәһәрдә бер *фәқир*, ил күзүндә ғаҗиз-у хур, вә хәқир [Мөхәммәдъяр, б. 40]; Бер кешенең ике булса дошманы, қайда тынғай ул *фәқирнең* бер җаны [Мөхәммәдъяр, б. 64].

Язма чыганакларда дини контекстта *кеше* сүзе дә кулланыла: Ғафил улма үзүңдин сән, и *кеше*, кәчә-көндүз (һәм) эшең сәрғин *кеше* [Мөхәммәдъяр, б. 46]; Бу үлүмдин қачса, қотулмас *кеше*, үлмәйен бу дөнйада қалмас *кеше* [Мөхәммәдъяр, б. 58].

Алга таба, аерым алганда XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтче язучыларының әсәрләрендә, кеше бар яктан да тулы канлы тормыш алып баручы актив социаль зат буларак тасвирлана башлый. Бу, үз чиратында, югарыда телгә алынган сүзләрнең эчтәлекләрендә чагылыш таба. Әлеге чорга караган язма текстларда алар кешенең социаль статусын, аның җәмгыятьтә тоткан урынын ачыклап килгән *иҗтиһадлы*, *хезмәт сәвән*, *хәтме көтеб кылмыш, ғалим*, *буйук*, *бай*, *малдар, җәмәғәтләнмеш, нөфүзле*, *укымыш, фәқир* сүзләре белән бергә кулланылып, дөньяви характердагы яңа мәгънә төсмерләре белән баетылалар:

*адәм*: Бу ханә үзе күчүк булса да, тахтадан башы, анбары вә мөхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһадлы вә *хезмәт сәвән адәм* идегене күстәрерләр иде [Акъегет, б. 2]; Петербургда университетта *хәтме көтеб кылмыш адәм* улса да, ... [Бигиев, 1887, б. 8]; Муса Салихов *җәмәғәтләнмеш адәм* түгел иде [Бигиев, 1887, б. 8];

*кеше*: ... ханәнең, аш вә йәмәкнең тәмизлеге *йахшы вә байырақ кешеләрне* җәлеп идәр иде [Акъегет, б. 9]; Ниндәләйен, *малдар кешеме*? [Бигиев, 1890, б. 10];

*зат*: Мохтара кәленчә, бу *зат* үзе *ғалим* улмаса да, бунларың милләтпәрвәрлекләрене аңлады [Акъегет, б. 29–30]; Хәзердә ул мәдрәсәдә бер *мөбарәк зат ғалләмә* вә фәридел-ғасыр улан дамелла Ғабделғәлләм хәзрәтләре дәрес әйтәдер [Бигиев, 1890, б. 10];

*инсан*: Ғалим дисәң, кәзалик хата дийәрез, чүнкә *ғалим инсан* ғәйбәтләрдән қачадыр [Акъегет, б. 13];

*кемсәнә*: Һәм авылда Гали байдан *нөфүзлы кемсәнә* йуқ иде, ул нә диде, шул булды [Акъегет, б. 12]; ... шәкердләрә вә *уқымыш фәқир кемсәнәләрә* тәслим иделеҗәк [Акъегет, б. 61]; Мәсҗедә кәлән җәмәғәт арасында нәдән исә дә, ғайәт фәқир кемсәнәләр дә күбдер [Бигиев, 1890, б. 3].

Бу дәвердә кеше, Алла колы буларак кына түгел, җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзасы, аның аерылгысыз өлеше буларак карала башлый һәм ул түбәндәге сүзләрнең кулланылышында да күренә:

*әһали*: Шәһәремезең һәммә *әһалисе* мәзкүр мәүкыйфә тупланмышлар [Акъегет, б. 41]; «К» қарйасы *әһалисенең* мәғишәт ичүн хезмәте игенчелек улса да, эксәресе башка шәһәрләрә, ... хезмәт вә тиҗарәт ичүн кидәйурлар [Бигиев, 1890, б. 2];

*халыҡ*: Ләкин чуҡ *халыҡлары* башҡа шәһәрләрә, мәсәлән, Әстерхан, Растуф, Казан кебиләрә иш вә тиҗарәт ичүн дағылырлар [Акъегет, б. 2]; Кичәге ма wаҡағаны Әхмәди бай белмәк түгел, бәлки нисфы шәһәр *халҡы* ишедеп, зийадәсилә белмешләр иде [Бигиев, 1887, б. 16];

*ислам*: Мәзкүр кяғыд Русйа *исламларының* сәламәтене вә хөсне мәғишәтене мөхафәза идән «Тәрҗеман» җәридәсе иде [Акъегет, б. 4]; Әмма унбер милиун *ислам* дере ҡалды [Акъегет, б. 7]; Мәуҡифнең эчендә вә тышында анда-бунда *исламлар* сөйләшүб гәзәләр [Акъегет, б. 42];

*мөселман*: Әмма базы *мөселманлар* ... иғәнә итмәделәр [Акъегет, б. 61]; Үткән кичдә бер чәйханәдә ике *мөселман* бу тариҡа сөйләшеп чәй эчәйүрлар ... [Бигиев, 1887, б. 30]; Җиһангир Агийевкә мағада бу ханәдә өчдүрт *мөселман* мәүҗүд иде [Бигиев, 1890, б. 36].

Йомгаклап әйткәндә, татар халкының дини күзаллаулар системасында кеше баштан ук Алла тарафыннан яратылган һәм бар нәрсәдә дә аңа буйсынучы җан иясе буларак кабул ителгән. Әлеге караш мөселман традициясе өчен хас дип санала. Ләкин, тел материалларыннан күренгәнчә, татарларда ул баштан ук яшәп килгән. Алга таба кеше җәмгыятьтә үз урынын билгән, социаль яктан актив зат буларак та карала башлый.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Бигиев З.* Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 543 б.

*Мирхәев Р.Ф.* Татар лингвокультурасында «Алла» концепты // Фәнни Татарстан, 2017, № 3, Б. 22–27.

*Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А–В. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г–Й. Казан: ТӘһСИ, 2016. 748 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. Казан: ТӘһСИ, 2017. 744 б.

*Статья подготовлена при финансовой поддержке РФФИ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 16-14-16011*

*Мәкалә Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 16-14-16011 номерлы фәнни проект кысаларында әзерләнде*

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145’28

*М.Р. Булатова*

# СТӘРЛЕБАШ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена характеристике языковых особенностей татар Стерлибашевского района Республики Башкортостан. В работе рассматриваются некоторые общие морфологические особенности стерлитамакского говора мишарского (западного) диалекта и белебеевского подговора мензелинского говора среднего диалекта татарского языка. Прилагаются образцы речи, в которых сквозь призму лексики и языковых особенностей местного говора рассматриваются материальная и духовная культура татар. Она написана на основе фактических материалов, собранных автором во время диалектологических экспедиций в 2010–2012 гг., и комплексной экспедиции, проведенной в 2017 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ по татарским деревням Стерлибашевского района РБ.

**Ключевые слова.** Татарская диалектология, стерлитамакский говор мишарского диалекта, белебеевский подговор мензелинского говора среднего диалекта, морфология, материальная и духовная культура, научная экспедиция.

Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы Айдарәле, Бакча, Бакый, Бузат, Гөлем, Әмир, Карагыш, Куганакбаш, Турмай, Хәлекәй, Өч-Әсән (Көчегән), Стәрлебаш, Тәтер-Арыслан, Яңгырчы, Яшергән һ.б. татар авылларына фәнни экспедицияләр уздыру милләттәшләребезнең халык традицияләрен яктырткан материаллар тупларга һәм тел, сөйләш үзенчәлекләре җәһәтеннән фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек тудырды.

Башкортстан Республикасында татар теленең ике диалекты вәкилләре яши: 1) урта диалектның бөре, златоуст, кормантау, тепекәй, турбаслы, учалы сөйләшләре; минзәлә сөйләшенең бәләбәй (бәл.), урта, яңавыл урынчылыклары; Түбән Кама керәшеннәре сөйләшенең бакалы урынчылыгы; 2) мишәр (көнбатыш) диалектының стәрлетамак (стрл.), байкыбаш сөйләшләре [Булатова, 2013, б. 3–4]. Без өйрәнгән Стәрлебаш җирлегенең татар авылларында урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгы һәм мишәр диалектының стәрлетамак сөйләше таралган.

Минзәлә сөйләше Татарстанның көнчыгыш (Әгерҗе, Бөгелмә, Зәй, Азнакай, Сарман, Баулы, Минзәлә, Мөслим, Әлмәт, Актаныш), Удмуртиянең Малая Пурга, Алнаш, Башкортстанның көнбатыш (Бишбүләк, Благовар, Борай, Бәләбәй, Дүртөйле, Илеш, Кырмаскалы, Краснокама, Кушнаренко, Миякә, Мәләвез, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Туймазы, Федоровка, Чакмагыш, Чишмә, Шаран, Янавыл, Әлшәй) районнарында таралган [Татар халык сөйләшләре, б. 212]. Бу сөйләшкә төрле елларда галимнәр (А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов, Л. Җәләй, А.А. Юлдашев, Л.Т. Мәхмүтова, Ә.Ш. Әфләтунов, Җ. Алмаз,

Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, Ф.С. Баязитова, Ф.Ю. Йосыпов, И.С. Насипов, М.Р. Булатова һ.б.) тарафыннан күзәтүләр ясала. Аны өйрәнүнең 100 елдан артык бай тарихы бар.

Минзәлә сөйләше таралган территориянең аерым төбәкләрендә яшәүче төркемнәрнең сөйләшендә, төрле факторлар (тарихи, мәдәни, географик һ.б.) йогынтысы астында, үзләренә хас үзенчәлекләр барлыкка килгән. Бу исә, үз чиратында, минзәлә сөйләшендә берничә урынчылыкны (әгерҗе, яңавыл, төп, бәләбәй урынчылыклары) аерып чыгарырга мөмкинлек бирә.

2010–2012, 2017 елгы экспедицияләр барышында Стәрлебаш районындагы Айдарәле, Бакый, Куганакбаш, Стәрлебаш, Тәтер-Арыслан, Тормай, Яңгырчы, Яшергән авыллары минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгына караганлыгы һәм Әмир, Бакча, Бузат, Гөлем, Карагыш, Көчегән (Өч-Әсән), Хәлекәй авыллары татарларының мишәр диалектының стәрлетамак сөйләшенә караганлыгы тагы да дәлилләнде.

Гомумән, бәләбәй урынчылыгы Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарында таралган. Җирле төрки халыкларның тыгыз аралашуы барышында минзәлә сөйләшенә хас төп үзенчәлекләрнең системалылыгы берникадәр дәрәҗәдә югалган. Мәсәлән, сакау *d* авазын, *-ай/-әй* дифтонгын куллану пассивлаша төшкән. Ә без өйрәнгән Стәрлебаш районы авылларында яшәүчеләр өчен сакау *d* авазын, *-ай/-әй* дифтонгын куллану хәзерге көндә бөтенләй хас түгел.

Стәрлетамак сөйләше дигәндә, Башкортстанның көньяк-көнбатышында таралган мишәр сөйләшләре күздә тотыла, Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы (Баулы районы) мишәр авыллары да шул төркемгә керәләр. Мишәрләрнең Урал тирәсенә күчүе 300 ел буена дәвам иткән. Яңа җирләрдә алар җирле халык һәм урта диалект вәкилләре белән тел-аралашу һәм тыгыз мәдәни-икътисади бәйләнешләр булдырганнар. Мондый үзара тәэсир итешү процессында урта диалект төп һәм хәлиткеч рольне уйнаган. Мишәр сөйләшләре, әйләнә-тирәдәге сөйләшләрнең йогынтысына дучар булу белән бергә, үзләренә генә хас үзенчәлекләрен дә саклап калганнар. Урта диалектка һәм мишәр диалектына хас үзенчәлекләрнең активлык дәрәҗәсе төрле җирдә төрлечә. Бу исә әлеге ике диалект вәкилләренең сан исәбе, аларның бирегә күчеп килү, ягъни бәйләнешкә керү вакыты белән турыдан-туры бәйләнгән.

Бәләбәй урынчылыгы һәм стәрлетамак сөйләшләре филология фәннәре докторы Д.Б. Рамазанова тарафыннан 1968–1975 елларда нигезле өйрәнелә. Галимәнең Башкортстан татарларының формалашуы, тарихи үсеше, тел үзенчәлекләре хакында архив материалларына таянып язылган монографиясе («Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии», 1984) һәм мәкаләләре басылып чыга.

Филология фәннәре докторы И.С. Насиповның «Древнетюркский пласт диалектной лексики мензелинского говора татарского

языка» (1994) дигән темага яклanган кандидатлык диссертациясендә дә бәләбәй урынчылыгында булган лексик берәмлекләр тикшерелә.

2010–2012 елларда минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы һәм стәрлетамак сөйләше, Башкортстанның көньяк өлешендә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен ареалогик аспектта өйрәнү барышында, әлеге мәкалә авторы М.Р. Булатова тарафыннан да тикшерелә, һәм кормантау, турбаслы, тепекәй, учалы һәм югарыда әйтелгән сөйләшләрдәге фонетик, морфологик үзенчәлекләрне тасвирлап «“Көньяк Башкортостан” ареалы татар сөйләшләрендә морфологик үзенчәлекләр» (2013) дип аталган темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Түбәндә татар теленең урта диалекты минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгы һәм мишәр диалекты стәрлетамак сөйләшләрендә күзәтелгән кайбер уртак морфологик үзенчәлекләр тәкъдим ителә. Мисаллар транскрипциядә бирелә.

**Исемнәр.** Сөйләшләргә кеше исемнәрен кыскарту хас: *Шәмәт* – әд. Шәмсетдин, *Хисамый* – Хисаметдин, *Кәлук* – Кәлимулла, *Гилмуш* – Гыйльмулла, *Исмай* – Исмәгыйль, *Дәрес* – Дәрессәләм, *Сорур* – Миңсорур.

Исемнәрнең иркәләү-кечерәйтү формалары, әдәби телдәгечә, *-кай/-кәй* кушымчалары белән ясала: *киленкәй, гөлкәйем* һ.б. Бу ике сөйләштә *-кай/-қай/-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы абстракт мәгънәле яки җансыз әйберләрне белдерә торган исемнәргә дә, сыйфатларга, ымлыкларга да ялганып килә. Мәсәлән: *Бу ағачқайым бик қарт инде* (бәл.). *Анда бик йыракай* (стрл).

*-қай/-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы, кешене белдерә торган сүзләргә, *нәрсә* һәм *нәстә* (диалекталь вариант) алмашлыгына ялганып килгәндә, эмоциональ-экспрессив мәгънәсен югалтырга да мөмкин: *Тағын бер хатынқаймы* (әд. хатын), *қызқаймы* (кыз) *бар иде* (бәл.). *Нәстәкәй* (нәрсә) *эшлисен әле?*(стрл.). *Урманнан бер нәрсәкәй дә алдыртмайлар* (бәл.).

Гомумән, *-қай/-кәй* кушымчасының мондый вазифаларны үтәве Башкортстанда яшәүче барлык татарларга да хас күренеш [Булатова, 2013, б. 85].

**Алмашлыклар**ның составы һәм төрләнеше буенча сөйләшләр, бер яктан, – мишәр диалекты, икенче яктан, күрше минзәлә һәм Урал төбәгенең башка сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә.

I һәм II зат алмашлыкларының юнәлеш килеше *миңа/ миңә/ мийа* (әд. миңа), *сиңа/сиңә/сийа* (әд. сиңа) вариантларында кулланыла: *Син давай өйлән шушы минем қызыма, мин сийа* (әд. сиңа) *усад'ба бирәм, дигән* (бәл.). *Сиңә* (сиңа) *күөзе теөшеп йеөрегән* (стрл).

Кыек килешләр катлаулы кушымчалар *(нарда/-нәрдә; -нарга/-нәргә, -нардан/-нәрдән)* белән ясала: *Төйәбез дә бәрәңге пешерәбез дә шунарга* (әд. шуңа) *салып бутыйбыз* (стрл.). *Шуннан хәзер анарга* (аңа), *өй күтәрткән-салган кешегә, барып йетә чират* (стрл.). Бәләбәй

урынчылыгында *ң*-варианты саклана: *аңа/ аңарга. Моңарга* (әд. моңа) *да сөйләрсең* (бәл.).

*Анау, монау* алмашлыклары килеш белән төрләнәләр, башка төрле кушымчалар да кабул итәләр: *Анауда* (әд. анда) *казлар күле* (стрл). *Монауның* (менә моның) *буйына шаршаулар эленә* (бәл.). *Анаусы* (әнә аныcы) *матур* (бәл.). *Утарлар йөри торган йулның монау* (бу) *йагында* (стрл.).

*Башта* **рәвеш**енең түбәндәге диалекталь формаларын куллану хас: стәрлетамак сөйләшендә – *тәү/тәүбаш/тәүрәк/тәүдәрәк/тәwендә/тәүдә/тәүге* (әд. башта); бәләбәй урынчылыгында – *тәүдә / иң тәү / тәү башлап* (башта). Мисаллар: *Тәүрәк* (әд. башта) *Бузат аwылына җиде кеше килеп утырган дип тә, кайсы биш кеше дип сүли* (стрл.). *Кем тәүдәрәк йасап бетер дип, йарышып шәлләрне бәйли идек* (стрл.). *Тәүдә өйгә нигез салалар оло абзыйлар* (бәл.).

**Фигыль** сүз төркеменең тәмамланмаган үткән заманы *-а + иде* конструкциясе ярдәмендә белдерелә, *иде* ярдәмче фигыле мишәр диалектындагыча да *(иде),* урта диалекттагыча да *(ийе)* әйтелә. I зат – *бара идем / барайым.* II зат – *бара + йдең / барайың.* Мисаллар: *Боламык пешерәләр иде. Син дә аны күргән идең.* һ.б.

*-адыр/-әдер иде* формасы да Стәрлебаш татарларында актив кулланыла: *Элек пәҗине* (киндер үсемлеге) *әниләр чәчәдер иде* (стрл.). *Кендек әбиләрен чакырадырыйык* (стрл.). *Аулаҡ өйләрдә йырлашып утырадырыйыҡ* (бәл.).

Хәл фигыльнең әдәби *-мый/-ми, -мыйча/-мичә* кушымчалы юклык формасы белән беррәттән, бәләбәй урынчылыгында – *-мый/-май/-ми, -мыйынчы/-майынчы, -мийенче/-мәйенче, -мыйчы/-миче/-мәйче, -мыйча/-мичә*; стәрлетамак сөйләшендә *-мыйчы/-миче, -мыйнчы/-минче, -мыйчак/-мичәк, -мыйчан/-мичән, -мастан/-мәстән* формалары да кулланыла: *Шул йылны чыгып киттем, укырга бармастан* (әд. бармыйча) *качып* (стрл.). *Миңә әйтмийенче* (әйтмичә) *эшләмә* (бәл.). *Картәни килмичәк* (килмичә) *башламыйбыз* (стрл.).

*-ганчы/-гәнче* кушымчалы хәл фигыль мәгънә төсмерләре ягыннан әдәби телдән аерылмый. Бәләбәй урынчылыгында бу форма актив кулланыла: *Менә шулай җилкәдәге чәчме ҡойолғанчы бала йылый икән дип әйтәләр* (бәл). *Ҡызыл төскә кергәнче ҡайнатабыз эремчекне* (бәл).

Стәрлетамак сөйләшендә *-ганчы/-гәнче* кушымчалы хәл фигыльнең берничә төрле варианты бар: *-гынчы/-генче* (төп вариант, иң киң кулланылышта), *-ганчыга/-гәнчегә/-к(г)ынчыга/ -к(г)енчегә, -г(к)ынчык/-г(к)енчек, -г(к)ычак, -к(г)ынча/ -к(г)енчә, -кынча/-гинча, -кинчы/-кинче/-гинчы/-гинче* + бәйлек һ.б. Мәсәлән: *Таң аткынчы* (әд. атканчы) *сүли ул. Картәни-картәти үлгенчек* (әд. үлгәнче) *кийәүгә чыктым. Унынчы классны укыгынчыга хәтле шәлләр ты°тып эш белән җийналабыз. Мин белгенчегә хәтле Фатыймә әбинең алты почмаклы өйөндә йома укыдылар.*

*-гач* кушымчалы хәл фигыль дә, нигездә, төрле вариантлары

булу белән генә әдәби формадан аерыла. Бәләбәй урынчылыгында: *-ғачтын/-гәчтен, -ғачтан/-гәчтән* (сирәк). Мәсәлән: *Мәктәптә уқый башлағачтын* (әд. укый башлагач) *башақ җыйарға йөридерейек басуларға* (бәл.). Стәрлетамак сөйләшендә: *-гач/-гәч, -гачтын/-гәчтен,-гачтан/-гәчтән, -гачтин/-гәчтин, -гачын/-гәчен, -гачыннан/-гәченнән.* Мәсәлән: *Урлап алып килгәчтен* (әд. килгәч), *мулла алып килеп никах укыттылар* (стрл.). *Шунан күрше аwылга йөрөп укырга суwык булгачын* (булгач), *анда бүтән йөрмәдем* (стрл.).

Стәрлебаш татарларында урын-араны һәм вакытны белдерә торган *алып* **бәйлек сүзе** актив, әмма ул стәрлетамак сөйләшендә *ала* һәм бәләбәй урынчылыгында *алата* вариантларында кулланыла, һәм чыгыш килешен башкара: *Шушы сызыктан ала* (әд. алып) *теге растойанийегә таш куйыла* (стрл.). *Тегеннән алата* (алып) *йөгөреп килде* (бәл.). *Шуннан алата көтү көтә* (бәл.).

Чагыштыр: татар теленең урта диалекты кормантау сөйләшендә *алта* варианты күзәтелә: *Эш буйынса килдегезме шуннан алта?* [Булатова, 2016, б. 167–168].

Мисаллардан күренгәнчә, төп грамматик категорияләр, аларның ясалышы һәм семантик функцияләре ягыннан минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы һәм стәрлетамак сөйләше татар әдәби теленнән аерылмый; әмма, шуның белән бергә, бу сөйләшләргә генә хас булган үзенчәлекләр, формалар да бихисап табыла.

Түбәндә экспедицияләр вакытында Стәрлебаш татарларыннан язып алынган, фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләрне һәм халык традицияләрен чагылдырган материаллар бирелә. Сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә күрсәтелә: *я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз һәм [қ], [ғ] (бәләбәй урынчылыгында) – тирән тел арты тартык авазлары кулланылды.

**Мишәр диалектының стәрлетамак сөйләшенә карый торган текст үрнәге:**

**Аш-су.** Аwылда ләwәш, пирәмәч, кыстыбый, пирүгләр, күмәч (*ак икмәк*), әпәй (*арыш икмәге*), баwырсаклар пешерәдерейек. Сугыш башлангачтын (*башлангач*), атна (*гел*) балтырган белән йәшәдек. Безнең картәтийең (*дәү әтиең*) эшчән кеше иде. Балтырганны, урманга барып, капчыклап җийалар иде. Күтәрәлмәслек хәлдә апкайтасың инде. Җәй чыкса, тамак туйа. Кеᵉз җиткенчек (*җиткәнче*), башак-мазарын, теᵉрлесен җийып. Кышкылыкка запас инде әзерәк. Кырда балтырган, каз тәпәйе (*казаяк*), кымызлык, гырлафа (*какы*), кәккүк тәпәйе (*каз үләне*), кузгалак үсә.

Мәләшләр (*миләшләр*), маланнар (*баланнар*) үсә бакчада. Кайнатып түгел, алар эссе (*кайнар*) суда монауның (*менә моның*) кебек саргылт теᵉскә керә. Йарты стакан гына су саласың кеᵉймәскә. Шунан суwытасың да иләктән сөзәсең. Сөзмәсе чыга. Тешен (*төшен*) ташлыйсың.

Сөзмәгә берничә кашык кына писук бутыйсың. Шунан эссе утта әз генә йылытып аласың. Кайнатмыйсың. Берничә бутап аласың, йылытмыйча. Писук эреп бетә, шунан шишага (*шешәгә, банкага*) тутырып куйасың (*2017 елгы экспедиция вакытында Стәрлебаш районы Хәлекәй авылында Мугаттарова Хәтимә Зәйнулла кызыннан (1935 елда туган) язып алынды).*

**Урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгына карый торган текст үрнәкләре:**

**Кул эшләре.** Кич утырып шәл бәйлидерийек. Бер көндә бер шәл бетәдерейе. Дүрт кыз чит бәйлидерийе. Ике кыз урта бәйлидерийе. Әбит (< рус. *обед*) wақытында кереп утырадырыйық, таң атқачтын (*таң аткач*), кайтып китәдерейек. Шәлне сатадырыйық.

Қарағa (рус. *чернила*) – имәннең йафрағы астында йәбешкән алмасы була, шуны алып, шуңа тутыққан қадақ саладырыйық (ржавчина, ржа получайытса иде) та шуннан ул бәскә (рус. *коричневый*) әйләнәдерейе. Шунарға манып йазадырыйық. Ул бетми. Имән қайырысын қайнатсан да әйбердән бетми бит. Шулай да йазасы булған инде. Қоромнан да йасыйдырыйық қараны. Қоромға әз генә май саладырыйық та. Қазан төбөнә йәбешәдерейе қором. Шуны аладырыйық та, шуның белән йазадырыйық (*2017 елгы экспедиция вакытында Стәрлебаш районы Яңгырчы авылында Кәримова Кәримә Лотфурахман кызыннан (1938 елда туган) язып алынды).*

**Туй йоласы**. ***Сөлге сорау.*** Қызның этисе йегетнең этисенә қулына сөлгө тапшыра. Сөлге чигелгән була. Сөлгөне тотоп тора, өстөнә теге йақ ақча сала. Ақча салғачтын (*салгач*), сөлгө тегеләргә була, ақча қыз йағына. Бу ризалашу була инде. Сөлгегә килгәчтен (*килгәч*), бөтөн нәрсә сөйләшелә – қайсы көннө никах билгеләргә, қайсы көннө туй уздырырга. Ничә пар бар. Йегет йағына биш пар барса, қыз йағына бер пар артық булырға тийеш булған. Алты пар. Туй тәүдә (*башта*) қыз йағында, аннан кийәү йағында. Сөлгө бирәсең икән, димәк, ризалық биргәнсең.

***Сөлге күрергә килү.*** Қыздан алып қайтқачтын, йегет өйөндә сөлгене түр башына элеп қуйалар. Күрше-тирә, туған-тумача килеп, кем күчтәнәч алып килә, кем ақча алып килә. Сөлге йанына. Ул йәшләрдә була. Сөлгөне алып қайтучылар – йегетнең эти-әниләре – туған-тумачасын җийнарға мөмкин. Сөлге күрегә (*күрергә*) дип.

***Кызлар ябу.*** Ниқахтан соң туйға қәдәр, кийәү булған кеше қыз йанында торорға тийеш. Ике атна. Қызлар йабу дигән әйбер бар. Келәткә. Ә хәзер өйгә. Айырым өйгә йабасың да, алар шунда төн йоқлыйлар. Иртән иртүк торалар да, аларга аwыл балалары бүләк алырға киләләр. Кем килә, кийәү бүләк әзерли. Малайларға пәке, қызларға нәрсә булса да йарый. Иртәнчәк (*иртән*), алар мунчаға киткәнче, балалар бүләккә баралар.

***Кияү мунчасы***. Қыз йағында кийәү мунчасы йағалар. Қодалар қунмадылар. Төннә қыз белән

кийәүне йабып ҡайтып киттеләр. Ҡыз белән кийәү йоҡодан торуға тегеләр кире килеп җиттеләр. Бездә мунча керергә апарғанда (*алып барганда*), ҡыш булса, чана белән, җәй булса – арба белән аппаралар. Хәзер мунча йаҡҡан кеше түгел, кем мунча кергән, шул себерке астына аҡча калдыра.

***Бирнә.*** Йоласы шулай – сандыҡны кийәү китерегә тийеш. Алдан китереп бирә дә, син тутырып итергә (*илтергә*) тийешсең.

Элеккечә ашны ҡодалар бер көн алдан китереп ҡуйдылар. Ике эпәй, ике пирог, ҡазны алдан китереп ҡуйдылар да.

***Су юлына төшү.*** Теге йаҡҡа килен булып төшкәчтен (*төшкәч*), безнеңчә су йулына төштөләр. Су йулында без чиккән алйапкычлар әзерләгән ийек. Һәрберсесенә (*һәрберсенә*) минем ҡызыҡай (*кыз*) чиккән алйапкыч таратты. Элек дүртәр көн туй үткәрмийенчә (*үткәрмичә*) туктамаганнар (*2011 елгы экспедиция вакытында Стәрлебаш районы Куганакбаш авылында Яхина Хәкимә Тимерхан кызыннан (1961 елда туган) язып алынды).*

**Мәзәк.** Бер бабай урманға барған. Утын төйәргә. Элек бит ҡоро ботаҡны да сындыртмыйларыйы. Бер нәрсәкәй (әд. *нәрсә*) дә алдыртмайлар. Балтасы да булған. Ҡоро ботаҡлар төйәгән. Төйәгән ботаҡларны Стәрлебаштан лесник килгән дә колхоз йортона бушаттырған. «Фамилийаңны әйт!» – дигән. Теге: «Кылғанов», – дигән. «Исемең?». «Шылған», дип йаwаплаған. «Шылған, иртәгә килмичәк (*килмичә*) калма, ыштраф салабыз, балтаңны шуннан алырсың», – дигән. Шуннан чаҡырталар икән Ҡылғанов Шылғанны. Ә андый йуҡ. Ҡылған бит шуып тора. Элеккеләр шулай шәп булған инде (*2017 елгы экспедиция вакытында Стәрлебаш районы Яңгырчы авылында Кәримова Кәримә Лотфурахман кызыннан (1938 елда туган) язып алынды).*

**Әдәбият**

*Булатова М.Р.* Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань: ИЯЛИ. 2013. 240 с.

*Булатова М.Р.* Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте. Казань: Магариф – Вакыт, 2016. 384 с.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Казан: Мәгариф, 2008. I китап. 463 б.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*К.М. Миңнуллин*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНЫҢ 8 ТОМЛЫГЫН ӘЗЕРЛӘҮ ТӘҖРИБӘСЕ

Одной из насущных задач современного татарского литературоведения выступает осмысление национального литературного процесса. В рамках подготовки 8-томной «Истории татарской литературы» учеными Татарстана была предложена новая концепция и актуализирована типология литературного процесса, особенно XIX столетия и XX века, путем выявления общих и особенных черт на уровне метода, стилевого сходства и т.п.

**Ключевые слова:** татарская литература, национальное сознание, история литературы, национальная литература, литературный процесс.

Һәр халыкның үз әдәбияты тарихын булдырырга омтылуы табигый. Чөнки ул – мәдәни һәм гыйльми үсеш күрсәткече. Татарларда милли әдәбият тарихын өйрәнүнең мөһимлеге XX гасыр башында көнүзәк мәсьәләләрнең берсенә әйләнә. Әмма тупланган тәҗрибә фәкать 1920–1930 елларда гына системалаша: татар әдәбияты тарихы мөстәкыйль фән булып формалашып җитә [Гилазова, 23]. Бу юнәлештә Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъдиләр эшчәнлеге хәлиткеч роль уйный. Аларның татар әдәбияты тарихына кагылышлы хезмәтләре ТАССР Мәгариф Халык комиссариаты карамагындагы Академик үзәк җитәкчелегендә, академик дәрәҗәдә языла, ул традицияләр, Татарстанда Тел, әдәбият һәм тарих институты оешкач, академик басмалар әзерләү юлы белән татар әдәбияты тарихы фәнен үстерү кебек дәвам иттерелә. Үз чиратында, мондый хезмәтләр мәктәпләргә һәм югары уку йортларына дәреслек-ярдәмлекләр әзерләү, мәдәният мәсьәләләре белән шөгыльләнүче даирәләргә һәм киң җәмәгатьчелеккә әдәбиятка кагылышлы белем-мәгълүматларны җиткерү һәм популярлаштыру өчен чыганак хезмәтен үти. Совет чорында татар әдәбияты тарихының томнары берничә тапкыр яңартыла. 1984–1989 һәм 2001 елларда дөнья күргән 6 томлык шушы юнәлештә башкарылган хезмәтләрнең соңгысы була.

Совет заманының идеологик чикләүләре алып ташлану 6 томлыкның, әле тулысынча нәшер ителеп беткәнче үк, «искерүенә» сәбәп була. Җәмгыятьтәге үзгәртеп корулар татар әдәбияты тарихын бөтенләй үзгә нигезләрдә, яңадан әзерләүне көн тәртибенә куя. Нәтиҗәдә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибрагимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Татар әдәбияты тарихы»ның 8 томлыгын өр-яңадан язу турында карар өлгерә.

Мондый зур күләмле проектны гамәлгә ашыру төгәлләнмәгән булса да, бүген без аның татар әдәбият белемен яңа этапка алып чыгуын күрәбез. 8 томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның яңалыгы, барыннан да элек, XIX һәм XX гасырлар татар әдәбияты үсешенә йогынты ясаган шартларны, заман рухына һәм таләпләренә җавап бирә торган идеяләрне билгеләүдән, шулар аша әдәби барышка, чорлар әдәбиятына, аерым язучылар иҗатына тулы һәм әдәби-эстетик кыйммәтенә нигезләнеп анализ ясаудан, бәя бирүдән гыйбарәт.

Сигезтомлыкның Борынгы һәм Урта гасырлар төрки-татар әдәбияты тарихына кагылышлы өлеше методологик яктан татар галимнәренең үткән чорлардагы классик хезмәтләренә таяна. Борынгы заманнан башлап XIX гасырның беренче яртысына кадәр төрки-татар мәдәнияте тарихын тәртипкә салган һәм төркемләгән Г. Гобәйдуллин һәм Г. Рәхим хезмәтләрендә [Рәхим, Газиз, 1922; 1923; 1924; 1925] 1920–1930 елларда ук бик мөһим концептуаль юнәлешләр билгеләнгән була. Алар татар әдәбиятын Урта гасыр язма традицияләре белән баетылып үскән төрки-мөселман мәдәниятенең бердәм мирасы эчендә өйрәнергә тәкъдим итәләр. Милли тамырларны барлап, галимнәр иҗади аңның иң борынгы катламнарына төшәләр, уртак әдәби барышта Гомумтөрки дәверне, Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларын аерып, татар әдәбиятында уртагасырчылык баскычы XIX гасыр ахырына кадәр дәвам итә дип күрсәтәләр. Икенче чорның башлануы алар тарафыннан XVIII гасыр ахырында калкулanган татар мәгърифәтчеләре эшчәнлеге белән аңлатыла [Рәхим, Газиз, 1924].

Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллин фикеренчә, Урта гасырлар төрки әдәбияты төрле җирлекләрдә яшәгән этник төркемнәр тарафыннан барлыкка китерелә, әмма алардагы уртак мотивлар, сюжетлар, образлар, тармакланып үскән агач кәүсәседәй, уртак әдәби традицияләрнең нигезен тәшкил итә.

Шул рәвешле, 1920 елларга татарларда Борынгы һәм Урта гасыр төрки-татар әдәбиятының тарихы концептуаль яктан төзек системасы эшләнә. Шул ук вакытта, идеологик таләпләрдән чыгып, ул концепциягә үзгәрешләр кертү омтылышлары да күзәтелә. Мәсәлән, Г. Ибраһимов хезмәтләрендә дәверләрнең тарихи чиге Казан ханлыгының басып алынуы белән бәйләп шәрехләнә һәм ул Көнчыгыш Россия мөселманнарының кадимчелек чоры («Кадим Шәрык Русия мөселманлыгы дәвере») дип атала. Әлеге позициянең нигезе булып сыйнфый мөнәсәбәтләр, ягъни феодализм, капитализм, социализм-коммунизм дәверләре алмашыну санала [Ибраһимов].

Мондый сәясиләштерүләр булуга карамастан, академик фәндә һәм гамәли тикшеренүләрдә Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллинның Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятын дәверләргә бүлү тәгълиматы, вакыт сынавын узып, инде бер гасыр төп чыганак булып хезмәт итә. Татар

әдәбияты тарихын тикшерүнең яңа проекты – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибрагимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан тәкъдим ителгән «Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгының беренче китаплары да алар күзаллавына таянып әзерләнә. Беренче томда гомумтөрки әдәбият, ислам дине үтеп керү белән бәйле үзгәрешләр (V–XII гасырлар) күрсәтелә, татар әдәбиятының Болгар (XII гасыр – XIII гасырларның беренче яртысы) һәм Алтын Урда (XIII гасырның икенче яртысы – XV гасырның беренче яртысы) чорлары аерым карала [Татар әдәбияты тарихы, I т., 2014]. Икенче томда Казан ханлыгы дәвере (XV гасырның икенче яртысы – XVI гасырның беренче яртысы) һәм XVI–XVIII гасырлар татар әдәбияты яктыртыла [Татар әдәбияты тарихы, II т., 2014].

Әмма татар әдәбияты тарихының соңгырак дәверләрен өйрәнү өчен башкача якын килү юлларын эзләү таләп ителә. Чөнки 1930 еллардан башлап рус әдәбияты тарихчылары гына түгел, СССРдагы башка милли әдәбият белгечләре өчен дә бу өлкәдә төп һәм бердәнбер юнәлеш Мәскәү күрсәткәнчә билгеләнеп килә. Татар әдәби барышы исә, иҗтимагый мөнәсәбәтләр алышынуга бәйле рәвештә, түбәндәге чорларга бүленә: 1. Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты; 2. XIX гасыр татар әдәбияты; 3. XX гасыр башы әдәбияты; 4. Татар совет әдәбияты [Миннегулов; 26]. Бу чылбырдагы XIX гасыр татар әдәбияты тарихы гамәлдәге рус әдәбияты тарихы үрнәгендә языла. Дини-суфичылык әсәрләренең үзенчәлегенә, аларның шул чор әдәби барышындагы урыннарына аерым игътибар бирелми. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты формалашу вакыты дип XIX гасырның я беренче яртысы (хәтта чиреге), яки беренче еллары күрсәтелә. Сигезтомлыкның III томында мондый методологик ялгышлар төзәтелә, XIX гасыр татар мәдәнияте Көнчыгыш Яңарышының һәм Көнбатыш үрнәгендәге мәгърифәтчелек хәрәкәтенең үзара йогынты ясау мәйданы кебек шәрехләнә. XIX гасырның беренче яртысын (1800–1860) үзгәрешләр дәвере кебек аеру, XIX гасырның икенче яртысы (1861–1905) татар җәмгыятендә мәгърифәтчелек фикерләре ояну, иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә үтеп керү һәм XIX гасырның соңгы елларында дөньяви рухтагы татар мәгърифәтчелек әдәбияты формалашу [Татар әдәбияты тарихы, III т., 2015] татар мәдәнияте һәм татар әдәбияты тарихының XIX гасырдагы тулы сурәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Алдагы этапны – XX гасыр башын тикшерү мәсьәләсендә хәл башкача була. Күренекле галим Г. Сәгъди 1926 елда ук инде бу чорны яңа дөньяви татар әдәбияты барлыкка килү һәм аның Көнбатыштагыча реализм, романтизм, модернизм кебек матур әдәбият методларына нигезләнеп зур тизлек белән үсеш алу вакыты дип билгели [Сәгъди, 1926]. Зур булмаган әлеге дәвердә татар әдәбиятының эчтәлеге һәм төзелешендәге

үзгәрешләр шулкадәр әһәмиятле була, хәтта әдәбият белемендә марксистик-ленинчыл эстетика урнашкан елларда да XX гасыр башын мөстәкыйль дәвер буларак аерып карау зарурлыгы фәндә бәхәс уятмый. Әдәбият белемендә болай якын килүләр М. Гайнуллинның «XX йөз башы (1917 елга кадәр) татар әдәбияты» (1947, 1954 елларда басылып чыга), Г. Халитның «XX йөз башында татар әдәбияты» (1954 елда нәшер ителә), И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1966 елда басылып чыга) хезмәтләрендә ныгытыла.

Әлбәттә, әлеге чорны өйрәнүдә идеологик тайпылышлар да очрый: татар әдәбиятының әзер теоретик калыпка яраклаштырылып, «мәгърифәтчелек реализмы – тәнкыйди реализм – социалистик реализм» чылбыры буенча үсеш алуы; романтизм белән бәйле тәҗрибәләрнең уңышсызлыгы (төшенкелекле, декадентлык әдәбияты) турындагы фикерләр шундыйлардан. Марксизм үлчәмнәренә туры килмәгән һәр нәрсә – автор биографиясе булсынмы ул, яки әдәби әсәр эчтәлегеме – әдәбият тарихыннан сызып ташлана. Татар укучысына, мәсәлән, XX гасыр башының Гаяз Исхакый кебек күренекле прозаиклары хакында мәгълүмат бирелми. Дини-рухани (суфи) поэзия дә рәсми өйрәнелми, әсәрләр дөньяви эчтәлеккә җайлаштырып тикшерелә. 1920–1930 елларда иҗат ителгән альтернатив характерлы, Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай» повесте кебек әсәрләр әдәби барыштан төшереп калдырыла. Кайбер текстлар, эстетик яктан камил саналмаса да, эчтәлеге идеологик таләпләргә җавап биргәнгә күрә, иң яхшы үрнәкләр кебек тәкъдим ителә. Асылда, 1917 елга кадәрге татар әдәбияты укучыларга татарларның көндәлек авыр, караңгы тормышын чагылдыручы дип аңлатыла башлый.

Сигезтомлыкның IV томында бу тайпылышлар төзәтелде, XX гасыр башы татар әдәбиятының Европа һәм рус мәдәниятенә йөз тотып, Көнчыгыш традицияләре синтезына нигезләнеп үсеш алган алтын дәвере, романтизм һәм реализм чәчәк аткан, модернизм формалаша башлаган вакыт буларак тикшерелде [Татар әдәбияты тарихы, IV т., 2016].

Татар совет әдәбияты тарихын язу иң катлаулысы булып чыкты. Әдәбият белемендә озак вакытлар «совет әдәбияты» төшенчәсе 1917 елдан соңгы дәверне үз эченә алып, милли әдәбиятларны өйрәнү һәм бәяләүнең үрнәге санала. 1920–1930 еллар, мәсәлән, рухланып коммунизм төзү вакыты, ә шушы чор әдәбияты әнә шул процессларның көзгесе дип атала. Иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга нигезләнеп, ул түбәндәге хронологик этапларга бүленә: 1920 еллар әдәбияты; 1930 еллар әдәбияты; сугыштан соңгы (1945–1953) еллар әдәбияты һ.б.

Үзгәртеп кору елларында совет чоры татар әдәбияты тарихының шул еллар рус әдәбияты үсеше белән тәңгәл булмавы ачыклана. Мәсәлән, XX гасыр башында яңа эчтәлек һәм формалар эзләү мәйданчы-

гына әйләнгән татар әдәбияты 1920–1930 елларда сәяси һәм идеологик факторлар басымы астында кала, әмма анда электән килгән, халык иҗаты һәм классик әдәбият традицияләрен саклау, модернизмны үстерү, альтернатив әдәбият тудыру, шулай ук традицияләрен яңарту омтылышы саклана.

XXI гасыр башында болар хакында ачыктан-ачык сөйләргә мөмкинлек туды. Сигезтомлыкның V томында төрле сәбәпләр белән укучылардан «яшерелгән» шагыйрьләр һәм прозаикларның мирасы фәнни әйләнешкә кертелде, аларның кызыл идеология басымына дучар ителгән иҗатларын һәм, Октябрь инкыйлабы гына түгел, шәхес культы, Бөек Ватан сугышы, коллективлаштыру, интернациональләштерү, руслаштыру нәтиҗәләрен дә тирәнтен өйрәнеп бәяләү башкарылды. 1917–1956 еллар татар әдәбияты беренче мәртәбә советчыл чикләүләрдән арындырып анализланды [Татар әдәбияты тарихы, V т., 2017]. Ул тарихи тетрәнүләр тегермәненә эләккән, әмма аннан котылу юлы таба алмаган кешенең, җәмгыятьнең, милли бердәмлекнең кичерешләрен һәм фаҗигасен бөтен тулылыгы белән укучыга күрсәтергә омтылган әдәбият булып күзалланды. Милли мәнфәгатьләрне үзәккә куйган шагыйрьләр һәм язучылар, чит илләргә китәргә мәҗбүр булган талантлар иҗатына аеруча зур игътибар юнәлтелде, шулай ук бу чор әдәбияты татар халкының дини-фәлсәфи һәм әдәби-эстетик фикерләве контекстында каралды.

Хәзерге рус әдәбияты тарихы «җепшеклек» (1953–1968 еллар) чорына, соцреализм кануны торгынлык кичергән яки «кырау төшү» этабына (1968–1986 еллар) һәм XX–XXI гасырлар чигенә бүлеп өйрәнелә. Татар әдәбиятына нисбәтән бу бүленеш сәяси генә түгел, ә эчке әдәби үзгәрешләр белән дә бәйле була. Әйтик, 1960 еллар татар әдәбиятында милли нигезләргә әйләнеп кайту, барыннан да бигрәк, эстетик бурычларны хәл итү, шулай ук совет җәмгыятенең иҗтимагый, әхлакый, сәяси проблемаларын калкыту максаты белән милли әдәби традицияләрне торгызу башлана. Сүз сәнгате күзлегеннән караганда, татар әдәбиятында классик романтизм белән реализм, модернистик агымнар яңара [Зәһидуллина, 2015]. Бүген институтта «Татар әдәбияты тарихы»ның VI томын (1956–1985 елларны эченә ала) шушы күзаллау кысаларында язу эше төгәлләнде. XX гасыр ахыры һәм XXI гасыр башы татар әдәбиятына багышланган ике том исә якындагы ике елда нәшер ителәчәк.

Шулай итеп, хәзерге татар әдәбияты белеменең иң мөһим бурычы – милли әдәби барышны мөмкин кадәр дөрес итеп чагылдыру. Татар әдәбияты тарихының сигезтомлыгын әзерләү барышында Татарстан галимнәре тарафыннан шушы бурычны хәл итүгә юнәлтелгән концепция тәкъдим ителде, ул, үз чиратында, әдәби барышка, аеруча XIX йөз һәм XX гасыр әдәбиятына карашны тамырдан үзгәртте.

Мәгълүм булганча, әдәбият үсешендә төп рольне тышкы һәм

эчке факторлар уйный. Милли әдәбиятларны тикшерүдә игътибар озак вакытлар дәвамында тышкы факторларга, ягъни ил эчендәге тарихи, икътисади, иҗтимагый, сәяси процессларга юнәлтелде. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең яңа концепциясе әдәбиятның эчке (имманент) факторларына таяна. Бу факторларга эстетик камиллек, әдәбиятның фольклор, дин, фәлсәфә белән мөнәсәбәтләре һәм милли аңга тәэсир итүче иҗтимагый фикер, этнология һ.б. күренешләр карый.

Яңа концепция татар әдәбиятына бөтенлекле һәм эчке үсеш-үзгәреш закончалыкларына нигезләнеп якын килүне күздә тота, монда факторларны һәм күренешләрне сайлап алу милли үзенчәлекләргә буйсындырыла, ә игътибар объекты булып әдәбиятның үсеш-үзгәрешенә зур өлеш керткән язучылар һәм шагыйрьләр иҗаты сайлана. Мондый юл милли әдәбият тарихын – этник үзаң, дөньяны танып белү тарихы буларак карарга, аны традицияләрнең буыннан буынга күчешенә бәйләп һәм милли иҗади фикерләүдәге яңарыштан чыгып бәяләргә мөмкинлек бирә. Болай якын килү әдәби ачышларны, яңалыкны, сүз сәнгате осталарының үз язу стилен күрергә ярдәм итә.

**Әдәбият**

*Гилазова Ч.М.* Проблемы литературоведения в историко-литературном наследии Г. Сагди: автореф. дис.... канд. филол. наук. Казань, 2006. 23 с.

*Заһидуллина Д.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Ибраһимов Г.* Татар әдәбиятында өченче дәвер. Аңларга тырышыгыз! // Безнең байрак. 1923. 23 апрель.

*Миннегулов Х.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. С. 26.

*Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд. Борынгы дәвер. III бүлек. 17, 18, 19 гасырда иске әдәбият. Казан, 1922. 186 б.

*Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд. Борынгы дәвер. II бүлек. Казан, 1923. 244 б.

*Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Беренче җилд. Борынгы дәвер. I бүлек. Казан, 1924. 174 б.

*Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы: феодализм дәвере. II басма. Казан, 1925. – 316 б.

*Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Беренче җилд. Борынгы дәвер. III бүлек. Мәдхәл. Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комб., 1924.

*Сәгъди Г.Г.* Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926. – 300 б.

*Султанов К.* Национальное самосознание и ценностные ориентации литературы. М.: ИМЛИ РАН, «Наследие», 2001.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. I т.: Борынгы чор һәм урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 415 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. II т.: XV–XVIII гасырлар / фәнни мөх. Х.Й. Миңнегулов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 471 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. III т.: XIX йөз / фәнни мөх. Ф.Г. Галимуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 551 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. IV т.: XX йөз башы / фәнни мөх. Р.К. Ганиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 533 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. V т.: 1917–1956 еллар / фәнни мөх. Д.Ф.Заһидуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 623 б.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

УДК 821.512.145

*Г.М. Ханнанова*

# Г. ТУКАЙНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ЛИРИКАСЫНДА МАТБУГАТ ТЕМАСЫ: ТӨП МОТИВЛАР ҺӘМ ЖАНР ТӨРЛӘРЕ

Одной из основных проблем современного тукаеведения – классификация и анализ мотивов творчества Г. Тукая. В статье рассматривается формирование Г. Тукая как поэта, темы и мотивы, нашедшие освещение в раннем периоде его творчества. В лирике Тукая уральского периода прослеживается тема периодической печати. Это связано с журналистской деятельностью поэта и его общественной позицией. В связи с этим на первый план в его лирике выходят мотивы развития национальной прессы, необходимости прогресса нации, просвещения нации, национального единения.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, татарская периодическая печать, тукаеведение, темы и мотивы лирики Г. Тукая.

Бүгенге көндә Г. Тукайны өйрәнү фәнендәге проблемаларның берсе – аның иҗатындагы мотивларны классификацияләү һәм шул мотив төрләренә анализ ясау.

Тукай иҗатын өйрәнүче әдәбият галиме Д.Ф. Заһидуллина шагыйрь шигъриятендәге төп мотивлар турында: «Тукай иҗатында әйдәп баручы мотивлар халык яшәешен, шул чор татар җәмгыятенең көнитешен тулысынча колачлап ала. Шуның белән бергә, алар бер лейтмотив – халык язмышы, милләткә хезмәт итү мотивы тирәсенә җыела» [Заһидуллина, б. 23], – дип яза.

XIX йөзнең икенче яртысы һәм XX йөз башы – татар халкының уяну, милләт буларак формалашу, милли азатлык өчен көрәш чоры. Бу чорга милли аң уяну, әдәбиятта, сәнгатьтә милли идеяләргә игътибар арту, милли мәсьәләләрнең һәм милләткә мәхәббәт тойгыларының үзәктә булуы хас.

Белгәнебезчә, Г. Тукай шагыйрь буларак Уральскида (Җаекта) формалаша башлый. Әдипнең иҗади үсешенә дә, шәхес буларак җитлегүенә дә Уральск, аның даирәсе, анда барган иҗтимагый процесслар зур йогынты ясый. Монда ул шигърияттә дә, журналистикада да беренче адымнарын атлый. Уральскида татар матбугаты оешу тарихы, бу эшкә Г. Тукайның керткән өлеше һәм аның бу чордагы журналистлык эшчәнлеге Г. Халит, М. Гайнуллин, И. Нуруллин, Ф. Әгъзамов, Ү. Гыймадиев, Ф. Яхин һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртылган [Халит, 1956; Халит, 1966; Гайнуллин; Нуруллин; Әгъзамов; Гыймадиев; Яхин, 1992].

Г. Тукайның иҗади үсешенә шул чорның алдынгы мәдрәсәләреннән саналган «Мотыйгыя»дә, рус сыйныфларында Әхмәтша Сираҗетдиновтан белем алуы, К. Төхфәтуллин оештырган газета һәм журналларда

(«Фикер», «Әлгасрелҗәдит», «Уклар») эшләве ярдәм итә.

Билгеле булганча, чит илләрдә белем туплаган К. Мотыйгый, Уральскига кайтып, әтисе Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укыту белән генә чикләнмичә, татар вакытлы матбугаты булдыруга керешә һәм шул эшкә мәдрәсәдә укыган һәм шигъриятькә һәвәслеген күрсәткән Тукайны да тарта. Г. Тукай 1903–1904 елларда мәдрәсә шәкертләре белән кулъязма рәвешендәге «Мәгариф» газетасы һәм «Әлгасрелҗәдид» журналы чыгаруда катнаша. Биредә шагыйрьнең тәүге шигырьләре дөнья күрә: «Әхмәтсафа әфәнде – фазыйль әдибдер кәнде...» (1904), «Тугъды, көн тугар кеби, бер сахибе һиммәт гани...» (1904). Соңыннан, хөкүмәт органнары ризалыгы белән «Әлгасрелҗәдид», «Фикер», «Уклар» газета һәм журналлары нәшер ителә башлагач, әлеге басма матбугат органнарында төрле вазифалар башкара*.

Әлбәттә, Г. Тукайның газета-журналлардагы эшчәнлеге аның иҗатында да чагылыш таба: беренчедән, тема конкретлаштырылып, аерым татар газета-журналларына һәм аларны нәшер итүчеләргә юнәлтелгән шигырьләре – «Чөнанча бездә...» (1905), «Шигырь» (1905), «Мөхәрриргә» (1906), «“Фикер” газетасына гына махсус түгел» (1906), «“Уклар” журналында мөхбир уланлара тәнбиһ» (1906) һ.б. языла; икенчедән, лирикасында бер мотив төре буларак, газета һәм журналлар чыгаруның милләтне тәрәккый итүдәге роле күрсәтелә.

Алда әйтеп үтелгәнчә, мәйданга чыккан татар газета-журналлары һәм башка халыклар матбугаты, аларның әһәмияте, халыкны агартуда уйнаган роле, вакытлы матбугатны тудыруда күп көч куйган асыл затларны мактау, аларга мәдхия – Тукайның Уральск чоры шигъриятендә шактый чагылыш таба, иҗатының бер темасына әверелә. Бу турыда тел галиме, әдәбият тарихчысы, тәнкыйтьче Җ. Вәлиди «Тукаевның иң элек телене ачкан шигырьләре форма ягыннан гына түгел, хис вә мәгънә игътибарилә дә шәркый бер характердадыр. Аның авызы мәдех белән ачылды», – дип, яңа тарихи шартларда Тукай каләменең ишан вә хәзрәтләрне мактауга түгел, ә мөхәррирләр, милләт хадимнәренә мәдхия укуга юнәлдерелүен билгели [Вәлиди, б. 186]. Әлеге сыйфат Тукайның беренче шигырьләрендә үк күренә.

Мәсәлән, Тукай Петербург шәһәрендә «Нур» газетасы (1905–1914) чыга башлауны куәтләп, бу газетага зур өметләр баглап, махсус «Шигырь» әсәрен (1905) багышлый. Шигырь «Нур»га мәдхия рәвешендә күтәренке рухта язылган. Анда «Нур» милләткә бәхет, байлык, якты киләчәк алып килүче якты кояш дип күрсәтелә, газетаның татар милләтенә яктылык, мәгърифәт нуры бөркүе, милләтнең рухи авыруларына

---

* Г. Тукайның матбугатка карашы, публицистик иҗатының төп юнәлешләре, форма һәм алымнары Ф.И. Әгъзамовның «Тукай – журналист» (Казан, 1986) исемле хезмәтендә җентекләп өйрәнелгән.

шифа булуы турында әйтелә. Алга таба өндәмә рәвешендә *(«Мәгариф тарату булсын бездә гадәт; / Бит шуңа бәйле бәхет-рәхәт / Бушка узмасын һич безнең һәр ай, һәр ел, / Тәрәккый итеп тотыйк алга юл»)* Тукайның башлангыч чор иҗатына хас булган мотивлар кертелә: аң-белем, мәгърифәт тарату, милләт тәрәккыятенә юл тоту.

Бу шигырьнең, кушымта буларак, башка үлчәм белән бирелгән өлешендә, шагыйрь инде байтак еллар чыгып килгән «Тәрҗеман» газетасына* да милләт авыруларын әйтеп бирүче булсын дигән өметләр баглый (әмма соңрак Тукайның «Тәрҗеман» газетасына мөнәсәбәте үзгәрә). Ул Бакуда чыга башлаган «Хәят» газетасын (1905–1907) да хуплап каршылый.

Тукайның «Рөшде вар, кауле гүзәл, наме – Рәшид...» (1906) дип башланган дүртьюллык шигыре дә мәдех традицияләренә нигезләнеп язылган. Биредә шагыйрь Петербургта чыга торган «Өлфәт» газетасы (1905–1907) һәм аның редакторы Габдерәшид Ибраһимовка (1857–1944) мактау сүзләре юллый. «Өлфәт» сүзенең «дуслык, бердәмлек»не аңлатуына таянып, милләттәшләрен дошманлык, тәкәллефлек кебек кимчелекләрдән арынырга, бердәм булырга чакыра.

1905 елның 9 июнендә «Әлгасрелҗәдид» журналын нәшер итәргә рәсми рөхсәт алынганнан соң, шул ук елның 15 сентябрендә, Оренбургта Ф. Кәрими (1870–1937) матбагасында «1906 сәнә башында чыкмая башлаячак «Әлгасрелҗәдид» журналының мөфассал игъланы» («1906 елда чыга башлаячак «Әлгасрелҗәдид» журналының тәфсилле игъланы») дигән реклама брошюрасында, К. Мотыйгыйга юлланган хатлар арасында, «Уральскидә мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән» исеме белән Г. Тукайның хаты һәм ике шигыре басылган. Аларның берсе – «Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый...» (1905) дип башланган исемсез шигырь. Бу шигырь журнал бастыруга керешкән К. Мотыйгый-Төхфәтуллин һәм аның «Әлгасрелҗәдид» журналын мактауга багышланган. Г. Тукай «Әлгасрелҗәдид»не милләтне дөрес юл белән алга илтәчәк журнал рәвешендә күзаллый [Яхин, 2016, б. 754]. «Әлгасрелҗәдид» – гыйлем, фикер чишмәсе, укучыларын үзара якынаю, дуслашу, милләт берләшүенә алып бара торган җеп, милләтне дөрес юлга илтәчәк журнал итеп тасвирлана.

«Әлгасрелҗәдид» журналының чыга башлавына бер ел вакыт үткәч, Тукай бу басмага «“Әлгасрелҗәдид”тә матдәтән вә мәгънән иштиракь идәнләрең лисане хале нә диер?» («“Әлгасрелҗәдид”кә матди һәм мәгънәви катнашкан кешеләрнең күңеле нәрсә әйтә?», 1906) исемле тагын бер шигырь юллый. Бу

* «Тәрҗеман» – 1883–1918 елларда Кырымда (Бакчасарайда) төрки-татар һәм рус (1905 елга кадәр) телләрендә нәшер ителгән әдәби-сәяси һәм фәнни газета. 1883–1914 елларда нашире һәм мөхәррире – Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914), 1914–1918 елларда нашире Рифат Гаспралы, мөхәррире Хәсән Айвазов була.

шигырь дә мәдхия рәвешендә «әлгасрелҗәдид»челәр исеменнән язылган. Автор фикеренчә, инде бер ел эшләп тәҗрибә туплаган бу журнал үз максатларына ирешкән. Тукай журналны караңгылыкка нур таратучы кояш, милләтне үлемнән алып калучы тереклек суы, милләт байлыгы, халыкның күңел теләге дип атый. Үз фикерен тагын да дәлиллерәк яңгыратыр өчен, автор Коръәнгә ишәрә ясый, изге китаптагы Исрафилнең сур өрүе мотивын кертеп җибәрә:

*Караңгылыкта нур тараттык без;*
*Бу үлгән милләтне тергездек без.*

*Һәм, Исрафил кебек, сур өрдек без;*
*Бу, шаять, җиңүче бер сур булыр.*

*Милләткә тереклек суы агыздык;*
*Үлем ишеген бикләтеп куйдык*
[Тукай, б. 142 ].

Әлеге мотив аша шагыйрь журнал чыгаручыларның эшчәнлеген Аллаһы Тәгаләнең дүрт фәрештәләреннән берсе булган Исрафилнең сур өрүенә тиңли (ислам мифологиясе буенча, Исрафил, сур (быргы) кычкыртып, фани дөньяның бетүе, ахирәт дөньясының башлануы турында хәбәр итә) [Габдулла Тукайның тормыш..., б. 140].

Бу шигырьдәге мотивлар да авторның алдарак искә алынган әсәрләрендәге мотивлар белән тәңгәл килә. Монда да милләтне тергезү, «милләткә дан һәм шан бирү» алгы планга чыга.

Уральскида Камил Мотыйгый наширлегендә һәм мөхәррирлегендә татар телендә нәшер ителә башлаган вакытлы басманың тагын берсе – «Фикер» газетасы. Г. Тукай дусты К. Мотыйгый башлаган бу эшкә дә актив катнашып, газетаның гамәли мөхәррир вазифаларын башкаруга керешә (рәсми мөхәррире булып К. Мотыйгый саналган). Бу газетада без Тукайны актив җәмәгать эшлеклесе, җитлеккән публицист итеп күрә башлыйбыз.

Г. Тукайның газета укучыларына мөрәҗәгать рәвешендә язылган, «Фикер» газетасына гына махсус түгел» дип аталган, 10 бәйттән гыйбарәт шигыре икешәр бәйткә бүленеп, газетаның биш санында (1906, № 11–15) басыла. «Фикер» редакциясендә эшләү сәбәпле, шагыйрь бу басманың нинди юл белән баруын ачык күз алдына китерә. Газетаның эшчәнлеген халыкның хәлен чагылдыру, аның уй-фикерләрен кузгатуда, милләт фикерен киң мәйданга чыгарырга вәгъдә итүендә күрә:

*Бар фикерегезне сыйдырыр:*
*мәйданы иркен «Фикер»нең –*
*Милләткә фикерләшергә ирек*
*биргән «Фикер»не* [Тукай, б. 79].

Ул фикерләр гел хәрәкәттә булырга, яңарып торырга, төрле ызгышлардан саклап, милләтне берләштерергә тиеш:

*Фикеребез торсын яңарып гел, –*
*саклан! Искермәсен;*
*Үзара җәнҗал-ызгыштан кыл*
*кадәр ис кермәсен!*
*Фикеребез халыкны таркаткыя*
*җилләр истермәсен,*
*Истереп, милләтнең берләшү юлын*
*кистермәсен* [Тукай, б. 79].

Күренә ки, бу шигырьдә дә, төп мотив буларак, фикерне яңарту, «үзара җәнҗал-ызгыштан» котылу, милләтне берләштерү яңгырый.

Г. Тукайның бу чор поэзиясендә вакытлы матбугат булдыру, аның эшчәнлеген тәэмин итү юлында күп көч куйган нашир-мөхәррирләрне, нәшрият хезмәткәрләрен мактап язылган шигырьләр бар. Алар арасында алдарак искә алынган «Чөнанча бездә...» (1905), «Рөшде вар…»(1906), «Мөхәрриргә» (1906), «Гәзитә мөрәттибләренә» (1906) исемле шигырьләрне атарга була. Шагыйрьнең «Мөхәрриргә» шигыре, мәсәлән, «Бәянелхак» газетасында Камил Мотыйгыйга каршы юнәлтелгән, аны «дәһри» («динсез») дип гаепләгән мәкаләләргә җавап рәвешендә язылган. К. Мотыйгый җитәкләгән демократик рухтагы «Әлгасрелҗәдид» журналы һәм аның эшчәнлеге Уральск реакционерларының ачуын китерә, «Бәянелхак» газетасындагы тәнкыйтькә теләктәшлек күрсәтеп, аларның К. Мотыйгый басмаханәсенә зыян салырга ниятләүләре дә билгеле [Тукай, б. 337].

Г. Тукай мөхәрриргә юнәлтелгән яла ягуларга игътибар итмичә:

*Дөресен сөйлә, дөресне яз –*
*беркемнән дә курыкма;*
*Сабыр бул, чөнки сиңа эшнең*
*җиңеле йөкләнмәгән, –*
[Тукай, б. 109]

дип, үзе билгеләгән туры юлдан сабырлык белән хәрәкәт итәргә өнди. Дүрт газета-журнал мөхәррире булуы, дүрт яктан аккан мәгърифәт елгасы агымында булуы белән аны бәхетле саный. Ләкин моның белән генә канәгатьләнмичә алга барырга, тәрәккый итәргә чакыра.

«Гәзитә мөрәттибләренә» (1906) исемле шигырендә Тукай, энҗе кебек сүзләр тезеп, милләт фикерен басмага салучы мөрәттибләргә (хәреф җыючыларга) мәдхия укый. Хәреф җыючыларның эшчәнлеге милләткә хезмәт итү, милләтне наданлыктан йолып алу белән бәйлелектә карала.

1906 елның июнь аенда Уральскида Камил Мотыйгый мөхәррирлегендә тагын бер журнал – «Уклар» нәшер ителә башлый. К. Мотыйгыйның «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдид» журналы, шулай ук рус телендәге «Уральский дневник» газетасы нашире булу сәбәпле, «Уклар»дагы төп эшне Г. Тукайга башкарырга туры килә. «Уклар» журналын чыгаруга рөхсәт алыну турындагы мәгълүмат «Фикер» газетасының 1906 елның 8 май санында дөнья күрә [Габдулла Тукайның тормыш..., б. 97]. Шул ук санда, игъланнан соң Г. Тукайның «“Уклар” журналында мөхбир уланлара тәнбиһ» исемле шигыре урын алган. Ул булачак «Уклар» журналының мөхбирләренә (хәбәрчеләренә) өндәмә рәвешендә язылган. Биредә Г. Тукай язучының коралы булган сүзләрне «уклар» дип атый. Алга таба укларны патроннар белән тәңгәлләштерә:

*Бездән фәрман шул сезгә: патрон*
*берлә не шалить!*
*Кирәк җиргә атканда, патроннарны*
*не жалеть!* [Тукай, б. 86].

Шул ук 1906 елның июнь аенда Тукай «Уклар» исемле шигырендә яңа журналның максатын иске фикерле муллаларны

«кызганмый чукмарлауда», дип билгели.

Алда китерелгән ике шигырьнең без мәдех традицияләренә түгел, ә сатирага нигезләнгән булуын ачыклыйбыз. Шулай итеп, Тукай иҗатының башлангыч чорында андый сатира белән сугарылган шигырьләр арасында матбугат темасына бәйле булган шигырьләрен дә очратабыз. Алар аерым газета һәм журналларга һәм аларны нәшер иткән шәхесләргә нисбәтле язылган.

Мәсәлән, «Кыямәт якын килде...» (1906) исемле шигырендә Тукай демократик юнәлештәге «Азат халык» газетасының либераль мәсләкле «Йолдыз» газетасы белән кушылуына ризасызлык белдерә [Бәширов, б. 395–396].

Шигырьнең беренче тезмәләрендә автор кыямәт көне сурәтен тергезә:

*Кыямәт якын килде – җир сораучы*
*ярылды;*
*Галимнәр тәүбә кыйлды,«Аллаһ»,*
*дигел бәдәвам.*

*Замана ахры булды – хәятләр*
*мәмат булды;*
*Көлгәннәр йөзтүбән китте, «Аллаһ»,*
*дигел бәдәвам* [Тукай, б. 122].

Икенчесендә исә «Азат халык»ның ябылуы ирония белән сугарылган:

*«Фикер» дән көлгән иде – һич*
*сәбәпсез бер «Азад»;*
*Инде ул китте назад, «Аллаһ»*
*дигел, бәдәвам* [Тукай, б. 122].

«Дөнья бу, йа!» (1906) шигырендә «Бәянелхак» газетасы нашире һәм мөхәррире Әхмәдҗан Сәйдәшевне, «Тәрҗеман» газетасын, мәсләген алыштырган «Азат халык» газетасын көлкегә ала.

Тукайның сатирик рухта язылган шигырьләре белән янәшә инвектива жанрында язылган әсәрләре дә бар. Мәсәлән, «Күрдегезме?» шигырендә «Дөнья вә мәгыйшәт» журналы* ачы тәнкыйть утына тотыла. Бу шигырьдә автор, әлеге басманы һәм аның мөхәррирен бәяләп, гади сөйләм сүзләрен дә куллана (*«Яшерми әйтегез миннән, китерми шөбһәне, шикне: / Мөхәррир, нашире кемдер – сыермы әллә ишәкме?»* [Тукай, б. 166]).

«Матбага берлә уйнаган бер байга» (1907) шигырен дә инвектива үрнәге дип санарга мөмкин. Анда Тукай Уральскида татар вакытлы матбугатына ярдәмен туктаткан Мортаза Гобәйдуллинга тискәре мөнәсәбәтен белдерә:

*Гыйльмә нашир[1] булды бу, яхшы*
*кеше булды, дисәм, –*
*Нәйләем[2] ки, бик кабих[3], шахшы*
*икәнсең син һәнүз[4]!*

---

* Журнал Оренбургта 1906 елның 31 декабрендә (наширләре – Ш. Шәфигуллин, М. Дәүләтшин; мөхәррире – З. Хәйруллин) чыга башлый. 1907 елның 13 апреленнән «Дин вә мәгыйшәт» (нашире – М. Хөсәенов, мөхәррирләре – Ф. Даутов һәм Г. Ханисламов) дигән исем астында 1917 елның октябренә кадәр нәшер ителә.

[1] Гыйльмә нашир – гыйлем таратучы.

[2] Нәйләем – ни хәл итим.

[3] Кабих – кабахәт.

[4] Һәнүз – һаман.

*Бу сәхи*[1]*, бер бай кеше тәкмил итәр*[2]
*барын, дисәм, –*
*Бер хәсис*[3]*, мәгъруp икән, карун*
*икәнсең син һәнүз* [Тукай, б. 201].

Татар газета-журналларының мәйданга чыгуы Тукай тарафыннан алкышлап каршыланса, аларның ябылуы шагыйрьдә үкенеч хисе тудыра. Мәскәүдә нәшер ителгән «Тәрбиятел әтфаль» («Балалар тәрбиясе»)* журналының чыгудан тукталуы уңае белән язылган шигыре шундыйлардан. Автор бер мөселман баласы исеменнән үзенең кайгы-хәсрәте белән уртаклаша. Милләт балаларын «нурландыру»ны (аң-белем, мәгърифәт бирүне) максат итеп куйган журналның ябылуына юл куйган ата-бабаларга:

*Аһ, кем! Ата-бабаларыбыз сакаллы*
*сабыйлар икән,*
*Аларны кеше дип исәпләү ялган*
*һәм яла икән* [Тукай, б. 165], –

дип, үпкә белдерә.

Г. Тукай 1907 елның 23 апреленнән, «Таң йолдызы» газетасының дәвамы буларак, Казанда чыга башлаган «Тавыш» газетасына да тәбрикләүләр юллый. «“Тавыш” хакында» исемле шигырендә Тукай аңа зур өметләр баглый.

*Аңлау кирәк: бу «Тавыш» – тик*
*сезнең тавыш,*
*Сезнең хакны даулар өчен бу*
*кузгалыш, –*

дип, «Тавыш»ны эшчеләр тавышы дип атый, алдынгы көчләрне газета тирәсендә тупланырга, эшчеләрне үз хокуклары өчен көрәшергә, алга барырга чакыра:

*Эшче туган! Тартыш кирәк, кирәк*
*тартыш,*
*Тартышмаган эшчеләргә бик батар*
*теш;*
*Изге эштер тартышмаклык хокук*
*өчен,*
*Тартыш, эшче! Тартыш, зинһар,*
*тартыш, тартыш!* [Тукай, б. 174]

Шулай итеп, Тукайның Уральск чоры лирикасында матбугатка бәйле шигырьләрендәге мотивлар ике төркем тәшкил итә:

– милли матбугатны югары дәрәҗәгә кую, аның иҗтимагый функцияләрен билгеләү, милләт тәрәккыятендәге ролен ассызыклау (милли тәрәккыят, мәгърифәт тарату, милләтне агарту, фикер үстерү мотивлары). Бу төркем шигырьләр, асылда, мәдех рухында язылганнар, аларның эчтәлеген аерым матбагачылыкны һәм аерым газета-журналларны яки аларны нәшер иткән шәхесләрне мактау били;

– милли матбугат үсешенә каршы килгән яки кадими юнәлештә нәшер ителгән газета-журналларны дискредитацияләү, аларның милләт мәнфәгатьләренә туры килмәвен күрсәтү. Бу төркем шигырьләр сатира коралы белән яки инвективага нигезләнеп язылганнар.

Шуны дә әйтергә кирәк, XX йөз башы татар шагыйрьләре иҗатына күз салсак, алар арасын-

[1] Сәхи – юмарт.

[2] Тәкмил итәр – түгәлләр.

[3] Хәсис – эшәке.

* «Тәрбиятел әтфаль» («Балалар тәрбиясе») – 1907 елда Мәскәү шәһәрендә бары биш саны гына чыккан төрки, татар балалар журналы. Нашире һәм мөхәррире – Мөхәммәдзаһид Шамил (1868–1920), нашире һәм җаваплы мөхәррире – Хөсәен Байбәков (? – 1919 елдан соң), җаваплы сәркәтибе – Фатих Әмирхан.

да вакытлы милли матбугатка багышланган шигырьләр күп түгел: М. Гафуриның «Мәнзум сүзләр» (1906), «Бәгыс» (1916), Н. Думавиның «Без дә файдаланыйк!» (1906), М. Укмасыйның «“Бәянелхак”ны сәнәлеге илә тәбрик идәмен» (1907), С. Рәмиевнең «Басма сүз» (1916) һ.б. Димәк, Г. Тукай татар шигъриятенең бу тематик өлкәсендә ин актив шагыйрь булып кала. Әлбәттә, бу аның татар журналистика өлкәсендә актив эшчәнлеге белән бәйле.

**Әдәбият**

*Әгъзамов Ф.* Тукай – журналист. Казан: Татар. кит нәшр., 1986. 271 б.

*Бәширов Ф.К.* Кыямәт якын килде // Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш. мөх. З.З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. Б. 395–396.

*Вәлиди Җ.* Тукаев хакында берничә сүз // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / Төзүчеләр: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 2 т.: мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр. Б. 184–192.

Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчесвта Габдуллы Тукая (1886–1907) / З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов, Г.М. Ханнанова, Ә.Х. Алиева, Н.Ш. Насыйбуллина, Р.Ф. Харрасова, А.И. Әхмәтова; З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов редакциясендә. Казан. 2018. 448 б.: илл. белән.

*Гайнуллин М.* Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во. 1983. 352 с.

*Гыймадиев Ү.* Сатира коралы белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 215 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Габдулла Тукай шигъриятендә төп мотивлар: халыкка багышланган гомер //Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәгланышлар: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (25 апрель, 2011 ел). Казан, 2011. Б. 22–23.

*Нуруллин И.* Габдулла Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 304 б.

*Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда / Габудлла Тукай. Академик басма. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев. Казан. 2011. 407 б.

*Халит Г.* Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века. Казань: Таткнигоиздат, 1956. 232 с.

*Халит Г.* Тукай и его современники. Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. 227 с.

*Яхин Ф.* Татарская литература в периодической печати Уральска (1905–1907). Казань: Татар. кн. изд-во. 1992. 125 с.

*Яхин Ф.З.* «*** (Чөнанча бездә ...)» // Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш. мөх. З.З.Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. Б. 754.

*Статья подготовлена при финансовой поддержке РФФИ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 18-412-160012*

*Мәкалә Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 18-412-160012 номерлы фәнни проект кысаларында әзерләнде*

***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Л.Ш. Галиева*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ ПОЛЬША

Данная статья представляет собой обобщение известных фактов о жизни и деятельности Гаяза Исхаки в период его пребывания в Польше (1927–1939-е гг.), с целью наметить план для дальнейших исследований в этой области.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Польша, польские татары, Ю. Пилсудский, «Rocznik tatarski», «Wschod-Orient», организация «Прометей».

Күренекле әдип Гаяз Исхакыйның унбиш томлы әсәрләр җыелмасы, аның иҗаты һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге буенча мәкаләләр, җыентыклар дөнья күреп, диссертацияләр яклanса да, язучы һәм җәмәгать эшлеклесенең биографиясендә, бигрәк тә аның мөһаҗирлектәге чорына кагылышлы ачыкланып бетмәгән фактлар да бар. Әлеге мәкалә Г. Исхакыйның Польша дәүләте белән бәйле мәгълүматларны барлау ниятеннән язылды. Алар әдипнең әсәрләр җыелмасыннан, төрле мәкаләләрдән, хезмәтләрдән алынды. Төп максат – билгеле булганнарны җыйнау һәм анализлау аркылы киләчәктә алып барыласы эзләнү эшләренә нигез салу.

Г. Исхакыйның 1991 елда басылып чыккан «Зиндан» җыентыгында Һ. Мәхмүтов һәм Л. Гайнанованың күләмле мәкаләсе урнаштырылган. Әлеге язмадан язучының «Польша чоры» иҗаты һәм эшчәнлеге хакында түбәндәге мәгълүматлар бирелә: 1) Туган иленнән, үз халкыннан аерылгач, Г. Исхакый башта Харбин (Кытай), аннан Париж (Франция), Берлин (Германия), Варшава (Польша) һ.б. шәһәрләрдә яши. 1939 елның июль аенда Гитлер Германиясе Польшага һөҗүм башлагач, Польша хөкүмәте кушуы буенча, ул, язмаларын, архивын калдырып, ашыгыч рәвештә Төркиягә күчеп китә; 2) Г. Исхакый Харбин, Берлин һәм Варшавада яшәгәндә «Милли юл» дип исемләнгән нәшрият булдырып, татар эмигрант язучыларын шул тирәгә туплый һәм «Милли юл», «Яңа милли юл», «Безнең байрак» дигән газета-журналлар чыгара; 3) әдипнең «Идел–Урал» тарихи-публицистик китабы 1938 елда Варшавада поляк телендә дөнья күрә [Мәхмүтов, Гайнанова, б. 656–658]. Г. Исхакый әсәрләренең V томында Л. Гайнанова билгеле булганнарга шунысын да өсти: Г. Исхакый, Польшадан эмигрантлар оешмасы «Прометей» җитәкчеләре белән бергә, Варшавадан чыгып китәргә мәҗбүр була [Гайнанова, б. 8]. Тулырак мәгълүматны Г. Исхакыйның «Польшадан китү» язмасыннан беләбез: «1939 елның 6 сентябрь төнендә, сәгать уникеләрдә, Варшаваның Allee Ujazdovskiдан ерак түгел, бер кечерәк урамның башында җыелышып, икенче егерме минутта юлга кузгалдык. Без – азәриләр

Әмин бәй Рәсүлзадә, Мирза Бала һәм Али Азәртәкин, Төньяк Кавказлы Сәгыйть Шамил, украин Смаль-Стоцкий, грузин Имнаидзе, Төньяк Кавказ казагы Билатти, шулай ук Төньяк Кавказлы Даут исемле егет, кырымлы Әдигә Шинкевич (Кырамал) һәм мин Гаяз Исхакый» [Исхакый, т. 13, б. 241]. Язучы биредә шулай ук бөтен әйберләре, киемсалымнары Варшавада калуын искәртә, аларны ул илдәшләре, башкалада укыган яшьләргә тапшырып китә [Исхакый, т. 13, б. 222].

Моннан тыш, шушы томның кереш сүзендә Л. Гайнанова тарафыннан түбәндәгеләр искәртелә: «Г. Исхакыйның Ватаныннан читтә яшәгәндә иҗат иткән барлыгы 11 әдәби әсәре мәгълүм. Шуларның икесе – “Ике ут арасында” драмасы һәм “Олуг бәйрәм” исемле хикәясе, әдипнең кызы Сәгадәт Чагатай төзүчегә язганча, әтисенең башка әйберләре белән бергә, Варшавада бер саклык банкысының кассасында кала, ул банкка бомба төшеп, бина җимерелә. Әмма Г. Исхакый үзе Варшавадагы архивының сакланып калу ихтималына беркадәр ышанган күрәсең. Лондонда курсларда укып йөргән кызы Сәгадәткә 1948 елның 26 октябрендә Истанбулдан язган хатында элекке танышлары булган нindидер Камиләгә сәлам күндерә һәм: “Ул Варшава белән язышамы? Минем өйдәге китапларның ни хәлдәгесен, янып бетеп-бетмәвен белмиме? Шуны сора әле”, – ди» [Гайнанова, б. 7].

Югарыда телгә алынган «Прометей» оешмасы хакында Г. Исхакый язганнардан: «Әле без, төрек-татар оешмалары һәр йирдә бергә, бер-беремезгә ярдәмләшеп, бер фикердә хәрәкәт итәмез. Дошманның көчлелеген аңлап, без бөтен рус кул астыннан котылыр өчен тартышкан халыклар белән якынлашырга телимез. Украина, Гөрҗестан, Кубань вә Дон казакларының истикъляль көрәшчеләре белән берегеп, «Прометә» исемле сәяси клублар төзедек. Шул ук исемдә Парижда французча бер мәҗмуга чыгарамыз. «Прометә»нең лозунгасы – Русияне милләтләр нигезендә бүлүдер» [Исхакый, т. 10, б. 177]. Әлеге оешма 1930 елда Польша хөкүмәте тарафыннан оештырыла һәм Тышкы эшләр министрлыгы каршында 1939 елга кадәр эшли [Исхакый, т. 10, б. 516]. Г. Исхакый – Варшавадагы «Прометей» клубының вәкиле булып торган [Исхакый, т. 10, б. 406]. Оешманың тоткан кыйбласы, максат-бурычлары, эшчәнлеге турында язучының тәфсилле «Прометә» мәкаләсен укып танышырга мөмкин [Исхакый, т. 12, б. 255–260].

Соңрак басылып чыккан мәкаләләрдә әдипнең Польша дәүләт эшлеклесе Ю. Пилсудский белән танышлыгы хакында мәгълүматлар китерелә. М. Хәсәновның Г. Исхакый әсәрләренең 1 томына язган кереш сүзенә мөрәҗәгать итик: Г. Исхакый Архангель сөргенендә чакта поляк революционеры (ә соңыннан күренекле дәүләт эшлеклесе) Ю. Пилсудский белән таныша, 30 нчы елларның икенче яртысында алар кабат очраша [Хәсәнов, 1998, б. 11], утызынчы

елларда Польшада «Варшау Прометее» дигән оешма белән җитәкчелек иткәндә ул Г. Исхакыйга ярдәм күрсәтә [Хәсәнов, 2000, б. 12]. Галимә Л. Гайнанова исә: «Польша хөкүмәтенең башлыгы, маршал Йозеф Пилсудский (1867–1935) Г. Исхакыйны Варшавага чакырып ала, аңа үз матбагасын оештыруда ярдәм итә», – дип язып чыга [Гайнанова, б. 7]. М. Сәхапов та әдипнең Пилсудский белән танышлыгына басым ясый: «Г. Исхакый 1907 елда Архангель губернасының Пинега шәһәрендә бергә сөргендә булган дусты маршал Юзеф Пилсудскийның шәхси чакыруы буенча Польшага килә һәм Варшава шәһәрендә төпләнә» [Сәхапов, 2006, б. 244–245]. Күрәбез, әлеге мәгълүматлар Г. Исхакый белән Ю. Пилсудскийның теге яки бу дәрәҗәдә аралашуы хакында сөйли. Әдип үзе исә Халидә Вафага «Мәгънәви васыятем кебек калсын» дип язган хатында мондый сүзләр җиткерә: «Ялгыз сәяси кыйммәтебезне аңлаган Ләһстан (Польша) хөкүмәте генә безгә аз-маз кулны суза ала. Аның аркасында мәмләкәттә күтәрелгән берлек байрагымызны йиргә индермибез» [Миңнегулов, 2004, б. 346]. Пилсудский, Дащинский кебек милли каһарманнарны Г. Исхакый гыйбрәт алырлык шәхесләр буларак бәяли [Исхакый, т. 10, б. 85].

Ф. Мусин хезмәтенә игътибарны юнәлтик. Галим Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге чорын тикшереп, әдипнең Ерак Көнчыгышка бару нияте турында хәбәр итә: «Польша властьларыннан Ерак Көнчыгышка командировка алу мәсьәләсе озак хәл ителми. Бу хакта без Г. Исхакыйның исем-фамилиясе билгесез бер поляк дәүләте чиновнигына рус телендә адресланган мөрәҗәгать-хатларыннан беләбез. Шул документларның берсендә, ягъни 1933 елның 6 июлендә язылганында, Г. Исхакый әлеге чиновникка “Господин капитан” дип мөрәҗәгать итә. ... Польша властьларының матди ярдәме белән оештырылган бу сәяхәт бер үк вакытта поляк разведкасының ныклы күзәтүе астына алына» [Мусин, б. 111–114]. Алга таба ул түбәндәгеләрне билгели: 1) әлеге ерак сәфәрдән әйләнеп кайтканнан соң, әдип төрки-татар конгрессын үткәрүне планлаштыра, Милләт мәҗлесе төзелүнең 20 еллыгына багышлап үткәрелгән конгресс 1938 елның 4–6 февралендә Варшавада уза; 2) әлеге конгресс хакында аның 1938 елның февралендә Варшава радиосы аша ясаган чыгышы мәгълүм [Мусин, б. 137–139]. Милләт мәҗлесе юбилееның ни өчен нәкъ менә Варшавада уздырылуы турында Г. Исхакый «Яңа милли юл» журналында язып чыга: «Ләһстан әфкяре гомумиясенең безнең милли эшләребезгә хәер-хаһча каравы, сәяси вазгыятьнең мөсагыйд булуы бу мөһим истәлек бәйрәмебезне Варшавада ясауны алга сөрде» [Исхакый, т. 12, б. 233–234].

Г. Исхакый һәм Польша, Польша татарлары темасы беренче тапкыр галим Ә. Кәримуллин язмаларында күтәрелә. Аның «Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары» мәкаләсе 1994 елда

«Мирас» журналы битләрендә басыла [Кәримуллин, 1994, б. 196–199]. Биредә галим, билгеле булган мәгълүматларга таянып, берничә сорау куя: «Г. Исхакый кайчан Польшага барып чыккан, кайсы шәһәрләрдә яшәгән, нинди эшләр башкарган, кемнәр белән аралашкан, нәрсәләр эшләгән? дигән сорауларга конкрет, тулы җавап әлегә юк. Архангель губернасында сөргендә вакытта аның Пилсудский белән бергә булуын искә алалар. Польшага килгәнче һәм анда барып чыккач, Исхакый Польша Президенты булган шул Пилсудский белән очрашканмы, юкмы? Аның Польшага барып чыгуы шул танышлыкка барып тоташмыймы?» [Кәримуллин, 2005, б. 262]. Әдипнең Польшадагы эшчәнлеге турында ул вакытта билгеле булган мәгълүматлар түбәндәгеләр: 1) 1927–1939 елларда ул Берлин һәм Варшавада яшәп ала (Х. Миңнегулов фикере); 2) Г. Исхакый инициативасы белән 1928 елның 28 июнендә Варшавада «Идел-Урал» комитеты оештырыла; 3) әдип биредәге «Прометей» оешмасында актив эшләп килә; 4) биредә ул 1928 елның 23 декабрендә «Милли юл» исемендәге журнал чыгаруга карешкән һәм ул тора-бара «Яңа милли юл» исеме белән чыга башлаган [Кәримуллин, 2005, б. 262]. Әдәбият галиме Х. Миңнегулов фикерен Г. Исхакыйның «Польшадан китү» язмасында китерелгән сүзләр белән раслый алабыз: «Без, төрек илләренең милләтчеләре, ун-унике еллап элек бу дус илдә төзегән яңа милли оешмаларыбыз, милли азатлык өчен көрәш үзәкләребез дә шулай ук Польша белән бергә ут эчендә кала һәм җимерелә иде!..» [Исхакый, т. 13, б. 240].

Болардан тыш, Ә. Кәримуллин журнал укучыларын Г. Исхакыйның 1932 елда «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы») дип исемләнгән поляк басмасында дөнья күргән «Польша татарларының милли бурычлары» мәкаләсе белән таныштыра. Әлеге язмадан аңлашылганча, Г. Исхакый Польшада яшәүче татарларның тарихы, мәдәнияте белән кызыксынган, аны аларның язмышы борчыган. Мәкаләне рус теленә галим Рифкать Йосыпов тәрҗемә итә. Соңрак ул аны «Польские страницы жизни Гаяза Исхаки» дип исемләнгән мәкаләсендә дә бастырып чыгара [Юсупов, с. 144–146]. Ә. Кәримуллинда китерелгән фактлардан тыш, Р. Йосыпов язмасыннан бер җөмләне өсти алабыз: «Краткое время в конце 1920-х гг. Г. Исхаки пребывал в Польше» [Юсупов, с. 144]. Әмма бу мәгълүматның кайсы чыганактан алынуы төгәлләштерелми. Галим Б. Гали «Польша татарларының милли бурычлары» мәкаләсенең «Милли юл» журналының 1929 елгы 12 нче санында урын алганын да искәртә [Гали, б. 56].

Л. Гайнанова 1999 елда басылып чыккан Г. Исхакый әсәрләренең икенче томында телгә алынган «Rocznik tatarski» журналы хакында өстәмәләр кертә: «Бөек Ватан сугышына кадәр Польшада поляк телендә поляк-литва татарларының тарихы, тормышы, мәдәнияте турында «Rocznik tatarski» («Татар

елъязмасы») дигән исемдә өч җыентык чыгып өлгерә (1932 елда – Вильнода, 1935 елда – Замощчта, 1938 елда – Варшавада)». 1932 елгы җыентыкта Г. Исхакый турында белешмә һәм аның «Польша татарларының милли мәсьәләләре» исемле мәкаләсе басылып чыга [Исхакый, т. 2, б. 458]. Әмма искәрмәләр авторы тарафыннан телгә алынган белешмә турында Ә. Кәримуллинда мәгълүмат юк.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗатын киң планда тикшергән галимнәрнең берсе – Х. Миңнегулов. Әлеге темага карата аның ике монографиясе дөнья күрә [Миңнегулов, 1999; Миңнегулов, 2004]. Алда саналган мәгълүматлардан тыш, соңгысында китерелгән фактларга тукталыйк: 1) Г. Исхакый бераз вакыт Польшаның Шәрык институтында эшләп ала; 2) 1937 елның башларында, бигрәк тә әдипнең туган ае – февральдә, Г. Исхакыйның иҗади эшчәнлеге башлануга 40 ел тулу мәмләкәттән читтә яшәгән татарлар арасында киң күләмдә билгеләп үтелә. Юбилей тантаналарының иң зурысы 5 март көнне Варшавадагы Шәрык институтының зур залында уздырыла; 3) 1930 елда Польша башкаласында Идел-Урал, Төркестан, Азәрбайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия, Карелия вәкилләрен үз эченә алган «Прометей» исемле милли-азатлык хәрәкәте оешмасы төзелә. Аның да үзәгендә Гаяз Исхакый тора; 4) «Яңа милли юл» журналының 1931 елгы җиденче-сигезенче саннарының тышлыгында «Ләһстанда татар атлы гаскәрие», «Наполеонның татар гвардиясе», «Татар сугышчысы» кебек сурәтләр бар, алар «Ләһстан мөселманнарының милли музәханәләреннән алынган» (Г. Исхакый үзе биредә булганмы?); 5) Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗирлеккә дучар ителгән милләттәшләребез 1552 елгы кара көнне Хәтер көне, Матәм көне рәвешендә билгеләп үткәннәр. Мондый чаралар 1920–1930 елларда Польшада да узган; 6) Варшавада язучы һәм җәмәгать эшлеклесенең «Ислам мәмләкәтләрендә» дигән юл хатирәләренең бер өлеше язылган [Миңнегулов, 2004]. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге әдәби иҗаты киңрәк планда Ә. Сәхапов, Г. Зәйнуллина, И. Мансуровларның фәнни хезмәтләрендә чагылыш таба [Сахапов; Зайнуллина; Мансуров].

Варшавада яшәү дәверендә Г. Исхакый биредә милләтебезнең күренекле әдипләренә багышлап төрле кичә һәм чаралар үткәрүдә катнашкан, оештырып йөргән. Мисал өчен, Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу, «Тәрҗеман»ның 50 еллык бәйрәме һ.б. уңаеннан Г. Исхакыйның чыгышлар ясавы, шулай ук, Варшаваның «Прометей» клубында, Шәрык институтында лекцияләр укуы да мәгълүм.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге тарихчы, журналист һәм җәмгыять гыйлеме галимнәре – Б. Солтанбеков, И. Таһиров, Р. Гайнетдинов, Б. Гали, С. Исхаков, А. Мөбарәкҗанова, Г. Галәметдинов һ.б.ның хезмәтләрендә дә урын ала.Мисал өчен, галим

Р. Гайнетдинов үзенең «Деятельность татаро-башкирских эмигрантских организаций и центров в 1900 – начале 1930-х годов» дип исемләнгән диссертациясенең бер өлешен Г. Исхакый җитәкчелегендәге «Идел-Урал» оешмасының СССРга каршы алып барган антисоциалистик эшчәнлегенә багышлый. Әлеге хезмәттән шунысы билгеле: «Идел-Урал» «Бәйсезлек комитеты» Польша Генштабының II бүлеге тарафыннан финанслана һәм моның өчен әлеге хәрәкәт әгъзалары СССР һ.б. илләр хакында мәгълүмат тупларга тиеш була [Гайнетдинов, б. 15]. Б. Гали исә әлеге көрәшне беренчел вакытта гына булуын ассызыклый [Гали, 41 б.].

Г. Исхакый һәм Польша темасы, әлбәттә, алга таба тагын да тирәнрәк өйрәнелергә тиеш. Биредә бары тик төп мәгълүматлар туплап бирелде. Билгеле булган фактлар шуны раслый: Г. Исхакыйның әлеге илдә алып барган эшчәнлеге төрле юнәлешле, ул күп кенә шәхесләр белән аралашуны күздә тоткан. Димәк, беренче чиратта, аларның исемлеген булдыру, эшчәнлекләре белән танышу, истәлек-хатирәләрне туплау һ.б. эшләрне башкару ихтыяҗы туа. Әлбәттә, бу юлда чит ил галимнәре хезмәтләренә таяну, алар белән элемтәгә керү дә сорала. Шул ук вакытта чит ил матбугатына игътибарны арттыру да зарур.

**Әдәбият**


*Гайнанова Л.* Төзүчедән // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 5 т. Казан, 2009. Б. 5–18.

*Гайнетдинов Р.Б.* Деятельность татаро-башкирских эмигрантских организаций и центров в 1900 – начале 1930-х годов: автореф. дис. ... канд. ист. наук. Казань. 1993. 20 с.

*Гали Б.Т.* Щедрый талант. Общественно-политическая деятельность и исторические взгляды Гаяза Исхаки. Казань: Унипресс, 2002. 96 с.

*Зайнуллина Г.И.* Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 2002. 24 с.

*Исхакый М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 10 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 527 б.

*Исхакый М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 12 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 471 б.

*Исхакый М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 13 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 335 б.

*Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 2 т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1909–1918). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 464 б.

*Кәримуллин Ә.* Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары // Безнең кардәшлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 261–270.

*Кәримуллин Ә., Нигъмәтҗанова А.* Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары // Мирас. 1994. № 5–6. Б. 196–199.

*Мансуров И.С.* Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 2005. 28 с.

*Мәхмүтов Һ., Гайнанова Л.* Зарыгып көткән мирас // Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 636–660.

*Миңнегулов Х.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.

*Миңнегулов Х.* Исхакый мөһаҗирлектә. Казан: Таң–Заря, 1999. 84 б.

*Мусин Ф.* Гаяз Исхакый: (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

*Сахапов М.Ж.* Творчество Гаяза Исхаки в период скитаний (1919–1954) = Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлек чорындагы иҗаты (1919–1954) = Gayaz Iskhaki the creative work at the period of warderings (1919–1954). Казань: Магариф, 2008. 294 с.

Сәхапов М.Җ. Бердәм агым. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 399 б.

*Хәсәнов М.* Татар ренессансының бөек каһарманы // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан. 2000. Б. 4–13.

*Хәсәнов М.* Татар ренессансының бөек каһарманы // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 399 б.

*Юсупов Р.Р.* Польские страницы жизни Гаяза Исхаки // Вестник Челябинской государственной академии культуры и искусств. 2012. № 1 (29). С. 144–146.

***Галиева Ләйсән Шәукәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ ИҖАТЫНДА ПОЭМА ЖАНРЫ

В статье анализируются лиро-эпические произведения известного татарского поэта второй половины XX века Р. Ахметзянова (1941–1995), написанные в разные периоды его творчества. Исследуя их, автор приходит к выводу, что в них отражается судьба советских людей, историческая документальность сочетается с поэтической выдумкой, а условность с реалистичностью. В манере изложения автора прослеживается связь с предшествующей национальной литературой, с художественными традициями мусульманского Востока и европейской поэзии. В своей самой известной и метафоричной поэме «Бишташ» Р. Ахметзянов выдвигает идейные, нравственные и культурные ценности, выстраданные народом в многовекой истории. В целом, творчество Р. Ахметзянова ценно тем, что проникнуто духом борьбы за защиту Родины, сохранение своей нации, родного языка, традиционной морали.

**Ключевые слова:** Р. Ахметзянов, поэма, художественные традиции, культурные ценности.

Милли рухлы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов хакында уйлый башладыңмы, күңелне үкенеч хисе кузгатып җибәрә: исән чагында иҗатка бәяне төрле премия-бүләкләрдә чагылдыручы хакимият тә, Татарстан Язучылар берлеге дә аңа игътибарсызрак булды, тәнкыйть исә язганнарын тиеш дәрәҗәдә бәяләмәде, ачмады. Р. Әхмәтҗан поэзиясе галимнәр тарафыннан аз яктыртылды, аның хакында, нигездә, җитди тәэсирле сүз һәм образлы нәфис шигърият тәмен аңлаган, чын кешене кадерләргә теләгән каләмдәшләре язды. Шунысы да сөендерә: ул һәрвакыт халыкның яраткан каләм иясе, исеменә-намусына тап төшермәгән көрәшчесе иде, ярый әле бик хаклы рәвештә бары тик милләт алгарышына хезмәт иткән һәм милли эчтәлектәге иҗат өчен генә бирелә торган Г. Исхакый исемендәге әдәби премия белән бүләкләнеп өлгерде.

* * *

Рәшит Әхмәтҗанов бала чагыннан ук каләм тибрәтә, армия чорында да, хезмәт вахтасында эшче булып басып торганда да язуын туктатмый, ә инде университет елларында бары тик шигърият белән яши башлый, чөнки бу вакытта татар бүлегендә чын мәгънәсендә иҗат атмосферасы хакимлек итә, югары уку йортының талантлы яшьләре, зур һәм көчле дулкын булып, үзләрен шунда ук таныта да башлаган әдәбият мәйданына үтә.

Рәшит Әхмәтҗановның вакытлы үзәк матбугатта исеме илленче елларның ахырларында күренә башлый. 1957 елда Әлмәттә нефтьчеләр газетасына беренче шигырьләрен китергәч, аларның камиллегенә гаҗәпләнгән

редактор белән секретарь, ышанырга-ышанмаска белмичә, 16 яшьлек егеткә әдәби сынау уздыралар, яңа әсәр яздырып карыйлар [Галиев, б. 7]. Ул әле аннан соң да иҗат кешеләрен иртә ачылган таланты белән шаккатыра. Әдәбиятка бик иртә килүенә карамастан, Р. Әхмәтҗанов поэма иҗат итүгә җитмешенче еллар ахырында гына керешә. Шагыйрьнең 1980 елда басылган «Исәннәр моңы» әсәре – лирик-драматик поэма. Анда Бөек Ватан сугышына бәйле вакыйга-күренешләр, шул чор кешеләренең уй-кичерешләре тасвирлана, һәм алар яңа заман хикәяләүчесенең сюжетта урын алган геройларга, аларның эш-гамәлләренә мөнәсәбәте белән үрелеп бара.

«Исәннәр моңы»нда лирик як өстенлек итә, эпик хикәяләү аерым фрагментлардан гына оеша. Аны укыганда, шагыйрьнең зур иҗтимагый-тарихи чорны кешеләр язмышы аша, эчтәлек җиңел аңлашылырлык итеп чагылдыруда кыенлык кичерүе сизелә. Дөрес, Р. Әхмәтҗан тәүге күләмле әсәрен язуга билгеле бер хәзерлек белән килә. Аның җитмешенче елларда күренеп алган циклы («Сугыш елы», ««Пәһлеваннар» спектакленнән алты шигырь»…), я булмаса, катлаулы төзелешле, күләмле шигырьләре («Мәңгелекне дәвам итәбез», «Балачак», «Башлыйбызмы?» ) поэма жанрына таба баруда тәүге адымнар була. Хәер, «Исәннәр моңы»н без Р. Әхмәтҗановның икенче поэмасы дип саныйбыз. Тәүге тапкыр «Моңлану» җыентыгында (1991) дөнья күргән «Язлар быел соңга калды» әсәрен, стиль үзенчәлеге, образлар системасы, лирик герой яссылыгыннан карап, җитмешенче елларда язылган поэма жанрындагы тәүге тәҗрибәсе булырга тиеш дип фаразлыйбыз. Тупланмадагы текстларның, нигездә, язылу вакыты тәртибендә урнашканлыгын да исәпкә алсак, әлеге фикеребез тагын да ныгый. «Язлар быел соңга калды»да шагыйрь лирик миннең туган җиренә, иленә Мәхәббәтен фәлсәфи планда, хис-кичерешләр эзлеклелегендә сурәтли. Герой үзен гел кошлар янәшәсенә куеп карый, аның өчен торналар, сыерчыклар, карлыгачлар туган җир белән бәйләүчеләр, хакыйкать эзләгән диңгезченең аңа әманәтен илтүчеләр, серләрен тыңлаучылар булып тора. Әсәрнең сюжеты юк, анда фикер үстерелеше генә күзәтелә, ул күләмле лирик шигырьгә якын тора һәм аның лирик поэма дип аталуы шартлы.

Р. Әхмәтҗанның «Исәннәр моңы»ның композициясенә һәм эчтәлегенә соңрак сизелерлек үзгәрешләр кертүе аның лиро-эпик жанрдагы тәҗрибәсеннән канәгать калмавын күрсәтә. Шагыйрь хәтта уңышлы башланып киткән сыман беренче строфаны ук үзгәртә: вакыйга-күренешләргә килеп керүне инде гомуми сүздән түгел («Кояш баткач, / Кем эзләми икән / Күңеленә якты бер кыйбла»), туп-туры ситуациядән башлый («Җилкапкасын шакымыйча гына / Узып киткән булсам ни була…»). Яңа вариантта күзәтелгән эреле-ваклы яңалыкларның барысы да поэманы камилләштерүгә, анда барган хәрәкәтне эзлеклерәк итәргә, ге-

ройларны үзара ныграк бәйләргә булыша. Җитмешенче еллар ахырында әсәрнең хикәяләүче герое ятимә апа белән очрашса, яңа вариантта әби кешенең сугышта югалган сөйгәне Рәхимҗанга бәйле хәсрәтләрен, уйларын уртаклаша. Ләйсәннең егеткә сөйләгәннәре шактый үзгәреш кичерә, озынайтыла. Икенче версиянең башлам өлешендә төрле лирик геройларга караган текстлар аерып куела, кушылып китми, шул сәбәпле эчтәлек җиңелрәк аңлашыла. Рәхимҗан хатына кергән үзгәрешләр, баш өлешнең традицион калыпка якынайтылуы, «Басыйр бәете»нең кыскартылуы шулай ук поэманың сәнгатьчә эшләнешенә уңай тәэсир иткән.

«Исәннәр моңы»нда Ләйсән һәм аңа гашыйк Рәхимҗан белән Басыйр исемле ике дусның үзара мөнәсәбәтләре һәм илдә барган вакыйгалар белән тыгыз үрелгән язмышлары үзәккә куела. Рәхимҗан сугышта үзен батырларча тота һәм вафат була, ә менә Басыйр, сөйгәне хакына дип, үлемнән качып калырга тырыша һәм исән кала. Туган авылына исән-имин әйләнеп кайтса да, аның гомер юлы Рәхимҗанны оныта алмаган Ләйсәннеке белән кушылмый. Куркаклыгы фаш ителгән Басыйр өчен яшәү газапка әверелә. Поэманы камилләштергәндә, Р. Әхмәтҗанов, текстның тәэсир көчен арттыру максатыннан, Басыйр хисләрен тәфсиллерәк сурәтли, аның җан газабын тирәнәйтебрәк күрсәтә. Халык өчен яшәү, бар көченә илгә хезмәт итү, авыл кешесенең тормышын кайгырту да ир күңелендәге авыр хисләрне тоныкландырмый. Бер караганда, Басыйр – чын мәгънәсендәге тискәре герой да түгел. Ул сугышка барган, фашизм белән көрәшкән, әмма хәлиткеч моментта дошманга каршы граната тотып ыргылмаган һәм шул сәбәпле «хыянәтче»гә әверелгән. Дусты Рәхимҗанның рухы (фантомы), әнә шуның өчен, аның ике ярны кушып салган асылмалы күпереннән дә чыгарга теләми.

«Исәннәр моңы»ның фольклор белән бәйләнешләре тыгыз. Рәхимҗанның Ләйсән күңелендә сакланган такмагы, сугыш чоры җырлары кабатланып килеп, поэманың тәэсир көчен арттырган, тормышчан иткән, бүгенгене узган белән бәйләүдә катнашкан. «Исәннәрнең моңы булып җир өстендә йөргән» Моңлы аваз сүзләре дә шул ук вазифаларны башкара. Автор поэмада борынгыдан килгән гадәт-йолаларны – авыл халкының асылмалы күпер янында күрешүләрен, озатып калу, каршы алуларын, ераклардагы якыннарын, хәвефкә тарганнарны дога-теләктә көтүләрен җанландыра. Ике гашыйк татар егетенең язмышы һәм матур әдәбиятта, һәм фольклорда чагылыш тапкан Мәҗнүн, Таһирларныкына янәшә куела. Әсәрдән шул аңлашыла: Ватан иминлеге өчен көрәш барганда чын ир кеше, хәтта сөйгән ярлары белән күрешү хакына да, үлемнән качып калырга, яу кырында үзен куркакларча тотарга тиеш түгел.

Сугыш чорларының кайтавазын тасвирлаган, үткән һәм бүгенгене кушкан, мәхәббәт һәм нәфрәт, дуслык һәм аңа хыянәт,

батырлык һәм куркаклык турында уйлаткан лирик-драматик «Исәннәр моңы» укучыда артык зур уңыш казанмый. Р. Әхмәтҗановның 2014 елны дөнья күргән икетомлыгында язылу вакыты 1988 дип билгеләнгән «Карачкы» поэмасының да, идея эчтәлеге тирән булса да, сәнгати яктан шагыйрь мөмкинлеге дәрәҗәсендә язылмаган сыман. Әлеге поэмада узган гасыр дәвамында ил, халык башына төшкән хәсрәтләр, тарихи-сәяси вакыйгалар аерым кеше язмышы, гаилә тарихы аркылы яктыртыла.

Фольклордан килгән элементлар «Карачкы»да тагын да күбрәк. Әсәр беренче битләреннән үк халык йолаларын, гадәтләрен, татарның уйлау-яшәү рәвешен сөйли башлый. Р. Әхмәтҗанның махсус рәвештә үзенчәлекле исем бирелгән Шигърия ханым фал ачып, авылга кайтып төшкән «Карачкы»ның кемлеген белә һәм сугыштан чит милләт кызына өйләнеп кайткан Төрек Садыйгының киләчәгеннән дә хәбәр бирә: «Фал китабын яба Шигърия, / Әллә ниләр тагын күренер. / Әнә анда Караком чүлләре, Мари урманнары... / Һәм Себер!» Болай эшләп, автор укучысының тарихи хәтерен яңарта һәм аны тасвирланачак вакыйгаларны кабул итүгә әзерли.

Поэма берничә үлчәмдә язылган, әмма алар катгый рәвештә сакланмый, шул сәбәпле ритмика бозылган урыннар шактый. Бу, үз чиратында, строфаларны авыр укылышлы итә. Шагыйрь кайвакыт, ритмик буыннарны калдырганда да, махсус эффект өчен, аларны юлларга төрлечә бүлә, һәм строфаларның аһәңенә үзе теләгән яңгыраш бирә. Фикергә, теге яки бу күренешкә, үзгәрешкә игътибарны арттыру максатыннан ритмиканы бозу очраклары да юк түгел. Боларын инде Р. Әхмәтҗан кулланган махсус алым дип карарга кирәк. Түбәндә аның уңышлы мисалын китереп узыйк:

Йокламый карачкы.
Күз йомса,
Йөрәге ыңгырашып уята.
Йөрәге кычкырып уята.
Таң ата.

Поэмага әледән-әле «Идегәй» үлчәмен һәм аның поэтик сәнгати алым-чараларын файдаланып язылган өзекләр килеп керә. Нәкъ менә «Карачкының шәҗәрәсе»нең дастанны искә төшертерлек иҗат ителүе – авторның зур табышы. Белгәнебезчә, «Идегәй»нең Туктамыш белән таныштыру өлеше – санау аһәңе дә булган тыныч хикәяләү тонында башлана, аңа әкренләп янәшәлекләр, каршылыклар үтеп керә. Инде «Карачкы»га мөрәҗәгать итик:

«...авыл саен бер галим,
Сабагыңны ал, бала.
Мөгаллимнең һәр сүзен
Күңелеңә сал, бала.

Күренмәсне – күрергә,
Табылмасны – табарга,
Югалганны юлларга
Өйрәтте ул аларга.

Татар мөгаллименең кемлеген, илгә нинди хезмәт башкаруын сөйләүдән этәрелеп китеп, шагыйрь халыкның борынгыдан килгән эчке тарткалашлары, шул

сәбәпле бүленеп, таралып бетүе, дошманнан җиңелүләре, җитмәсә, талаучыларның да «бар асылны сайлау»лары хакында сөйли. Поэмада «Идегәй» белән тирәнгә яшеренгән бәйләнешләр еш тоемлана. Идел буенда барган сугышларга ишарәләүче юлларны, төрле гыйбрәтле сүзләрне укыганда, Идегәй тавышы ишетелгән кебек, аның кисәтүләре-киңәшләре искә төшә:

Ил таланып таралса,
Ташларына куй башың…
Бәхетеңне табыша
Урланмаган Кояшың!

Әсәр үзгәртеп кору елларында язылса да, анда метафорик, яшеренеп әйтелгән карашларга биниһая зур урын бирелгән. Әлеге күренеш, шагыйрьнең һаман да саклануына, хәл-күренешләрне, вакыйгаларны турыдан-туры сөйләп чыгу һәм фикерләрен ачыктан-ачык әйтеп бетерү кебек җиңел юлдан китмичә, образлы җиткерү омтылышына бәйле. Бу урында, бигрәк тә чит милләт кешесе яисә бүгенге укучы эчтәлекне яхшырак аңласын өчен, поэма эчтәлегенә сизелерлек үзгәрешләр кертергә кирәклекне дә әйтик. Автор һич югы «Карачкы»ның кайларда сугышуын, кай яклардан өйләнеп кайтуын аз гына булса да тәгаенләштерсә, томанга төреп бирмәсә, әсәрнең эчтәлеге ныграк, дөресрәк аңлашыла. Сугыштан ияреп кайткан киленне төрекләр төрекмәннәрдән кергән дип санаган һәм шундый ук әйтелештә очрамаган Әмен дип атау да отышлы түгел. Әлеге исем, поэманың аерым өлешләре, анда чагылыш тапкан һәм нигездә Төрекмәнстан территориясен биләгән Караком чүле, башка кайбер детальләр героиняны, төрек гүзәленнән дә битәр, төрекмән кызы дип күзаллата. Дөрес, поэмадан кызның Ватаны Төркия дип күрсәтелә: ул хакимият тарафыннан шунда яшәгән туганнары белән хат алышуда гаепләнә. Садыйкның кайсы сугыштан өйләнеп кайтуын ачыклау өчен, тарихны яхшы белергә, поэмадан төрле җиргә сибелгән фактларны җыеп берләштерергә, уйлап утырырга кирәк. Әсәрне уку барышында җавабы табылмаган күп сораулар туа. Мәсәлән, Карачкы утызынчы елларда авылдан сөрелә, сугыш башлана, Әмен әле – имчәк бала белән генә…

«Карачкы»ны кайбер ноктадан камилләштерү зарурлыгы таләп ителсә дә, идея эчтәлеге белән, биргән гыйбрәте һәм киңәшләре белән, ул гаять тирән язылган. Анда сүз узган гасырда СССР дигән илдә яшәгән халыклар кичергән авырлыклар һәм әлеге авырлыкларның махсус тудырылуы, кеше гомеренең бәһасез булуы, һәркемнең куркыту-җәзалау этапларын узуы турында бара. Халык бәхете өчен дип, миллионнар гомере хисабына төзелгән илдә эчке сәясәтнең юнәлешен һәркемнән дошман эзләү һәм аны юк итү, кешене ачлык, хәтта көче җитмәгән хезмәт белән юкка чыгару һәм башка шундый яман күренешләр билгели. Әсәрне Ватанын, ирен сагынып яшәгән, совет кешеләре белән бергә тормышның барлык авырлыкларын кичергән,

баласын исән калдырырга дип кырдан алып кайткан бер уч башак өчен Себергә сөрелгән Әмен кичерешләре, ач, әтиле килеш ятим булган баланың елаулары бик тәэсирле итә. Кеше драмасын тудыруга автор тәфсилле тасвирлар, чагыштырулар, мөмкин булганның каршысына, янәшәсенә көтелмәгәнне, ышанасы килмәгәнне кую, ярашмаганны яраштыру, сыймаганны сыйдыру һәм башка алымнар ярдәмендә ирешә:

Дөньямның җылысы калган
Әнкәм учакларында,
Тәмугка китеп барганмын
Егет кочакларында…

Күрәбез ки, мисалда җылының төрле зурлыктагысы, дәрәҗәдәгесе (учак, дөнья җылысы, тәмуг) искә алына, алар ярдәмендә гадәти күзаллаулардан читкә чыккан күренешләр тасвирлана; «Кочакта тәмугка бару» исә бөтенләй акылга сыймаслык фикер йөртү рәвешендә кабул ителә, һәм болар Р. Әхмәтҗановның укучыны сискәндереп җибәрерлек сәнгати табышлары булып тора. Поэма сөекле хатынын, улын, күпсанлы авылдашларын югалткан «Карачкы»ның Әмен каберенә барганда яшәү, үлем, тормыш кануннары, иҗтимагый үзгәрешләр турындагы уйларын сөйләү белән тәмамлана.

Узган гасыр ахыры татар халкының үткәненә, бүгенгесенә, киләчәгенә бәйле кыю фикерләрен, хыял-омтылышларын сәнгатьтә, вакытлы матбугатта чагылдыру мөмкинлекләре тудыргач, Р. Әхмәтҗан каләме иҗтимагый-сәяси-тарихи юнәлештә тагын да активлаша. Шагыйрь тарихи үткәнне бары тик эпик әсәрләрдә, күләмле текстларда гына киң һәм тирән, тәфсилле чагылдырып, ягъни чын мәгънәсендә ачып булганны аңлап эш йөрткән. Ул, чор алып килгән мөмкинлекләрнең вакытлыча гына булуын фаразлагандай, ашыгып-ашкынып, поэмалар яза. Рәшит Әхмәтҗановның, алда телгә алынганнардан тыш, Үзгәртеп кору елларының башында ук иҗат иткән «Бишташ» (1987), «Аучылар кибетендә» (1988) һәм язылуыннан күпкә соң басылган «Карга каргышы» (2001) әсәрләре бар.

Лиро-эпик мирасы шактый булса да, Р. Әхмәтҗановны чын мәгънәсендә поэма остасы сыйфатында «Бишташ» таныта, һәм ул шагыйрь иҗатында, чыннан да, яңа этап башлануны сөйли. «Бишташ» 1987 елда «Казан утлары»ның дүртенче санында басыла, шунда ук әдәби җәмәгатьчелектә югары бәясен дә ала. Аны укыйлар, өйрәнәләр, югары уку йортларының уку планнарына кертәләр, аның турында сөйлиләр, язалар һәм поэма Р. Әхмәтҗанның иң билгеле әсәренә әверелә.

«Бишташ» Р. Әхмәтҗанов поэзиясен яңа ассоциацияләргә, читләтеп әйтүләргә корылган троплар белән баета. Моннан тыш, шагыйрь иҗатында элек күренгән образлар да яңа контекст эчендә бөтенләй башкача ачылып китә. Шуларның иң калкуы – таш образы. Р. Әхмәтҗановның тулы бер иҗатын таш концепты ноктасыннан тикшереп, күләмле монография язарга мөмкин. Әлеге образның

шагыйрь иҗатында актив кулланышта йөрүен тормышының бер этабы, шул этапта үзләштергән һөнәре белән генә бәйләп карау дөрес булмас. Шунысы хак: Р. Әхмәтҗан – татар поэзиясендә әлеге образны сизелеп торырлык күп һәм төрле мәгънә эчтәлеге салып кулланучы. Таш Р. Әхмәтҗановта символ да, метафора да, әдәби деталь дә булып килә һәм шәхеснең, милләтнең рухи-матди яшәешен, тормыш фәлсәфәсен тирәннән ачуга хезмәт итә. Әлеге образны куллану ешлыгы, аңа йөкләнгән мәгънә төрлелеге һәм контекст үзенчәлеге ноктасыннан чагыштырганда, башка һичбер шагыйрь Р. Әхмәтҗан белән ярыша алмый сыман.

Таш дөнья әдәбиятында тарихи хәтерне чагылдыручы образ буларак билгеле. Шул ук вакытта ул ныклык, көч, тотрыклылык һәм башка күпсанлы мәгънәләрне аңлата. Аларның һәрберсе Р. Әхмәтҗан поэзиясендә чагылыш тапкан. Дөрес, шагыйрь тормыш авырлыкларын, шул авырлыкларны күргән башларны, кешене таштан да катырак-ныграк саный, һәм каты көнелләрне дә йомшаткан хатын-кыз, мәхәббәт барлыгын, ташларны да елатырлык югалтулар күплеген дә сөйли:

* * *

Таш дисеңме? Ташны бит мин каты димим,
Әллә башка катылыклар күп күргәнгә.
Сине уйлап уелам да, һәм кинәттән,
Нәфис чәчәк булып калам мин бер мәлгә.
/…/
Дус чәчәкләр күптән шиңде.
Күзәтәм мин
Йөргәннәрен яфракларның күктә очып.
Берсе әнә мәңгелеккә ятып калды,
Болындагы таудан төшкән ташны кочып.
Аны җәлләп таш елармы, таш эрерме?
Калганнары күктә очып күп йөрерме?

Мөселман әдәбиятында таш төшенчәсенең изге кәгъбә ташына, шайтанны куу һәм гөнаһлыларны җәзалау йоласына яисә күктән җәза рәвешендә төшкән яшен ташына бәйле эчтәлекләре дә бар. Р. Әхмәтҗанның «Синме?» әсәрендә бу яссылыктагы күчемлелек күзәтелә: «Һәм бар кеше бер кешегә таш бәргәнне – / белмәдеңме?». Соңгы чор әдәбиятларында да таш, еш кына, җәза коралын, урынын (таш зиндан) белдерә, кешенең үлеме (кабер ташы) турында сөйли. Р. Әхмәтҗановның «Шигыремнең күчермәсен сорый» әсәрендә мондый юллар бар: «Таш төрмәне / Кабер ташлырына / Бүлгәләсәң, җитми калыр күк». Авырлыкка дучар булган татар кешесе, бәгыремә таш утырды, ди. Тормышның башка күренешләренә дә таш төшенчәсе ярдәмендә мөнәсәбәт белдерүче әйтем-мәкальләребез шактый. Әйтик, «башка таш яудыру» кебек гыйбарәне шагыйрь үз әсәренә шушы рәвешчә трансформацияли: «Хакыйкатьне җанда яшәткәнгә, / Ташлар ява төнлә тәрәзәмә». Исламгача таш табигать һәм ирлек көчен чагылдырган. Ул башка халыкларда да табыну объекты: аннан ир һәм

хатын-кыз мөнәсәбәтләренә, җан ясаучы көчкә ишарәләүче фигуралар гәүдәләндерелгән, таштан пирамидалар корганнар, шулардан бигрәк тә караларын чиктән тыш изгеләштергәннәр. Күктән иңгән ташлар, бигрәк тә каралары түбән һәм югары дөньяны бәйләүче чара булып торган. Кыскасы, Р. Әхмәтҗанов кебек рухи ныклыгы, көрәшчелеге белән дан тоткан ирләр шигъриятендә таш лексемасының гаять күп кулланылуы табигый.

Таш концепты Р. Әхмәтҗанның күбрәк тирән фәлсәфи эчтәлектәге әсәрләрен бизи, теге яки бу уй сөрешен тудыруда, фикерне җыйнаклауда, бер ноктага туплауда катнаша. Белгечләр, таш, тау, агач, кыя һәм кайбер башка предметлар, символ буларак, үзара береккән, ди. Әлеге бәйләнешне тагын да киңәйтергә булыр иде. Бу күренеш Р. Әхмәтҗан әсәрләрендә дә очрый. Тау – яр – чуерташ – тауташ образларының үзара бәйләнешләренә бер мисал: «Тауларга менсәм дә уй килә»; «Ярларга таянып торсам да»; «Нәп-нәни чуерташ ясадым»; «Таш белән бәрдем мин, таш белән» («Ак гөнаһ»). Р. Әхмәтҗанда таш һәм су янәшәлеге (чуерташ – инеш, таш яр – елга, кыя – диңгез; таш – тамчы, таш – ташкын...) аеруча еш күзәтелә: «Тиздән, улым, / сайрар кошлар кайтыр / Диңгезләрнең ташлап таш ярын»; «Нинди генә ташкын бәрми миңа, / Нинди генә ташлар бәрелмиләр!» һ.б. Шагыйрьнең таш төшенчәсен кулланып ясаган метафора-символлары арасында үтә оригинальләре бар: «Ил ташына – тау башына / Ак болытлар куналар» һ.б.

Р. Әхмәтҗан поэзиясендә таш шулай ук гөл, баш, кала, янартау, яшь, уй һәм башка образлар белән дә оядаш булып килә: «Ташны каты димим, /…/ Чәчәк булып калам мин бер мәлгә», «Таш өстендә гөлләр…». Шагыйрь үзара береккән образлар ярдәмендә (уй – дулкын – таш) бөтенләй көтелмәгән ассоциацияләр тудыра; хәтер, үч, уйларның символы булган ташның төрләре аларны күләм ноктасыннан яисә башка яктан сыйфатларга да мөмкин:

Йөгерек-йөгерек дулкыннарда
Йөгерә генә күңел.
Күңелдәге чуерташлар
Бер дә җиңелдән түгел.
/…/ Уйларым ага-ага да
Тирән суларга бата.
Я, дулкын бәргән балык күк,
Яр ташларына ята.

(«Йөгерек-йөгерек дулкыннарда»).

Чираттагы мисалда, әйтик, таш һәм баш көрәшче герой кулындагы корал-чарага әверелә, без лирик мин уенның һәм гамәленең үзара бәйләнгәнлеген күрәбез: «Таш белән бәрдем мин, таш белән, / Баш белән бәрдем мин үлемгә». Р. Әхмәтҗанов «Бишташ» поэмасын язуга әнә шулай – таш төшенчәсеннән еш һәм даими файдалана-файдалана, аның ярдәмендә нинди зур проблемаларны күтәреп була дип уйлана-уйлана килә, еллар дәвамында бу юнәлештә тәҗрибә туплый.

«Бишташ» атамасы таш символының поэмада төрле яссылыкларда ачыласына һәм текстның

композицион үзенчәлекләренә (төп бүлекләр санына) ишарәли. Эпиграф һәм «Поэмага чакыру» дип исемләнгән Кереш исә укучыны әсәрдә барачак вакыйгакүренешләрне кабул итүгә әзерли. Әлеге Кереш һәм соңгы структур кисәк «Поэма белән саубуллашу» поэмага бөтенлек рәвеше бирә. Шагыйрь сайлаган төзелеш борынгы татар әдәбиятындагы тартмалы композицияне искә төшерә. Әсәрнең Кол Галидән алынган эпиграфы логикага сыешмавы белән сискәндерә: «Таш батмыйча, / Су өстендә йөзеп йөрде...». Урыс баскыннарын Болгарга яу белән чабудан туктату, янәшә территориядә көн иткән халыкларны дуслыкта яшәтү максатыннан төзелгән илара шартнамәдә, судагы таш өскә калыкса һәм колмак суга батса гына ике ара бозылыр, дип әйтелгән була. Димәк, бүгенгенең шагыйре дә әлеге шартнамәдә бирелгән вәгъдәләрнең тарих дәвамындамы, бер чордамы бозылганлыгы хакында сөйләргә тели. Ташның суда батмавыннан хәбәр сөйләнәчәк ситуацияләрне алдан ук гиперболалаштырып җибәрә.

«Бишташ» рефлексияләр нигезендә һәм шагыйрь автобиографиясенә таянып иҗат ителгән. Әсәрдә үткәннәргә әйләнеп карау зур урын алып тора. Бу «Поэмага чакыру» өлешендә үк ачык сизелә. Лирик герой анда яшьлегендә Әлмәткә килүе, үзенә яңа дөнья ачуы, уйга салырлык, хәтердә калырлык тормыш тәҗрибәсе туплавы турында яза:

Каршылады Әлмәт мине,
Ташларына ташлар бәреп,
Ул ташларны җыя килдем,
Куя килдем мин күтәреп
Күңел дигән корабыма,
Җаныма – җыр кәрваныма…
Тау кадәрле йөк төядем
Үз аңыма,
Дәрманыма.

Лирик герой, үзен башкалар белән чагыштырып, корган оям нигезендә ташлар ята, ә кемнекендәдер башлар ята, дигән нәтиҗәгә килә. Таш образы Кереш өлештә туры мәгънәсендә дә аңлашыла, ә читләтеп әйтелгән мәгънәләрен (кайгы, шатлык, корал…) авырлык төшенчәсе белән гомумиләштерергә мөмкин. Әйтик, югарыдагы өзектән, күргән авырлыклардан үзем – карашларым да формалашты, дигән фикер дә аңлашыла. Нигез ташын культлаштыру, таш йортны тотрыклылык символы итеп күзаллау, агачын исә таш нигезгә утырту… Болар борынгы кешенең нигез ташына бәйле ышануларының, йолаларының бик азын гына чагылдыра. Фәлсәфилеккә зур урын биргән, милли фольклорны һәм дөнья сүз сәнгате традицияләрен яхшы белгән Р. Әхмәтҗан шигъриятендә нигез ташы яңа тирән мәгънә ала. Бик борынгыда барлык халыкларда да йорт, кирмән, сарай салганда, гомерле булсын, хуҗаларының, халыкның гөнаһлары кичерелсен яисә бөтен дөнья сафлансын һәм яман көчләргә бирешмәсен дип, нигезенә кемне дә булса күмеп калдыру традициясе булган. Р. Әхмәтҗанов аннан шулай ук бөтенләй яңача файдалана:

Таш астына салсам да мин
Җанның сыгып кайгыларын,–
Онытмагыз түбә астында
Мәңге гашыйк йөрәк барын.

«Поэмага чакыру»дан лирик геройның, бөтен тормышын яңадан кичереп, ниндидер нәтиҗәләр ясау өчен, уйлануларын балачактан башлаячагы һәм сүзнең гомер ахырынача дәвам итәчәге аңлашыла. Шагыйрь әсәренең башында «биш моңайдым» җөмләсе ярдәмендә сөйләнәсе сүзләрнең сагышлылыгы хакында, ә иң соңгы строфада «Биш шигъри йөзегемә / Җем-җем кашлар куярмын» юллары аша поэманың гүзәллегенә ишарәли.

«Беренче таш» нигез ташларының тарихи таш – «Ил хәсрәте иңгән таш» икәнлеген ача. Кайбер халыклар Дөнья үзәген таш формасында күзаллаган, кешене ераклардан таш белән килгән матдәләрдән яралган дип фаразлау бар. Р. Әхмәтҗанов исә укучыны, Ил үзәген нигез ташы тәшкил итә, татарлар өчен бу болгар баба нигезенең ташы, дигән фикергә алып килә. «Беренче таш»ның татар әдәбиятындагы гүзәл әсәрләр белән күзгә артык бәрелмәгән бәйләнешләре бар. Х. Туфанның «Сөйли торган материя»сендә лирик мин үзен матдә дип атый, матдә буларак сөйләшә һәм бик борынгылыгын шушы рәвешчә яза:

Ераклардан, галактикалардан
Без бу җиргә бергә килдек ич,
Без матдәнең безне тудырачак
Потенциаль көче идек ич.

Р. Әхмәтҗан поэмасының беренче бүлегенә куелган эпиграфта таш телсез калган иң борынгы материя дип аталса да, сюжет башында ук телгә килә һәм ташның кеше кулында ничек итеп табыну объектына, сугыш-җиңү-яулау-җәзалау коралына әверелү тарихын ачып бирә. Бу, шулай ук, ташларны тоемлы кеше ишетә ала, чөнки алар узганнан мәгълүмат саклый дигән ышануга барып тоташа. Ташбалта ясаган кешене шагыйрь тагын Х. Туфан иҗатыннан алынган юллар белән хуплата: «Талантлы син, Кеше туганым!». Бу юлларда бераз ирония тоемлана. Р. Әхмәтҗан поэмасы, инсанның булдыклылыгы, акылы тормышны бизәүгә, үзе һәм башкалар бәхетле, мул һәм җиңел яшәсен өчен хезмәт итәргә тиешлеген, әмма Кеше үз тарихының башында ук, ташның авырттырып бәрү һәм кисү сыйфатларын күреп алгач та, аннан күршеләрне юкка чыгару, байлыкларын талауда файдалану кирәк, дигән фикергә килүен сөйли. Талантлы кеше уйлап тапкан корал инде шул заманнарда ук аның үз башына җиткән булып чыга.

«Икенче таш»та алдагы мотивлар тагын да киңәйтелә, тирәнәйтелә. Тарихилык мәгънәсен дә югалтмаган таш инде кабер, залим, туган җир ташлары булып аңлашыла. Алар үзара береккән төшенчәләр: Туган җирне каплаган кабер ташлары астында залимнәр дә, халыкны аларның золымыннан яклаган шагыйрьләр дә ята. Бүлекнең төп фикере эпиграфтан ук аңлашыла: «Тик шагыйрьләр яклаганга гына, Җирдә исән калдык, күрәсең». Бу бүлектә үз халкын тәмам юкка чыгудан саклап калган Кол Гали образы легендаларга таянып җанландырыла, аның сүзләре ярдәмендә, бомбаларга каршы тормаса, кешелекнең үк юкка чыгарга

мөмкинлеге искәртелә. Димәк, кеше таланты ярдәмендә таштан берьюлы күпләп үтерүче корал ясауга ук ирешелгән. Болар изге китаплардагы Адәм белән Хаува риваятенә барып тоташа. Алар, Тормыш агачы белән кызыксынасы урынга, Танып белү агачына йөз белән борыла һәм Эдемнан куыла, мәңге яшәү мөмкинлеген югалта, аларга хезмәттә узачак Җир тормышы язмышы бирелә.

Икенче ташны, бүлек эчтәлегеннән чыгып, яклау яисә туган җир ташлары дип гомумиләштерергә мөмкин, ә менә өченче бүлектә тасвирланганы зәһәр ташы кебек кабул ителә. Ходай Оҗмахтан куылган Адәмгә, син яхшылыкны да, явызлыкны да беләсең инде, ди. Димәк, алар – кешенең булырга һәм берсе өстенлек итәргә мөмкин ике сыйфаты, әмма җан ияләре, еш кына, явызлыкны сайлый. Бу бүлектә елан турында борынгыдан килгән риваять бар. Белгәнебезчә, аңа бәйле ышанулар да күп. Сөйләшә торган елан Адәм белән Хауваның гөнаһ кылуында зур роль уйный, чөнки кешенең үлемсезлеген үзенә хәйләкәрлек белән тартып алырга тели. Р. Әхмәтҗан поэмасында Җәһәннәмнән чыккан янартау күккә зәһәр ташын ата һәм аны елан йота. Җир асты көчләре белән бәйләнештәге һәм үтерүче булган елан авызындагы таш кеше өчен куркынычка әйләнә. Шагыйрь бу урында тагын тормышның капма-каршылыклардан торганлыгын искәртә, яхшылыкка – яманлык, дуска – дошман, тынычлыкка – сугыш булган кебек, нәфрәт янында мәхәббәт яшәгәнне әйтә:

Картлыктан кимеми
Еланның зәһәре.
Зәһәре – җирдәге
Мәхәббәт кадәрле.

Р. Әхмәтҗанов мәхәббәтне гөл образы аша чагылдыра, еланны Җирне күмгән гөлләр җиңгәнне әйтә. Гүзәллекне, яшьлекне, бәхет-сөенечне һәм башка төшенчәләрне аңлаткан әлеге образ шагыйрь иҗатында шулай ук актив кулланышта. Шулай итеп, өченче бүлектә таш, җәһәннәм, янартау, язмыш ташы мәгънәләре янәшәсендә, мәхәббәтне дә аңлата, чөнки әлеге хис-көч нәфрәт ташына каршы куела. «Дүртенче таш»та исә бәхет, иркәләү, өлеш һәм көрәш ташлары турында сөйләнә. Лирик мин белән очрашкан танышы, халык акылы һәм тәҗрибәсе тупланган мәкальләргә каршы килеп, ташка аш белән бәрмәскә, ә халыкны яклап көрәшергә чакыра. Алдагы бүлекләрдә сүз туган илне, туган җирне саклау турында барса, монда алар янәшәсенә ана телен яшәтү мәсьәләсе дә килеп өстәлә.

Бишенче таш – үлемгә каршы тору ташы да, бакчаныкы, гөлләрнеке, шагыйрь каләменеке дә… Бүлек ахырында аны Р. Әхмәтҗанов, үлемгә бәрсә генә, шагыйрь каләменә сөрмә булачак яшен ташы, дип атый. Бу кисәктә автор, Туфан әсәрләрендәге мотивларны гына файдаланып калмый, сюжетка аның үзен дә алып керә. Ташлар санындагы авырлыклар күреп – «биш кыямәт кичеп» туган җиренә кайткан шагыйрь ул. Туфан, халыкның, лирик мингә, «Бер алманы бишкә бүләек» дигән җыры аша, бер-берегез өчен үләргә әзерме,

дигән сорау куйганлыгын аңлата. Гомере буе таш кискән, таш җыйган, таш бәрүләргә түзгән, «күз яше ташка әйләнгән» Туфан лирик мингә якыная, чөнки Әлмәттә өч көн ташчы булып эшли.

Биш санына еш мөрәҗәгать итсә дә, балачакта уйнаган уенда шул сандагы таш кына кулланылса да, көрәшкә әйдәгән сүзләр поэманы тәмамлый алса да, Р. Әхмәтҗанов «Тагын бер таш» турында яза, әйтерсең, шуның белән лирик геройга, шагыйрьләргә, гомумән, татар халкына киләчәктә бәреләчәк ташларның чиксезлеге турында әйтергә тели. Бу бүлеккә эпиграф куелмаган, чөнки алдан аның хакында язылыр дип фаразланмаган, эчтәлеге һәм төзелеше алдан уйланылмаган:

Тәмамлыйм дип торганда
Җырымны – «Бишташым»ны –
Кем кулыдыр таш атты
Тәрәзәмә…

Берәүнең үчлекләнүе, шагыйрьне уйларыннан бүләргә теләве аның хәтерен кабат яңартып җибәрә. Ул милләте узган хәсрәтле елларны исенә төшерә һәм таш образын бөтенләй яңа шигъри контекстларга кертә, авыр елларда таштан аш кайнаткан аналар хакында яза, халык сөйләмендә, иҗатында урын алган ташка бәйле фикерләрдән чыгып, укучы алдына сораулар куя: «Ни ул – ташка табыну, / Ни була – таш ябыну?».

Язмабызда таш образына салынган барлык мәгънәви йөк, аның төрле ышанулар белән бәйләнешләре, образның күчемлелеге тулысынча тасвирланмаса да, әмма шул килеш тә Р. Әхмәтҗановның аны оригиналь контекстларга трансформацияләве аңлашыла. «Поэма белән саубуллашу»да, мәсәлән, тәүге эпиграфтагы мотив бөтенләй башкача яңара: күп ташлар күтәреп авырайган герой суга батмый, чөнки аның җаны таш түгел. Шагыйрь халыкны үзен, илен, телен сакларга чакыра, турыдан-туры сәяси мөстәкыйльлек сүзен кулланмаса да, халыкны үз илендә иркле яшәве өчен көрәшкә әйдәве күренеп тора:

И Иделләр ага илләр буйлап,–
Рухи Кораб иңли киңлекне…
Янмый калганнарын суга сала
Кемдер көчләп таккан кимлекнең.

Әсәрнең аерым торган «Кулларымда һаман ташлар уйный…» юллары белән тәмамлануында да зур мәгънә бар: әлегә берсе дә атылмаган, җай көткән көрәш-җавап ташлары ул. Аларның атылуы-атылмавы иреккә ничек ия булуга бәйле. Автор белән тиңләштерергә мөмкин лирик герой, үткәннәргә әйләнеп карап, вакыйга-күренешләрне, эш-гамәлләрне тәнкыйди анализлауга, халкының көрәш тарихына, шул тарихта шагыйрьләрнең һәм, димәк, үзенең дә эш-гамәлләрен бәяләүгә сәләтле. Ул олыгайган саен рухи ныгый һәм камилләшә, үзенә үткәннән идеал итәрлек шәхесләр таба, яшәү һәм җан, милләтләрнең, илләрнең, Кешелекнең яшәү мәгънәсе турында гыйбрәтле нәтиҗәләргә килә бара:

Җан – синеке, Яшәү!
Сабый чактан
Таш өстендә чәчәк булырга
Өйрәттең дә... чиксезлегең хәзер
Ни хыялга сыймый, ни уйга.

Таш – дөньяның, мәңгелекнең, күккә ашкан тауларның, Җир шарының нигезе булса, җан һәм фикер – кешенең, кеше – аерым гаиләнең, гаилә – халыкның, халык – илнең, ил исә Җир шарының асылын билгели, ди шагыйрь. Тау-ташлар кешене югарыга өндәргә, үзен мескен һәм ким итеп түгел, ә ирекле шәхес, ирекле милләт баласы итеп тоярга чакырырга тиеш, дип аңлата:

Ташлы таулар югарыдан торып,
Иңдерәләр җанга зурлыкны.
Халкым башы түгел,
Хәтта җирнең
Ташы күтәралмый хурлыкны.

Р. Әхмәтҗан иҗаты XX гасырның икенче яртысында метафоралы фикер йөртүне гаять көчәйтеп җибәрде. Ул башта поэтик аллегорияне нечкә, кеше күңеленең төпләрендә яткан хисләр белән үрде, ә аннан көчле агымга тиң хисләр һәм фикер ташкыны белән кушты. Шагыйрь гиперболалы тасвирдан кыю файдаланды, поэзиябезгә күпсанлы яңа образлар алып килде, үзеннән элгәреләр кулланган тропларның мәгънә чикләрен сизелерлек киңәйтте, бигрәк тә таш концептыннан шигърияттә файдалануның мөмкинлекләре гаять зур икәнлекне күрсәтте.

## Әдәбият

*Әхмәтҗанов М.* Аучылар кибетендә // Соц. Татарстан. 1988. 13 август.

*Галиев М.* Тәңренең тамгасы белән // Рәшит Әхмәтҗанов. Әсәрләр: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 7.

*Галиуллин Т.Н.* Дәгъва. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. Б. 230–231.

*Зәйдуллин Р.* Ташларны җыяр вакыт // Татарстан яшьләре. 1987. 26 май.

*Рәшитов Ә.* Иман яңартканда: публицистика, тәнкыйть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 131–135.

*Фәйзуллин Р.* Нечкә хисле, батыр йөрәкле // Мәйдан. 2003. № 10. Б. 97–100.

***Харрасова Рифә Фәтхрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Э.Д. Рафикова*

# 1960–1980 ЕЛЛАР ТАТАР ПРОЗАСЫ Ф. МИҢНУЛЛИН БӘЯЛӘВЕНДӘ

В данной статье предпринята попытка анализа научных взглядов известного татарского литературного критика, публициста Ф.М. Миннуллина относительно татарской прозы 1960–1980 годов. В своих статьях критик определяет основные тенденции развития прозы этих лет, выявляет ведущие темы, жанры, а также приемы и средства, используемые писателями.

**Ключевые слова:** татарская проза, Ф. Миннуллин, тема, жанр, поэтика, национальная особенность.

Фәрваз Миңнуллин – XX гасырның икенче яртысында яшәп, әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче, публицист буларак киң танылу алган, хезмәтләре белән чор әдәби процессына зур йогынты ясаган шәхесләрнең берсе. Ул әдәбиятка XX гасырның алтмышынчы еллары башында килә һәм аның тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре шул елларда көндәлек матбугатта даими басылып бара. Ул күп еллар «Казан утлары» журналы редакциясендә хезмәт куя, Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре булып эшли, Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир вазифасын башкара. Ф. Миңнуллин әдәби барышны даими күзәтеп баручы, аның үсеш-үзгәреше һәм табыш-югалтулары хакында сүз әйтүче актив тәнкыйтьчеләрнең берсе була. Күзәтү характерындагы мәкаләләре, төрле буын язучыларның иҗат портретлары укучыга оригиналь фикерләре белән һәм үз чоры әдәбиятындагы актуаль проблемаларны күтәрүе белән кыйммәт.

Ф. Миңнуллинның әдәби тәнкыйть эшчәнлеге белән кызыксыну соңгы елларда көчәйде. Аның эшчәнлегенә Т. Галиуллин, Ә. Закирҗанов, Р. Харрасова, Ч. Гыйлаҗева, Д. Яруллина һ.б.ның язмаларында бәя бирелә, шәхес һәм тәнкыйтьче буларак аерым үзенчәлекләре күрсәтелә. Аерым алганда, Р. Харрасова болай дип яза: «Ф. Миңнуллин әдәби тәнкыйть өлкәсенә караган барлык төр, шул исәптән теоретик мәсьәләләрне дә күтәрә, әмма алар хакында күпчелеккә ерак академик фәнни стильдә язмый, теләсә кайсы социаль төркем вәкиле аңларлык, кызыксынырлык рәвештә иҗат итә» [Харрасова, б. 6]. Әлеге мәкаләдә без Ф. Миңнуллинның тәнкыйди эшчәнлегендә мөһим урын алып торган бер мәсьәләне – 1960–1980 еллар прозасын бәяләвен – өйрәнүне максат итеп куйдык.

Ф. Миңнуллинның мирасы, ягъни аның эшчәнлегендә аерым әһәмияткә ия төп басмалары түбәндәгеләр: «Якты юллар» (1975); «Прозаның гражданлык йөзе: бүгенге прозада повесть

жанры»(1983); «Талантлар юлы» (1984); «Затлылык» (1989); «Балта явызлар кулында» (1994). Үзенең мәкаләләрендә Ф. Миңнуллин бигрәк тә проза жанрына яратып һәм белеп мөрәҗәгать итә. Ул әдәби тәнкыйтьче буларак әлеге жанрны өйрәнеп кенә калмый, бәлки аның үсеш-үзгәрешен, төп көчләрен барлый, табыш-югалтуларны ачып сала һәм актуаль проблемаларны күтәрә, аларны чишү юлларын эзли. Проза жанры үзенчәлекләре аеруча «Реаль хәлләргә күз салыйк», «Прозаның гражданлык йөзе» һ.б. язмаларында һәрьяклап һәм тулы, җентекле өйрәнелә, бәяләнә.

1960–1970 елларда татар прозасы җитди үзгәрешләр кичерә. Бу төрдә Ә. Еники, И. Гази, М. Әмир, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Н. Фәттах, М. Мәһдиев кебек танылган әдипләр хезмәт итә. Проза әсәрләре тема һәм жанр ягыннан байый, сурәтләлекнең яңадан-яңа алым-чаралары табыла. Әдипләр иң яхшы әсәрләрендә соцреализм кысаларын үтеп, заман проблемаларын милли яшәеш белән бәйләп чагылдыралар, заман кешесен, гадәттә, милли геройны алгы планга чыгаралар. Җитди яңалык буларак, «авыл реализмы» үсеш кичерә. Ә. Еники, А. Гыйләҗев, В. Нуруллин, Ә. Баянов һ.б. әсәрләрендә татар авылы милләтне саклаучы төбәк, халыкның традицияләрен, гореф-гадәтләрен дәвам итүче изге урын буларак сурәтләнә. Шуның белән бергә, татар прозасы илкүләм мәйданда яңгыраш алмый. Тәнкыйтьче моңа җитди борчылуын белдерә һәм бер сәбәбен тәрҗемә эшенең тиешле дәрәҗәдә куелмавында күрә. Бу турыда ул: «Ил күләмендә яңгырау мәсьәләсенә килсәк, ул күп кенә башка сәбәпләргә, күрә һәм күрсәтә, аңлата белүгә, барыннан да бигрәк, әдәби тәрҗемә эшенең торышына барып тоташа» [Миңнуллин, 1989, б. 6], – дип яза. Моңа мисал итеп М. Мәһдиевның «Фронтовиклар» романын китерә. Тәнкыйтьче күзлегеннән караганда, рус теленә тәрҗемәдән соң, әлеге әсәр үзенең кыйммәтен югалта. Ә менә Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы, киресенчә, танылган язучы В. Чивилихин кулына эләгеп, рус теленә тәрҗемә ителгәннән соң, киң яңгыраш ала. Рус теле аша илебез халыклары һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителә. Әсәр төрле мактаулы исемнәр яулый, укучылар тарафыннан яратып укыла.

Әлеге чор проза әсәрләренең бер үзенчәлеге итеп Ф. Миңнуллин аларга ил күләмендә барган вакыйгаларның зур йогынты ясавын атый: «Халыклар һәм илләр арасындагы бәйләнешләр нык көчәйгән бүгенге көндә язучыдан тирән белем, киң колачлы иҗат кешесе булу сорала. Сәнгать турында, матур әдәбият әсәрләре турында сүз йөрткәндә, без аларны тормыш белән бәйләнештә карыйбыз, аларга шул ноктадан чыгып бәя бирәбез. Язучылардан без тормышчан тема һәм проблема, тормышчан сюжет һәм тормышчан вакыйгалар, тормышчан образлар таләп итәбез» [Миңнуллин, 1989, б. 8]. Чыннан да, язучылар илдә барган җитди иҗтимагый-социаль, тарихи,

мәдәни үзгәрешләрдән, бигрәк тә шул чордагы фән-техника прогрессы тудырган казанышлардан читтә кала алмыйлар. Илдәге үзгәрешләр, әлбәттә, укучыга, аның аңына да тәэсир итә, ягъни шул чор укучыларының да ихтыяҗлары үзгәрә дигән сүз. Шуңа да бу чорда иҗат иткән язучылар эзлекле рәвештә заманга яраклы сәнгать чаралары, яңа стиль-алымнар эзлиләр. Димәк, образ тудыру алымнары, сурәтләү чаралары үзгәрү белән бергә, әдәбият тә үзгәрә, үсеш кичерә дигән сүз.

Ф. Миңнуллин фикеренчә, 1950 еллар әдәбиятыннан аермалы буларак, 1960 еллардан соңгы әдәбиятка тыгыз һәм кыска язу тенденциясе хас. Бу тенденция аерым язучылар иҗатын тикшергәндә ныграк күзгә ташлана. Мәсәлән, прозада үз мәктәбен булдырган Әмирхан Еники, әдәбиятның үзәктәге, иң мөһим мәсьәләләрен вакытында күреп алып, шуларны публицистик пафос белән сурәтләп баручы Гариф Ахунов, укучыларны һәрвакыт гамь белән, уйланыпборчылып яшәргә өндәүче Аяз Гыйләҗев, өзлексез яңа формалар эзләүче, прозаның кырыс реализмын поэзиянең шартлы алымнары белән үреп баручы Әхсән Баянов, әсәрләрендә кырыслыкны юмор белән, лиризмны сатира белән чиратлаштыручы, кызыклы ситуацияләр һәм эпизодлар остазы Мөхәммәт Мәһдиев һ.б. иҗаты әлеге үзенчәлеккә матур мисал булып тора.

Ф. Миңнуллин прозаның үсешен тоткарлаучы сәбәпләрнең берсе итеп буыннар алышынуын күрсәтә. Көчле һәм талантлы өлкән буынга алмашка килгән яшь буынны ул элгәреләр күләгәсендә үсте дип саный. Өлкән буын әдипләрнең көчле булуы, җитди мәсьәләләрне вакытында күреп алып язуы аңлашыла да, алар революцияне күргән, колхозлар төзүдә катнашкан, илне фашизм афәтеннән саклап калган, кыскасы, зур тарихи вакыйгаларны кичереп, шунда кайнап үскән кешеләр. Яңа буынның йомшара төшүе, бер темадан икенче темага талпыныш-күчешләре, эзләнүләре дә аңлашыла кебек – аларга инде ревалюция ясау кирәкми, кискен үзгәрешләр тынган, шуңа һәрберсе әкрен-әкрен үз юлларын эзли. Һәм таба да. Шуңа да Ф. Миңнуллин аерым замандашларының «проза бу елларда үсми» дигән фикерләре белән килешеп бетми. Тәнкыйтьче бик дөрес тоемлап, моңа дәлилләр китереп, үз карашын белгертә: «Реаль хәлләргә күз салсак, бүгенге прозабыз турындагы байтак фикерләрнең берьяклырак булуын күрербез. Проза үсми, прозаиклар эзләнми, дип зарлануларны алыйк. Бу – уйлап җиткермичә әйтелгән фикер. Бәлки, без көткәнчә үсмидер, без теләгәнчә эзләнмиләрдер?.. Әмма әдәбият эзләнми яши алмый. Юкса, ул шунда ук заман барышыннан артта калачак. Шуны аңлап, язучылар өзлексез төстә чорга ярашлы сәнгать чаралары, чорга ярашлы әдәби стиль эзлиләр. Әнә шулай, акрынлап, әмма туктаусыз төстә язучыларның тормыш материалына булган мөнәсәбәте, образ тудыру алымнары, сурәтләү чаралары үзгәрә –

әдәбият үзгәрә» [Миңнуллин, 1989, б. 8].

Ә инде иҗат итү өчен яңа темалар табылып кына тора. Бу, беренче чиратта, җитештерү (эшче) темасы. Ләкин бу тема буенча иҗат иткән байтак язучыларны тәнкыйтьче актуаль тема артыннан куудa гаепли, аларда җан җылысы азрак булуын ассызыклый. Мәсәлән, Барлас Камаловның «Урманнар киңәя» повесте геройларының КамАЗ белән бәйләнеше аларның, эштән бушагач, ял вакытларында яңа шәһәр, андагы үзгәрешләр белән танышудан, сокланып йөрүдән әллә ни ерак китми.

Бу чор прозасының актуальлеге шунда, әдәбияттагы сыйфат яңарышы буларак, аларга гади кеше темасы, кешенең эчке дөньясын сурәтләү, ягъни психологик анализ көчәя. Ул нәкъ менә яңа буын язучыларының әдәби-эстетик карашлары формалашкан чорга туры килүе белән аңлатыла. Шуңа күрә, алар язган роман-повестьларда тормышчан һәм ышандырырлык гадәти геройлар, бер уку белән истә кала торган тормыш күренешләре күп. Әмма, тәнкыйтьче фикеренчә: «Алгы планга «шәхси як» чыкты, иҗтимагый як икенче планда калды.Урта буын дип йөртелгән прозаикларның әдәби-эстетик карашы шул чорда формалашты, дөресрәге, шул чорда калыплашты. Шуңа күрә булса кирәк, алар язган роман-повестьларда тормышчан һәм ышандырырлык гадәти геройлар, бер уку белән истә кала торган тормыш күренешләре күп. Әмма олы характерлар, эпик киңлек һәм масштаблылык җитеп бетми» [Миңнуллин, 1989, б. 13].

Жанр өстенлекләренә килгәндә, бу елларда хикәя һәм роман жанрлары пассивлаша, ә менә повесть иң актуаль һәм демократик җанр санала: «Хикәя һәм роман жанрлары пассивлаша төшкәнгә күрә, повесть алар тартырга тиешле йөкнең бер өлешен үз җилкәсенә алырга мәҗбүр булды. Нәтиҗәдә, хикәягә тартым яки романга тартым әсәрләр күбәйде. Повестьның тематик колачы нык киңәйде, ә архитектоник төзелеше шактый таркауланды. Болар һәммәсе повесть жанрындагы чуарлыкны тагын да көчәйтә төште» [Миңнуллин, 1984, б. 17], – дип ассызыклый тәнкыйтьче.

Әйе, Ф. Миңнуллин белән килешми мөмкин түгел, чөнки повесть жанрын өлкән буын да, иҗатка яңа килүче яшьләр дә үз итә. Алар арасында М. Галиев, К. Каримов, Ф. Бәйрәмова кебек прозаиклар, Г. Рәхим кебек шагыйрьләр, Т. Миңнуллин кебек драматурглар бар. Повесть жанры сан ягыннан күбәя, сыйфаты яхшыра, сюжеты һәм композиция төзелеше төрләнә. Тематикага килгәндә, документаль материалларга нигезләнеп, автобиографик характерда язылган яки истәлеккә тартым повестьлар барлыкка килә (Р. Вәлиевнең «Эт кояшы», Г. Рәхимнең «Көннәр язга авышкач» һ.б.). Бу повестьларның нигезенә тормышчын материаллар, җитди характерлар салына һәм төп геройны бөтен барлыгында ачу принцибы куела. Кагыйдә буларак, мондый повестьларның үзәгендә яшь кеше

образы. Төп игътибар аның кырыс чынбарлык белән очрашуын, тормышта үз юлын эзләвен сурәтләүгә юнәлә.

Әдәбиятның мәңгелек темасы булган мәхәббәт шулай ук актуаль кала бирә. Ф. Миңнуллин әйткәнчә, әлеге мәңгелек мәсьәләне үзәккә алган повестьларның ниндие генә юк: «Ирхатын һәм сөяркәләр мәхәббәтенә багышланганнары, беренче мәхәббәт, соңгы мәхәббәт, көзге мәхәббәт турындагылары. Инде зур, олы мәхәббәт, кешене кеше, аны гражданин итә торган мәхәббәт турындагы, бу хисне туган илгә, туган җиргә мәхәббәт дәрәҗәсенә күтәргән, алай гына да түгел, безнең прозада мәхәббәт һәм нәфрәт темасын яңа биеклеккә күтәргән повестьларны санарга кушсалар, күбебез, беренче чиратта, Миргазиян Юнысның «Биектә калу», Аяз Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар», Әхсән Баяновның «Тау ягы повесте» әсәрләрен телгә алыр идек» [Миңнуллин, 1989, б. 19]. Тәнкыйтьче фикеренчә, повестьларның барысы да әлеге әсәрләр дәрәҗәсендә булса, прозаның хәле күпкә яхшырак булыр иде. Әмма чынлыкта күпчелек әсәрләр гаилә мөнәсәбәтләренә багышланган булу сәбәпле, аларда охшаш ситуацияләр, калыплашкан алымнар күп очрый.

Тәнкыйтьче аерып чыгарган тагын бер үзенчәлек буларак шуны әйтергә кирәк – прозада сатирик башлангыч көчәя [Миңнуллин, 1989, б. 24]. Бу күренеш әхлак мәсьәләләрен кискен итеп куюдан килә. Мондый әсәрләрнең үзәгенә куелган герой тормыштагы җитди каршылыкларга, һәртөр гаделсезлекләргә каршы күтәрелә, шуның белән укучыны да битарафлыктан чыгара, бүгенгебез һәм киләчәк турында уйланырга этәрә. Ә. Баяновның «Аязучан болытлы һава», Т. Миңнуллинның «Хөсәен Вәгыйзович» повестьлары – нәкъ шундыйлардан.

Гомумән, Ф. Миңнуллин 1960–1980 еллар прозасына, минемчә, шактый тулы һәм объектив бәя бирә. Ул прозаның реаль хәлен һәрьяклап анализлаганнан соң гына үзенең төпле һәм уйландыра торган фикерләрен җиткерә. Аның әлеге сыйфатын билгеләп, үзе дә танылган тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Т. Галиуллин болай дип яза: «Ф. Миңнуллин мирасының иң зур өлеше прозага, аның шанлы тарихына һәм хәзерге торышына багышланган. Тәнкыйтьче бер мәкаләсендә дә тоташ мактау, мәдхия яудыру юлына басмый, уңышлы якларны күрү белән беррәттән, җитешсез, килешеп бетмәгән якларга игътибар иткәндә, автор киләчәктә тагын да камилрәк әсәрләр тудыра алсын дигән ният белән яза» [Галиуллин, б. 14].

Тәнкыйтьче үзенең замандашларының, проза төренең үсү-үзгәреше турындагы я мактап кына, я тәнкыйтьләп кенә, гадәттә уйлап җиткермичә әйтелгән берьяклы фикерләрен кире кага. Аларга каршы итеп, әдәби хәрәкәтнең күпкә катлаулы процесс булуын, ә уйланылганча гына, күз алдына китергәнчә генә бармавын ассызыклый. Чыннан да, әдәбиятта аерым жанрлар

даими һәм өзлексез үсә алмый, киресенчә, вакытлар үтү белән кайбер җанрлар, агымнар нәкъ менә үз вакытына, мохиттәге күренешләргә бәйле рәвештә үзгәреп тора. «Соңгы вакытта без әдәби тәнкыйтьнең шул бер генә төренә йөз тота – күзәтү жанрын гына үстерә башладык. Бүгенге прозабыздагы яңалыкларны тирәнтен тикшергән, прозаның үсеш тенденцияләрен гомумиләштергән җитди хезмәтләр язылмый, аерым язучыларның иҗат үзенчәлеге ныклап өйрәнелми. Шул эшләр тиешле дәрәҗәдә эшләнсә, ихтимал, прозабызның хәлен бәяләгәндә бер чиктән икенче чиккә ташланланулар да, урынсыз зарланулар да кими төшәр иде» [Миңнуллин, 1984, б. 4].

Шулай итеп, Ф. Миңнуллин 1960–1980 еллар татар прозасы торышына бәя биреп, бу төрдә иҗат итүче төп көчләрне барлый, әйдәп баручы тенденцияләрне ачыклый, сәнгати эзләнүләргә бәйле үзенчәлекләрне аерып чыгара. Киң планда караганда, үз чоры прозасында куанып сөйләрлек уңышлар, шул ук вакытта, уйланырга мәҗбүр иткән фикерләр, чишелергә тиешле проблемалар булуын әйтеп, аның алдагы елларда үсү-үзгәрү мөмкинлекләрен дә билгеләп үтә.

### Әдәбият

*Галиуллин Т.Н.* Онытмадык сине Фәрваз дус! // Мәдәни җомга. 2009. 7 авг. № 31. Б. 14–15.

*Әдипләребез*: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.

*Миннуллин Ф.М.* Реаль хәлләргә күз салыйк // Затлылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 8–24.

*Миннуллин Ф.М.* Прозаның гражданлык йөзе: бүгенге прозада повесть жанры. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 4–17.

*Харрасова Р.Ф.* Фәрваз Миңнуллин тәнкыйтьче // Фәрваз Миңнуллин. Казан: Школа, 2010. Б. 6–7.

***Рафикова Эльвира Дамир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 821.512.145

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# САДРИ МАКСУДИНЫҢ ӘДӘБИ ТӘҖРИБӘСЕ – «МӘГЫЙШӘТ» РОМАНЫ

В статье анализируется первый литературный опыт выдающегося ученого и политического деятеля Садри Максуди (1878–1957) – роман «Магишат» («Жизнь»), который посвящен семейному укладу и повседневному быту татар конца XIX века. В произведении, написанном в духе просветительского дидактизма, поднимаются вопросы многоженства, женского образования, противостояния отцов и детей, старого и нового.

**Ключевые слова**: Садри Максуди, роман, татарский быт, дидактизм, просветительство.

Күренекле галим, хокук белгече, сәясәтче Садри Максуди (Садретдин Низаметдин улы Максудов) (1878–1957) яшьлек дусты Гаяз Исхакый белән бер үк вакытта үзен әдәбият аланында да сынап караган. 1900 елда Казанда борадәран Кәримевләр типографиясендә басылып чыккан «Мәгыйшәт» романы – шул әдәби тәҗрибә җимеше. Кызы Адилә ханым Айда язганча, Садретдин әфәнденең әдәбият белән якыннан кызыксынуы Казандагы Татар укытучылар мәктәбендә Гаяз Исхакый белән бергә укыган чорга туры килә, һәм романнар укырга яраткан яшь егет үзе дә матур гына бер әсәр иҗат итә. 1914 елда әсәрнең икенче басмасы Оренбургта «Вакыт» газетасы матбагасында чыга. Саллы тираж белән ике тапкыр басыла, әмма татар әдәбияты тарихын өйрәнүчеләр бу әсәргә әлегә кадәр җитди игътибар бирмәделәр, шунлыктан роман киң катлам укучыларга бөтенләй диярлек билгеле түгел. Садри Максудиның вафатына 50 ел тулу уңае белән, Айшән Услу Байрамлы ханым әсәрнең 1914 елгы басмасын төрек телендә анализлап язып чыкса да [Bayramlı], «Мәгыйшәт» тексты, ни татарча, ни төрекчә әйләнешкә кермичә, укучыларга тәкъдим ителмичә калды. XX йөзгә кадәрге татар әдәбияты зур күләмле әсәрләргә әллә ни бай түгел, шуңа күрә булганын барларга һәм кыйммәтен белергә кирәк дигән фикердән чыгып, авторының юбилей елы булуын да истә тотып, «Мәгыйшәт» романына махсус мөрәҗәгать иттек һәм матбугатта нәшер итү максатында текстын «Безнең мирас» журналына әзерләп бирдек, якын көннәрдә әсәр белән танышу мөмкинлеге туар дип өметләнәбез.

«Тормыш, көн итү, яшәү, тереклек, көндәлек хәят» мәгънәләрен белдерүче гарәпчәдән кергән «мәгыйшәт» сүзе XIX гасыр азагы – XX гасыр башы татар сөйләмендә киң таралган булып, гаилә тормышы, өй эчендәге хәят белән бәйле кулланылган. Мисал өчен, бер үк тамырдан булган «мөгашәрат» сүзен кулланып,

Галимәтелбәнат Биктимириянең 1897 елда «Мөгашәрат әдәбе» исемле рисалә язуы билгеле. Ул анда хатын-кызларга, кияүгә баргач, ни рәвешле ире, кайнанасы, кайнатасы һ.б. туганнары белән яхшы мөнәсәбәт корырга, гаилә тормышында уңышка, сәгадәткә ирешергә кирәклеген бәйнә-бәйнә аңлата. «*Ир белән хатын арасында булган тереклектә мәслихәт улмас исә, һәр икесе өчен олуг хәсрәт вә зур мәшәкать улыр. Мәгыйшәтнең ләззәте бетәр, рәхәте китәр, тәдбирләр бозылыр – җөмлә өй җәмәгате арасында дошманлык заһир улыр, балалар тынычсызланырлар. Моннан исә күп хәерсез эшләр мәйдан алыр*» [Мөгашәрат әдәбе, б. 3; Татар әдәбияты тарихы. II т., б. 409], кебек нәсыйхәтләр бирә. Нигездә, Садри Максудиның әсәре дә шул ук юнәлештә язылган: автор, гаилә мөнәсәбәтләренә багышланган уйдырма сюжетны кызыклы гына итеп оештырып, үз үгет-нәсыйхәт фикерләрен укучыга җиткерүне максат итә. Сюжетның гадилеге, конфликтның тиз һәм уңай чишелүе, күзгә ташланып торган дидактизм Садри Максудины бу әсәре белән, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакыйлардан да бигрәк, Закир Һади, Муса Акъегетзадә, Фатих Кәримиләр когортасына кертә һәм романны XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбиятының классик бер үрнәге буларак бәяләргә мөмкинлек бирә. Хикәяләүченең вакыйгалар дилбегәсен даими үз кулыннан ычкындырмыйча сөйләү рәвеше, укучыларга эндәшеп, аларга риторик сораулар бирүе дә әсәрнең мәгърифәтчелек рухында язылуын исбатлый.

Автор әсәрнең жанрын «милли роман» дип күрсәтсә дә, күләме, сюжет-композиция катлаулылыгы, геройларның саны буенча ул «озын хикәя» яки повесть жанрыннан артык түгел. Язучы вакыйгалар төенләнешен кайбер деталь һәм моментлар ярдәмендә катлауландырырга тырыша, ләкин моңа әле осталыгы һәм тәҗрибәсе җитеп бетмәгәне күренә. «Милли роман» билгеләмәсендә Садри Максуди аеруча «милли» сүзенә басым ясый, 1914 елгы басмасына язган «Кереш сүз»ендә ул Казан татар теленең әдәби тел булып яшәргә тулы хокуклы булуын, милләт тәрәккыяте өчен әдәби телның мөһим бер шарт булуын әйтә һәм әсәрен бу өлкәдә үзеннән бер өлеш кертү максатында язуын белдерә [Bayramlı..., s. 105].

Әсәрнең үзәгендә К. шәһәренең зур байларыннан Халид абзый образы тора һәм вакыйгалар аның тормыш-мәгыйшәте тирәсендә оеша. Тире сәүдәсе белән байлык туплаган, халык арасында үзенә күрә абруе булган Халид агайны автор ягымлы гына бер юмор белән тәкъдим итә: «*Халид агай яхшы күңелле булганга, кеше өчен кайгыручан, халык файдасын төшенүчән иде: сүзе үткән кешеләргә һәрвакыт вәгазь-нәсыйхәттә иде, Халид агайның вәгазе, димләгән нәрсәсе – искелек иде*» [Максуди, б. 2]. Искелек тарафдары, үткән-беткәннәргә гашыйк Халид агай мәдрәсә шәкертләренә химаялек итә: «*үз мәхәлләсендәге мәдрәсәнең фәхри мөдире (попечителе)*

*булып, утын, керосин ... һәрбере аның акчасы илә үтәлә иде. Мәдрәсәгә бондан башка рамазанда зәкят керту, ашларга чакыру кеби күп яхшылык кыйла иде; шуңа күрә шәкердләр Халид агайны яраталар иде. Яту-тору, ашау-эчү кебек эшләрдә Халид агай теләгәнчә булырга, аңа каршы килмәскә тырышалар иде*» [Максуди, б. 3]. Ләкин уку-язуы чамалы гына булган байның мәдрәсәдәге уку-укыту процессына катышырга үзен тулы хокуклы санавы, кирәкмәс фикер-таләпләре белән шәкерт-хәлфәләрне даими борчуы эч пошыргыч күренеш итеп сурәтләнә.

Тормышы бар яктан җитеш Халид агайның, үз фикеренчә, бу дөньяда бер генә кимчелеге калган: ул, мал-дәүләте әллә кайчан икенче хатын алу мөмкинлеге биргән килеш, һаман бер хатын белән генә гомер итеп ята! Авыз тутырып рәхмәтләрен әйтмәсә дә, Халид агай үз эшләренең зураюында, мал-мөлкәтенең артуында атасына бердәнбер кыз, бай мираска хуҗа булып калган хатыны Хәлимә абыстайның мөһим өлеше барлыгын исендә тота һәм, *«бәхете ачылуына сәбәп булган җәмәгате Хәлимәгә ригая хакына»,* аңа көндәш итеп яшь хатын алырга озак вакытлар кыймый йөри. Тик байлыгы арткан саен, 60 яшьләренә килгән агайның хатыныннан оялу хисе кими бара. Автор героеның күңелендәге шөбһә һәм әхлакый каршылыкларны оста гына тасвирлый: *Халид агай эчендән: «Аллага шөкер, байлыгым йитәрлек булды, инде байлыкның рәхәтен күрергә дә кирәк, дөрест, Хәлимә өстендән өйләнү бик килешеп тә йитми, ни эшләмәк кирәк, Хәлиманең картаюы хак бит, юкса, мәхәббәтем юктан түгел, Ходай беләдер, Хәлиманең миңа булган файдаларын онытасым юк. Ходай бу кадәр байлык биргәч, рәхәтен дә күреп калырга кирәк. Гомерне бер хатын белән генә үткәрү минем кебек бай кешегә, үзе дә килешеп җитми инде, Хәлимәне ригая кыйлам дип, әле дә бик күп чыдадым: иншаллаһ, мин бу эш өчен гөнаһлы булмасам кирәк», дип уйлый иде* [Максуди, б. 9].

Ул заманның байлары арасында яшь хатын алу киң таралган күренеш булып, үзенә күрә бер атрибут, байлык, муллык билгесе итеп саналган: татар баеса – нишләсен, ди, икенчегә (хәтта өченчегә) яшь хатын алган әлбәттә.

Ниһаять, хыялын тормышка ашырырга кискен карар биргәч, буйга җиткән балаларының һәм Хәлимә абыстайның каршы булуына да карап тормыйча, Халид агай, мәхәллә хәзрәтенә барып, өйләнергә аның фатихасын ала һәм тиз арада ул тәкъдим иткән кызга – тирече Хөсәен байның кызы Рәбигага яучы да җибәрә. Вакыйгалар Рәбига һәм аның гаиләсе тирәсенә күчкәч, автор олы яшьтәге Халид абзыйның үзләренең сылу һәм акыллы кызларын алырга теләк белдерүенә карата Хөсәен агай белән Латифә абыстайның мөнәсәбәтен тасвирлый. Ана кеше буларак, Латифә абыстай һич кенә дә яшь, тыйнак кызының карт иргә барып, көндәш янында яшәвен теләмәсә дә, Хөсәеннең үз мәнфәгате бар:

Халид абзый белән туганлашу аның байлыгын арттырачак, халык арасында абруен күтәрәчәк. Киңәшергә килгән хәзрәт тә, бу никахны җөпләп, аның нәфесен котыртып тора, шуңа күрә икенче тапкыр килгән яучы уңай җавап алып китә. Татар әдәбиятында шактый киң таралган бу тигезсез никах темасын ачканда, Садри Максуди бөтенләй үк тапталган юлдан китмичә, вакыйгаларны бераз көтелмәгәнрәк, гадәти булмаган юнәлештә дәвам иттерә: Халид агайга өйләнергә киңәш ителгән кыз, баксаң, үз улы Фатихның яраткан һәм өйләнергә уйлап йөргән кызы Рәбига булып чыга. Акыллы, итагатьле, тәрбияле кыз һәм егет күптән бер-берсен тапкан һәм вәгъдәләшкән икән, ләкин моннан һич тә хәбәре булмаган Халид һәм Хөсәен агайлар, никах-туй эшләре белән мавыгып, Рәбиганың елавына да, Фатихның атасына каршы чыгуына да карамастан, тиз генә уйлаган эшне хәл итеп кую ягында. Бары тик Фатихның шәригать кануннарын яхшы белүе һәм никах укырга чакырылган хәзрәтнең гөнаһтан куркуы аркасында гына Рәбига сөйгәненең атасына яр булмыйча кала. Кеше сүзеннән курыккан хәзрәт, Халид белән Хөсәен агайлар, эшне тиз генә йомып, бер-берләрен яраткан Фатих белән Рәбиганы кавыштырып куярга мәҗбүр булалар. Әгәр әсәр шушы ноктада тәмамланган булса, дөреслек өскә чыкты, яшьләр теләкләренә ирешә дип, бәхетле финалга куанып, укучы китапны ябып куяр иде. Ләкин Садри Максуди тигезсез никахларны тәнкыйть итү белән генә чикләнми, төп максаты – укучысын мәгыйшәткә өйрәтү эшеннән читенми. Шуңа күрә Фатихның туеннан соңгы хәлләр әсәрдә аерым бер интрига тәшкил итеп, зәвык белән тәфсилләп аңлатыла: уңышсыз адымыннан соң Халид агайның гаилә әһелләренә, аеруча кулыннан яшь кәләшен тартып алган улына карата мөнәсәбәте игътибар үзәгенә куела. «*Халид агай, яшь хатын ала башлаганчы, ачучан, борчулы кеше түгел иде. Әмма шул өйләнә башлаганнан соң холкы бөтенләй бозылды, бар эше ачуланып, сукранып йөрү була башлады. Хезмәтчеләрне һич гаепсез ачулану, йорт җәмәгатьләрен һич сәбәпсез орышу-тиргәү гадәте булып китте. Йорты эчендә бигрәк тә ачуланганы Фатих иде. Ул бичараны шул кадәр тыгыз тота башлады ки, хәтта газета карарга да рөхсәт бетте, китап укыганны күрсә, буран чыгара иде*» [Максуди, б. 61]. Ниһаять, почтальонның өйгә килеп, рәсемле русча газета калдырып китүе, алдынгы фикерле Фатихның, «Тәрҗеман» газетасы белән берлектә, госманлы һәм рус матбугатын да алдыртуын белү, аннан ничек үч алырга белми йөргән Халид агайга уңайлы бер сәбәп була: ата улын өйдән куып чыгара. Шулай итеп, ата-угыл арасындагы шәхси каршылык иҗтимагый төс – искелек белән яңалык бәрелеше рәвешен ала. Акчасыз, йортсыз калган улының үзенә ялынып килүен көтеп утырган Халид агай бу бәрелештә җиңелә: «*егетлек патшасы, яшьлек урнәге*» Фатих юкка чыкмый, ә менә аның үзенең

сәүдә эшләренә зыян килә, хатыны белән кызы Һәдия аны ташлап китә, сәламәтлеге бозыла. Ялгыз калган үзсүзле һәм горур Халидкә «*Рәхәт, тыныч мәгыйшәт – парлы яшәүдә*» фикерен хәтта өендәге пар *«Мысыр күгәрченнәре»* дә сөйли кебек тоела. Халид агай, үлеме якынлашканын аңлагач, эшләгән ямьсезлекләре өчен үкенә, авыру этисе яныннан аерылмаган, аңа ачу сакламаган, миһербанлы улыннан һәм тугрылыклы хәләл җефетеннән гафу үтенә. Аның вафатыннан соң, Фатих төп йортка кайта һәм Рәбига белән бик матур гаилә корып яши башлый. Хатынының абыстайдан алган белемен җитәрлек дип санамаган Фатих, аның гыйлемнәрен арттыру, дөньяга карашын киңәйтү, ислам динен үзләштерү юлында иренмичә тырыша һәм, нәтиҗәдә, Рәбига «*бик тәрбияле, бөтенләй галимә бер ханым*» булып китә, «*китаплар, газеталар укуны бик яраткан кеби, үзенә тиешле булган хезмәтләрне дә бик әда итеп, кайнанасына, иренә, бөтен өй җәмәгатенә яраклы, аларның рәхәтенә тырышкан тәрбияле бер йорт анасы*» [Максуди, б. 76] булып җитешә. Туачак буынның «*бик тәрбия илә, ислам рухы илә үсеп, галим, диндар, һамиятле, милли бер кеше булып, милләткә, дингә теле, фигыле вә малы илә файда итәрлек бер адәм*» [Максуди, б. 77] булып җитешүе өчен төп алшартларның берсе – ана кешенең гыйлемле һәм тәрбияле булу зарурлыгын ассызыклаган язучы Фатих белән Рәбиганың яңа туган уллары Рәшидне шундый бәхетле балалардан берсе итеп күрсәтә.

Гомумән, әсәрдә хатын-кыз мәсьәләсе иң әһәмиятле темаларның берсе буларак күтәрелә һәм булачак хокукчы Садри Максуди аның шәргый өлкәдәге нюансларына аеруча игътибар бирә, укучының ялгыш аңлавы мөмкин булган бер генә нечкәлекне дә күздән ычкындырмаска тырыша: әйтик, Рәбига белән Фатихның өйләнешкәнгә кадәрге очрашулары һәм хат алышулары шәригать кануннары һәм ислам әхлагыннан читкә чыкмавы, бер-берсенә вәгъдә бирешкәндә яннарында шаһитләрнең булуы әйтелә, шулай итеп Халид агайның Рәбигага – үз углының «гакыйдәле хәләленә» өйләнергә дини яктан хокукы булмавы дәлилләнә. Әсәрдәге бу эпизод Закир Һадиның «Бәхетле кыз» (1903) хикәясендәге конфликтның чишелешен хәтерләтә: сөйгән кызы Гайшә белән карт мулланың никахына бик аз вакыт кала, укымышлы егет Габбас Сәлим мулланың сөт кызы булган Гайшәгә өйләнергә хокукы булмавын исбатлап өлгерә һәм кызны бәхетсезлектән коткарып кала. Шулай ук Гайшәнең әнкәсе, караңгы фикерле Ибәт абзыйның хатыны – уңган, күркәм холыклы, ачык йөзле, ягымлы Хәдичә абыстай белән Рәбиганың әнкәсе Латифә абыстай, Фатихның әнисе Хәлимә абыстайлар арасында да уртаклык күренә, гомумән, ике әсәрдә дә, фикри аваздашлык белән беррәттән, хатын-кыз персонажларның төпле фикерле, акыллы итеп, ә өлкән буын ир-атларның исә тискәре итеп сыйфатлануы күзгә ташлана.

Халык арасында киң таралган күренеш яучы арадашлыгы

белән өйләнешү, димләү-димләшү гадәтен кире какмаган Садри Максуди, Фатих мисалында яшь егетнең үзенә кыз сайлауда хокуклы булуын да күрсәтә. Кызны күрми алу гадәте булса да, егетләр күпчелек очракта булачак хатыннарын «күреп», сөйләштереп карап алырга тырышканнар, Фатих та башта ярын үз сыйныфы – бай гаиләләрнең кызлары арасыннан эзли, ләкин аларның холык-фигыле егетнең идеалларына туры килми, шуннан соң түбәнрәк дәрәҗәдәге кешеләрнең кызлары турында мәгълүмат туплый һәм Рәбига исемле кызны бик мактауларын ишетә. Ләкин кеше сүзенә генә карап өйләнә торган егет түгел Фатих: Рәбиганың акылы һәм әдәбе, башкалардан аерылып торган матур сыйфатлары турындагы төпле фикеренә ул, сеңлесе Һәдиянең кызлар мәҗлесе җыйган көнне, өйдә яшеренеп калып, аларны тыңлап торганнан соң килә. Ир-егетләрнең сайлау мөмкинлеге булып та, хатын-кызларның үзләренә яр сайлауда бу хокуктан мәхрүм булуларын, алырга-бирергә мөмкин булган бер әйбер итеп каралуына уфтануын автор Рәбиганың Фатихка язган хаты аша белдерә: «*Сез, муафикъны табып, эстәгәнегезне алуда ихтыярлысыз, әмма үзеңезгә мәгълүм, безнең хатын-кызда теләгәнеңне сайлау, эстәгәнеңә бару ихтыяры юктыр*» [Максуди, б. 41]. Карт кешегә икенче хатын булып китәчәген белгәч тә, Рәбига чарасыз кала, ата-анасы сүзеннән чыга алмый, язмышы белән килешергә әзерләнә, иреге-хөрлеге өчен үзе көрәшә алмаганга, бердәнбер өметен сөйгәне Фатихка баглый.

Яшьләрнең тәгълим-тәрбиясе темасына җитди тукталып, Садри Максуди шәһәр шартларында яшәгән татар кызының белем алу мөмкинлекләрен барлый һәм, кызлар мәктәпләре әлегә ачылмаган чор булганлыктан, асыл чара итеп «сабак өй»ләрендә остазбикәдә укуны күрсәтә. 7 яшендә остазбикәгә йөри башлаган Рәбига 16 яшендә укуын тәмам итә. «*Маһирә остазбикәнең укыта торган нәрсәләре*» арасында «Кисекбаш», «Ярым алма», «Бакырган», «Йосыф», «Мөхәммәдия» һәм башка бик күп китаплар булып, төрки һәм гарәп телләренең грамматикасына да шактый урын бирелә. Рәбиганың остазбикәсе кыз балаларны «*инсафлы эшләр, әдәпле сүзләргә өйрәтү бик тиеш эш икәнен белгәнгә, үзендән укыган кызларның тәрбия белән үсүенә кулындан килгән кадәрле тырыша*» [Максуди, б. 47] торган ханым итеп сурәтләнә. Гомумән, тарихыбызда остазбикә һәм укымышлы абыстайларның хатын-кызларны рухи камиллеккә ирештерүдә, милләт аналары итеп тәрбияләүдәге ролен безнең әле бүгенгә кадәр аңлап-бәяләп бетерә алганыбыз юк.

Рәбиганың укыган сабаклары арасында иң яратканы «Мөхәммәдия» булып, «*аның» Мөхәммәдия»не укыганын ишеткән кеше һәрвакыт икенче тыңлыйсы, икенче тыңласа, өченче ишетәсе килә иде*» [Максуди, б. 48]. Автор Рәбиганың гыйлеме бик яхшы, остазбикәсе бер хаттат (каллиграф) мелланың кызы бул-

ганга, язуы да бик матур булуын белгертә һәм «*кем белер, тагы да яхшы тәгълим күргән булса, бу кадәр кабилияте, бу кадәр гүзәл тавышы, көйгә-шигырьгә һәвәсе, уку-гыйлемгә ихласы илә милләтемезнең беренче әдибә-мөхәррирәсе булган булыр иде*» [Максуди, б. 48], дип тә өсти.

Әсәрнең идеаллаштырылган икенче герое – Фатихның гыйлем-тәрбиясе турында да озын-озак итеп язган автор, аның башка бай малайларыннан аермасын нәкъ менә укуга омтылышында күрә. Үз заманы өчен яхшы белем алган, үзлегеннән укуын дәвам иттергән Фатих әсәрдә хатын-кызны иҗтимагый яктан да югары бәяләүче шәхес буларак тасвирлана, атасыннан аермалы буларак, ул хатын-кызга өй хезмәте яки ир-атның күзен һәм тәнен куандыру өчен кулланыла торган объект итеп кенә карамый, аны яшь буынны тәрбияләүче ана һәм җәмгыять вәкиле итеп күрергә тели, шуңа күрә Рәбиганы үзенә тиң, белемле һәм югары культуралы итеп тәрбияләүгә әһәмият бирә. Бу урында яшь авторга төрек әдәбияты остасы Әхмәд Мидхәт иҗатының йогынтысы сизелә.

«Мәгыйшәт» романының теле турында да берничә сүз әйтергә кирәк: фикернең ачык итеп бирелүе һәм теленең төзеклеге ягыннан яшь автор, шиксез, мактауга лаек. Төркиядә инде профессор Садри Максуди Арсал булып танылгач та, ул үзенең бу беренче әдәби иҗаты үрнәгенә әйләнеп кайта. 1930 елда ул «Төрек теле өчен» [Arsal] исемле фәнни хезмәт нәшер итә һәм төрек телен, госманлыдан калган авыр гыйбарәләрдән һәм гарәп-фарсы алынмаларыннан арындырып, саф төрки телгә якынайту мәсьәләсен күтәрә. Латин хәрефләре белән төрки телләрдән үрнәкләр китергәндә, Казан татар әдәби теленнән мисал итеп, Садри Максуди үзе язган «Мәгыйшәт» әсәренең башлангыч өлешеннән өзек бирә.

**Әдәбият**

*Arsal, Sadri Maksudi.* Türk Dili İçin. Ankara: Türk Dil Kurumu yay, 2015.

*Bayramlı, Ayşen Uslu.*Sadri Maksudi'nin Ölümünün 50. Yılı Anısına: Sadri Maksudi'nin Hayatı Ve Maksudi'nin Az Bilinen «Maişet» Romanı Hakkında// Balıkesir Üniversitesi Sosyal Bilimler Dergisi Cilt 17 Sayı1, Haziran 2007. S. 101–109.

*әл-Максуди, Садретдин бин мелла Низаметдин.* Мәгыйшәт. Милли роман. Казан, Борадәран Кәримевләр матбагасы, 1900 ел.

Мөгашәрат әдәбе. Икенче басма. СПб., 1898.

Татар әдәбияты тарихы. II том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы,*
*М. Горкий исемендәге Дөнья әдәбиятлары институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 93/94

*М.Р. Гайнанова*

# ТЕЛДӘ, ФИКЕРДӘ, ЭШТӘ САДРИ МАКСУДИ

Статья посвящена деятельности известного татарского политика Садри Максуди, которому в 2018 году исполнилось 140 лет со дня рождения. В работе автор раскрывает роль и место Максуди в общественно-политической жизни татарского и турецкого народов в первой половине XX века. Деятельность Садри Максуди в Государственной думе 3 и 4 созывов Российской империи раскрывает его как борца за права всех мусульманских народов, проживающих на территории империи. Турецкий период Максуди характеризуется его значительным вкладом в правовую и историческую науку, активной деятельностью в политической и общественной жизни новообразованной Турецкой республики в период с 1925 по 1957 годы. Активная научная и политическая жизнь С. Максуди в Турции является связующим мостом между Татарстаном и Турцией.

**Ключевые слова:** Садри Максуди, татарское просветительство, Государственная дума Российской империи, татарский язык, Турция, Ататюрк.

Исмәгыйль Гаспралының «Телдә, фикердә, эштә берлек!» дигән мәшһүр шигаре төрки дөньяда еш яңгырый. Садри Максудиның татар һәм төрек милләтенә хезмәт итүе, эшчәнлеге дә безнең милләтләрне берләштерүче дуслык күпере ролен үти.

XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар җәмәгатьчелеге яңа сулыш белән яши башлый. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Баруди, И. Гаспралы, Ф. Кәрими, Й. Акчура, Һ. Максуди, Г. Исхакый, С. Максуди, Ф. Әмирхан һ.б. күпкырлы җәмәгать эшлекләре, белем ияләре, сәясәтчеләр – тарихыбызда якты эз калдырган шәхесләр. Аларның эшчәнлеген җентекле, тулы өйрәнү эше бүген дә дәвам итә. Күренекле дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе Садри Максуди Низаметдин улының (1878–1957) тууына 2018 елда 140 ел булды. Шәхес булып формалашуда, үз урыныңны табуда кеше тормышында зур роль уйнаган, яхшы киңәш бирүче кешеләрнең булуы мөһим. Садри Максудиның шундый укытучылары булып, бертуган абыйсы Әхмәтһади Максуди һәм күренекле кырымтатар даһие Исмәгыйль Гаспралы санала. Икенчесен – «Минем рухи атам – Исмәгыйль Гаспралы» дип әйтүен – кызы Адилә Айда язып калдыра [Айда, 1996, б. 27]. Нәкъ И. Гаспралы киңәше белән ул 1901 елда Истанбулга китә, ә аннан Парижга аталкы Сорбонна университетының Хокук бүлегенә укырга керә. 1902–1906 елларда ул әлеге уку йортында белем ала, шулай ук өстәмә рәвештә тел, тарих курсларына укырга йөри. Бу вакытларда Парижда Йосыф Акчура да белем ала, яшь Садри Максуди аның белән Фатих Кәрими йомышы буенча Й. Акчурага хат тапшырырга барганда таныша. Бу очрашу тарихын Максуди үзенең истәлекләрендә язып

калдыра: «Йосыф Акчура белән беренче очрашуым 1902 елның башында, Парижлагы «Quartier latin» дип йөртелгән җирдә булды. Белем алу өчен Парижга китәр алдыннан Йосыфның, Траблусгарптагы сөргененнән качып, укуын дәвам итү өчен Парижга киткәнен белгән Фатих Кәрими аның белән танышырга киңәш иткән иде. Миңа аның өчен язылган хат та бирде. Парижга килеркилмәс хатны тапшырыр өчен һәм шунда ук танышырга дип Йосыф бәй яшәгән кунакханәгә юл тоттым. Берхолет урамы, 11 йорт – «Hotel du Monte» исемле кечкенә генә бер гостиница иде бу. Мин парижлашып беткән, купшы бер яшь төрек офицеры белән очрашуымны чамалый идем. Ялгышканымны тиз аңладым. Бүлмәгә кергәч тә башына искергән фәс, өстенә уңган яшел бишмәт кигән, кечкенә генә өстәл каршына утырып, китабын күзенә якын тотып укыган утызутыз ике яшендәге бер кеше белән очраштым. Боек кына каршы алган Йосыф бәй, хатны укыгач, җанланып китте, Казандагы дуслары һәм туганнары турында сораштыра башлады. Шулай итеп, беренче очрашуыбыз һәм танышуыбыз берничә сәгатькә сузылды. Моннан соң да бик еш күрешкәли башладык. Йосыф бәй Парижда Сәясәт мәктәбендә (Ecole des Sciences politques), мин исә Хокук факультетында укыдык, ләкин кирәк икән ул, кирәк икән мин, үз дәресләребездән соң, Сорбоннага безне кызыксындыручы дәресләрне тыңларга бара идек» [Maksudi, 1977, s. 346]. Әлеге шәхесләрнең дуслыклары Төркиядә дә дәвам итә, дуслар, берләшеп, яңа җөмһүриятнең киләчәге өчен Ататөреккнең ярдәмчеләре булып эшлиләр.

Парижда укуын 1906 елда тәмамлап, туган якларына кайту белән Садри Максуди сәяси тормышта кайный башлый. 1907–1912 еллар аралыгында ул Россия Дәүләт думасында депутат була. Петербургта Россия империясендә яшәүче барлык мөселман халыкларының хокукларын яклап чыгышлар ясый, казакъ, кыргыз милләтләренең дә мәсьәләләрен кайгырта. Ә аның Думада татар теленең укытылуы турындагы чыгышы безнең көннәрдә дә гаять актуаль: «Һәрвакыт ислам динебезне һәм төрки телебезне өйрәнергә теләячәкбез. Һәм төрки телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз.

Телне сакларга бик күп нәрсәләр ярдәм итә. Иң мөһиме – ул телнең ибтидаи (башлангыч. – *М.Г.*) мәктәпләрдә өйрәнелүедер. Бер милләтнең теле ул милләтнең балалары укый торган иң кечкенә мәктәпләрдә өйрәнелмәсә, ул тел, һич шөбһәсез, акрынлап югаладыр.

Әгәр балалар ибтидаи тәхсил күрә торган җирләрендә милләт телен өйрәнә торган булмасалар, никадәр башка яктан тырышсаң да, милләт бинасы җимерелеп төшәдер. Милләтнең нигезе – телдер.

Шуның өчен укуханәләрдә телебез укылу вә укылмавына бик зур әһәмият бирәм. Мин телебез укылу-укылмавын безнең милләтебезнең исән калу-калмавы мәсьәләсе белән бер дип уйлыйм. Укуханәләрдә телебез укылса, без калырбыз, укылмаса, акрынлап бетүебезне, моннан милли мәктәпләребез дә алып кала алмас» [Максуди, 1910, № 600].

«Куәтебез булмагач, тиз егылу ихтималыбыз юкмы дисәк, моның да җавабы читен түгел: без инде егылган, бары тапталып кына бетмәгән, актык куәтләребезне сарыф итеп тибрәнсәк, торырга яңадан кеше шикелле көрәшә башларга ихтималыбыз бар. Әгәр егылган көенчә тагын бераз ятсак, тапталып изеләчәкбез, бу – көн кебек ачык... Икътисад мәйданында егылган дип нинди кешеләрне вә нинди милләтләрне атарга мөмкин?

– Икътисад мәйданында егылган милләтләр шул милләтләр: кайсылары һәм төрле гамәл-эш мәйданында иң авыр вазифаларны эшләп иң аз файда күрәләр...» [Максуди, 1910, № 526]. Мәкаләдә татар халкының ачы чынбарлыгы күрсәтелә. Идел елгасында бурлак булып татарлар күп эшли, ди Максуди, руслар арасында да бурлаклар бар әлбәттә, дип искәртә, тик гади эшче булуы белән бергә, пароход йөртүчеләре – капитаннары да булуын ассызыклый. Икенче мисал итеп, Казандагы Алафузов фабрикасында чистарак эштә эшләүчеләр арасында, көч азрак сарыф ителә торган эшләрдә һәм хезмәт хакын күбрәк алучылар арасында мөселманнар һичбер кеше юк, дип сыкрана: «Университетта укытучылар руслар, идән себерүче, мичкә ягучылар мөселманнардыр... Нинди генә мисал китерсәк тә, без мөселманнар һәр җирдә иң ямьсез, иң авыр хезмәтләрдә эшләсәк тә, бик аз хак алабыз, бик аз файда күрәбез.Чөнки мөселманнар эшне күп файдалы итә алмыйлар, чөнки бу заманнарда икътисади сугышларда җиңү коралына ия түгел. Җиңү коралы нәрсә ул? Бу икътисад мәйданында җиңү коралы уку, белү, мәгълүмат – болар мөселманнарда юк.

Икътисад җәһәтеннән изелү милләт җәһәтеннән бетә башлауның башыдыр. Башы гына да түгел, уртасыдыр. Шуның өчен, әгәр миллият җәһәтеннән югалып китәсебез килмәсә, икътисад җәһәтеннән көчле булырга тырышыйк. Икътисад җәһәтеннән көчле буласыбыз килсә, заманча көрәшергә өйрәник. Заманча көрәшергә беләсебез килсә, укыйк, мәгълүмат тәхсил итик, укырга тырышыйк. Надан булмыйк, фәкыйрьләнербез. Фәкыйрь булмыйк – бетәрбез. Укыйк, зинһар, милләттәшләр, бетмик!» [Максуди, 1910, № 528]. Садри Максуди үз милләтенең башкалардан икътисади яктан куәтле, мәгариф ягыннан көчле булуын җаны-тәне белән теләгән.

1907 елда Россиянең III Дәүләт думасына Мәгариф министры Петр Михайлович фон Кауфман тарафыннан башлангыч мәктәп турында канун проекты кертелә. Әлеге проектта башлангыч мәктәптә белем алу вакыты дүрт ел, сыйныфта укучылар санының илле кешегә кадәр булу

мөмкинлеге, мәктәптә дини һәм дөньяви белемнәр бирү карала [Электр. ресурс]. Садри Максуди бу проект турында фикерен җиткермичә калмый, милли мәктәпләр ни хәлдә калачак дигән сорауга җавап табарга тырыша: «Безнең мөселманнарда уку-язу өйрәтү бик иске заманнардан бирле гадәт булган һәм дин өйрәнеп, язу өйрәнеп чыга торган җиргә “мәктәп” дип исем биргәннәр. Европаның соңгы илле елда ибтидаи (башлангыч мәктәп) укуның таралуы вә мәҗбүри булуы билгеле. Безнең Русиядә рус халкы арасында ибтидаи уку аз таралган. Шуның өчен Русиядә укый-яза белгән кеше йөзгә утыз гына. Димәк, хөкүмәт вә Думаның комиссиясе Русиядә уку-язуны тарату дигән вакытта рус телендә уку-язуны таратуны күздә тотадыр. Русиядә һәрвакыт хөкүмәт рус теленең асыл вә гомуми булып, һәр табигага белергә лязем булуына тырышачактыр. Моны бик яхшы белеп куярга кирәк. Русия хөкүмәтенең уку мәсьәләсендәге тоткан юл сәясәте шул: хөкүмәт сәясәтенең иң зур максаты уку-язуны русча булуы бер яктан хөкүмәттә руслыкның сәясәте, икенче яктан вак милләтләрдә үз милләтләрен саклау сәясәте. Болар бәрелешкәч, билгеле, боларның берсе дә вөҗүдкә чыга алмыйдыр. Һәрберсенә үзе теләгәннән кимрәк нәтиҗәләргә разый булырга тиеш буладыр» [Максуди, 1910, № 577]. Милли мәктәпләрнең тарихи роле, аларның урыны турында С. Максуди болай дип яза: «Русия мөселманнарның Русия кул астына керүләренә өч-дүрт йөз ел булып килә. Шул гомердән бирле Русия мөселманнары төрле яктан чолганган руслык дулкыннарына карамыйча исән-сау, сәламәт калганнар. Телләре сакланган, гадәтләре онытылмаган бер милләт булып торганнар. Без исә Русиянең нәкъ уртасында, һәр ягыбызда рус булган көенчә, миссионерларның бертуктаусыз тырышуларына карамаенча үзебезнең милләтебезне саклаганбыз. Бу гаҗәп хәл ни аркасында булды? Безнең милләтебезне саклауда шул мөбарәк мәхәллә мәктәпләребезнең булу аркасында мөмкин булган» [Максуди, 1910, № 582]. Әлеге сүзләрне бүгенге көнгә күчерсәк, нәрсә әйтә алабыз? Без шулай ук Россиянең уртасында яшибез, шулай ук башка милләт халыклары белән матур гына аралашып, тыгыз элемтәдә торабыз. Ә милли мәктәпләребез хакында берни әйтә алмыйбыз. Хәтта соңгы бер елда, татар теле белән бәйле бәхәсләр чыккач, күпчелегебез сискәнеп калды. Туган телне укыту-укытмау, ирекле рәвештә укытыргамы, юкмы дигән сорау булырга тиеш түгел. Ана телебез дәресләрендә укучыларның гореф-гадәтләрне, әдәбиятны, тарихны өйрәнеп, милләтне сөюче кешеләр булып тәрбияләнүе бүгенге көндә бик мөһим. Шуңа күрә дә мәктәпләрдә татар теле укытылуның әһәмияте биниһая. Садри Максуди шул ук вакытта рус телен укытуның кирәклеге турында да искәртеп, милли телләрне саклап калуның кыйммәтен ассызыклый.

Мөселман фракциясе депутаты буларак Садри Максуди Төркестан якларына эш сәяхәте

белән йөри, андагы кыргыз, казакъ халыкларының мәнфәгатьләрен Думада кайгырта, җир мәсьәләсе белән бәйле чыгышлары «Йолдыз» газетасы битләрендә басылып чыга [Йолдыз, 1910, № 542, 590].

IV Дәүләт думасына Садри Максуди кандидатурасы үтми. «Йолдыз» газетасы битләрендә: «Садри әфәнде кебек бер кешебезнең рәсми сәясәт эшләреннән читләштерелүе милләт өчен аның хәзердәге хәлендә зур бер хәсрәттер» дип языла [Йолдыз, 1912, № 890].

1918 елдан соң сәясәтченең тормышы үзгәрә, Милли Идарә куып таратыла. Милләт Мәҗлесе әгъзаларының күпчелеге большевиклар тарафын сайлый, бер өлеше (Ә. Максуди, Ф. Кәрими, С. Мәмлиев, Ш. Алкин, Г. Салихҗан, Н. Корбангалиев һ.б.) большевиклар тарафыннан җәбер-золым күрә, атып үтерелә. Чит илгә чыгып китә алганнар – Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Закир Кадыйри, Габдулла Баттал, Зәки Вәлиди һ.б. Садри Максуди өс-башын үзгәртеп, сакал-мыек үстереп, Петербургка килә. Монда аңа дусты Муса Бигиев Финляндиягә чыгарга ярдәм итә. Финляндиядә 9–10 ай яшәгәннән соң, 1919 елның май аенда ул Парижга килә, чөнки монда Париж тынычлык конференциясе (18 гыйнвар 1919 – 21 гыйнвар 1920) уза. Бу конференциядә Гаяз Исхакый һәм Фуад Туктаров та катнашырга тиеш булалар, тик алар виза, юл белән бәйле мәсьәләләр килеп чыкканга, Парижга апрель аенда гына килеп җитәләр. Монда аларны Садри Максуди каршы ала һәм аларга Версаль килешүенә Россия төрек-мөселманнарының хокукларын яклау буенча меморандумы белән мөрәҗәгать итүен аңлата. Әлеге меморандумда Садри Максудиның имзасы гына куелган булырга тиеш, чөнки, алда әйтеп кителгәнчә, Г. Исхакый белән Ф. Туктаров әлеге меморандумга кул куярга соңга калган булалар. Моннан тыш, С. Максуди җитәкчелегендәге һәйәт әгъзалары төрле халыкара җыеннарда катнашып, татар халкының проблемалары белән Европа һәм дөнья җәмәгатьчелеген таныштыралар. Шул исәптән, Милләтләр лигасына да мөрәҗәгать итәләр, 1921 елда Париждагы конференцияләрдә катнашалар. Тик матди һәм мәгънәви яктан ярдәмсез калгач, Милли Мәҗлеснең соңгы органы булган солых һәйәте дә 1922 елда тарала [Исхакый, 1933, № 4].

Садри Максуди 1922–1925 еллар эчендә гаиләсе белән Финляндиядә, Германиядә, Франциядә яши һәм 1925 елда Төркиягә күченә. Әнкарага килеп җитүгә Садри Максуди 5 ноябрьда ачылган Хокук мәктәбендә мөгаллим булып эшкә алына һәм төрки халыкларының хокук тарихы фәнен укыта башлый. Хәзерге көндә әлеге Хокук мәктәбе Әнкара университетының Хокук факультеты дип атала. Бу мәктәптә профессор-мөгаллимнәр арасында, С. Максуди белән бергә, Йосыф Акчура да эшли. Әлеге курсның максаты – төркиләрнең борынгыдан ук дәүләтле, үз хокук системалары булган, икътисади яктан алга киткән халыклар икәнен

күрсәтү. Максуди, кешеләрнең мәдәниятендә мөһим аспект булып инсаниятлек принципларына нигезләнгән хокук системасы тора, ди.

1928 елда Төркиядә латин алфавитына күчү башлана һәм бу эшкә галимнәр һәм Ататөрек ярдәмчеләре ныклап тотыналар. Садри Максуди шул ук елны «Миллият» газетасында «Lisan ıslahı meselesi» («Тел реформасы мәсьәләсе») исемле мәкаләләрен бастыра башлый. Укучыларга телнең никадәр мөһим роль уйнаганын дәлилли, яңа төрек телендә яңа сүзләр уйлап табасы түгел, ә башка төрки телләрнең сүзлек составына нигезләнергә, дини терминологиягә кагылмаска кирәклеген аңлатырга тели. Аның укучыларга җиткерергә теләгән асыл фикере булып, барлык төрки халыклар өчен уртак бер тел булдыру тора. Әлбәттә, аңлашыла ки, Максуди мәшһүр Исмәгыйль Гаспралының идеясен алга сөрә, ул күрсәткән юлдан бара. Яңа алфавит кабул ителә, чит телдән шактый сүзләр алына, тел буенча махсус комиссия төзелә, ләкин С. Максуди бу комиссиядә эшләүдән баш тарта, тел белән бәйле мәсьәләләр буенча эшләмәскә тырыша, чөнки 1937 елда «Денизбанк» атамасы өчен ул кискен тәнкыйтькә дучар була. Ататөрек банкны «Денизбанк» дип атый, С. Максуди бу терминны төрек грамматикасына туры килми, банк чит-ят сүз, шуның өчен «Дениз банкасы» дөресрәк булачак дип, Ататөрекнең сүзенә каршы чыга. Бу сүзләрдән соң Максудига каршы кампания оештырыла, радио аша, газета битләрендә аның үзенә һәм эшчәнлегенә кискен тәнкыйтьләүләр башлана. Г. Баттал-Таймас үзенең китабында, «Денизбанк» тирәсендәге күңелсезлекләр озакка сузылмый, Садриның хаклыгы таныла, бу бәйләнүләр аның дәрәҗәсен төшерә алмый. Ничек кенә булмасын, бу хәлләрне ул авыр кичерә, дип билгели [Баттал-Таймас, 1999, б. 53]. Карьерасы югарыга барганда мондый мәсьәләнең килеп чыгуы, Ататөрекнең фикеренә каршы үз сүзен әйткәне өчен массакүләм чараларының аны «наданлыкта» гаепләве, тискәре сүзләр язуы С. Максудины тетрәндерә. Бу вакыйгалар аңа эшендә, тормышында борчу китерә, кызының хатирәләрендә Ататөрекнең Максудига карата булган кампанияны туктатуын сорап язганы билгеле, шуннан соң гына этисенең тынычлап эшкә тотына алуы теркәлә.

Мөһаҗирлектә дә С. Максуди сәяси тормыштан читтә тора алмый. Ул Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесенә өч тапкыр милләт вәкиле итеп сайлана: 1931–1939 елларда – Җөмһүрият Халык партиясеннән, 1950–1954 елларда – Демократия партиясеннән. С. Максудиның иң соңгы китабы – «Миллият тойгысының социологик әсаслары» (1955) иҗатының йөзек кашы булып санала. Ул анда милләтләр турында, милли хис, милли холык турында, ырк мәсьәләсе хакында уйлануларын яза. Максуди фикеренчә, кеше шовинизмнан ерак, рациональ, аңлы, уяу милли хисләр белән сугарылган булырга тиеш.

Төрки халыкларны берләштерү өлкәсендә зур көч куйган шәхесләр аз түгел, шундыйлардан Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Акъегетзадә, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Акдес Нигъмәт Курат, Әхмәт Тимер һәм башка мәшһүр зыялылар бу исемлекне дәвам итә ала. Әлеге алдынгы карашлы кешеләр арасында Садри Максудиның үз урыны бар. 1918 елга кадәр С. Максуди татар халкының якты киләчәге, Россиядә яшәүче барлык мөселман халыкларының теле, дине, мәдәнияте өчен Дәүләт думасында актив эш алып барган затларның берсе була. 1919–1924 елларда Европада яшәгән чорында ул туган якларына кайту теләге, өмете белән яши. 1925–1957 елларда С. Максуди Төркиядә. Яңа Ватанында да төрки халыкларның хокук тарихын, дөнья тарихында аларның урыны, роле, телләре турында фәнни мәкаләләр, китаплар яза, университетта белем бирә, гомумән, гомерен татар халкы, төрек халкына хезмәт итүгә багышлый.

### Әдәбият

*Айда А.* Садри Максуди Арсал. М., 1996. 357 с.

*Баттал-Таймас Г.* Ике бертуган Максудилар. Казан: Фән, 1999. 144 б.

*Исхакый Г.* Беренче Милләт мәҗлесенең 15 еллыгы // Яңа милли юл. 1933. № 4.

Йолдыз. 1910. № 542, 590.

Йолдыз. 1912. № 890. 7 октябрь.

*Максуди С.* Милли сөхбәтләр // Йолдыз. 1910. № 526. 11 апрель.

*Максуди С.* Милли сөхбәтләр // Йолдыз. 1910. № 528. 15 апрель.

*Максуди С.* Милли мәктәпләр ни хәлдә калачак // Йолдыз. 1910. № 577. 19 август.

*Максуди С.* Сөхбәтләр. Тәгълим гомуми мәсьәләләр // Йолдыз. 1910. № 582. 2 сентябрь.

*Максуди С.* Милли сөхбәтләр // Йолдыз. 1910. № 600. 21 октябрь.

*Maksudi S.* Dostum Yusuf Akçura // Türk Kültürü. 1977. № 174. S. 346–354.

Электрон ресурс http://www.doc20vek.ru/node/1638

***Гайнанова Миләүшә Рамил кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*И.И. Ямалтдинов*

# 1920 ЕЛЛАРДА ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫНДА ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ТИКШЕРЕНҮЛӘР

Статья посвящена раскрытию проблем и направлений исследования татарской фольклористики в 20-е годы XX века.

**Ключевые слова:** татарская фольклористика, народное творчество, фольклор, становление фольклора.

XIX гасыр урталарыннан татар фольклорын җыю һәм өйрәнү эшен татар мәгърифәтчеләре башлап җибәрә, шулай итеп, гасыр ахырына татар фольклористикасы формалаша. XX йөз башында татар халык иҗатын фольклорчылардан Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Г. Рәшиди, әдәбиятчы галимнәрдән Г. Баттал һәм Г. Рәхим, шулай ук шагыйрьләр һәм язучылардан Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан өйрәнәләр. Алар фольклор мәсьәләләре, проблемалары белән шөгыльләнәләр, үзләренең оригиналь фикерләрен әйтәләр, халык иҗаты һәм аның аерым жанрларының үзенчәлекләре турында күзәтүләр ясыйлар, мәкаләләр бастыралар, җыентыклар нәшер итәләр һәм шуның белән милли фольклористиканың үсешенә шактый зур, әһәмиятле өлеш кертәләр [Урманчеев, б. 20; Бакиров, б. 12]. Болар барысы XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар халкының иҗтимагый-сәяси һәм милли-мәдәни тормышының җанлануы фонында була.

Гомумән, XIX–XX йөз башында, бихисап татар фольклоры әсәрләрен җыю һәм бастыру эше белән беррәттән, беренче фәнни хезмәтләр языла.

1920 елларда ТАССР төзелүгә бәйле рәвештә татар фольклорын пропагандалау һәм өйрәнүгә булган кызыксыну күп тапкырга арта. Шушы ук чорда татар фольклоры Казанның югары уку йортларында предмет буларак укытыла башлый, һәм аны фәнни яктан өйрәнү өчен шартлар тудырыла.

Көнчыгыш педагогика институты доценты Г. Рәхим берничә ел татар фольклоры курсын укыта. Үзенең лекцияләрендә борынгы гомумтөрки катламнарга һәм халыкның йола иҗатына басым ясый. Халык әдәбияты иң борынгы төркиләрнең күзаллауларын һәм идеологиясен дәлилләү чыганагы дигән фикерне алга сөрә. Текстның төзелеше һәм язылу стиленнән чыгып, фольклор әсәрләрен «көйле һәм көйсезләргә» бүлә. Мәдрәсә фольклорына аеруча зур игътибар бирә, Казан ханлыгы турындагы легендаларга һәм тарихи бәетләргә аерым туктала [Толымбай, б. 94–95].

1924 елда Г. Рәхим, Г. Газиз белән бергә, «Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер» басма-

сының беренче томыннан ике бүлеген бастыралар. Культура-тарих мәктәбе вәкилләре буларак, авторлар әдәбият тарихын яктыртуга системалы якын киләләр, шулай ук эволюцион һәм культура-тарих методларына таяналар. Аерым алганда, фольклорны әдәбиятның нигезе итеп саныйлар һәм «Борынгы төркиләрнең әдәбиятлары» бүлегендә борынгы авыз иҗаты әсәрләренең үрнәкләрен, шулай ук фольклор һәм язма әдәбият буенча хезмәтләрне өйрәнәләр. «Идел буендагы борынгы тел һәйкәлләре» бүлегендә шул чор фольклоры һәм Идел буена Шәрыкъ халыклары фольклорының үтеп керүе турында сүз бара. Шул ук елда әлеге авторлар тарафыннан «Татар әдәбияты тарихы. I җилд: Борынгы дәвер: 3 нче бүлек: 17, 18 һәм 19 гасырларда иске әдәбият» китабы бастырыла. Анда да фольклорга шактый зур урын бирелә. «Татар әдәбияты тарихы»нда феодализм чорындагы дастаннар, бәетләр, әкиятләр турында фикерләр әйтелә.

1927–1928 елларда «Безнең юл» журналында Ф. Туйкинның «Халык әдәбиятын тикшерү юлында» һәм Г. Толымбайның «Татар фольклоры турында кайбер фикерләр», «Тукай һәм әдәби фольклорыбыз» мәкаләләре басылып чыга. Әле хезмәтләрдә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү өлкәсендәге җитешсезлекләр күрсәтелә, фольклорны «рухи атмосфера» һәм иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнештә комплекслы тикшерү тәкъдим ителә.

1929 елда «Татарстан» журналында Н.И. Воробьевның «1929-нчы елның җәендә Нократ һәм Глазов татарлары янына бару», «Татар җөмһүриятенең Минзәлә кантонындагы халыкны этнографик ягыннан күзәтү» дигән мәкаләләре басылып чыга.

Н. Воробьевның татар этнографиясен өйрәнүгә карата әйтелгән, фольклорны һәм милли мәдәниятны өйрәнүгә комплекслы якын килү мәсьәләсен күтәргән фикерен яклап, Г. Толымбай болай яза: «Казан татарлары культурасын тикшереп караганда, анда борынгы төрки халыкларының, Урта Азия мөселман культурасын, шулай ук фин, рус халыклары йогынтысын күрергә була. Без фольклорны тикшергәндә культураларның бәйләнешен күрәбез. Безгә мифологиядән пәри, дию, шайтаннарны тикшергәндә, Урта Азия аркылы килгән культураны истә тотарга кирәк була, әкиятләрне чагыштырганда рус әкиятләренә бик нык игътибар итәргә туры килә, угыз сөте, багучы кебекләрне тикшергәндә, иске күчмә төрекләргә үк кайтмый хәл юк» [Тулумбайский, б. 58].

1920 еллардагы яңа сәяси шартларда татар фольклорын өйрәнү буенча рус авторларының да тикшеренүләре барлыкка килә, бигрәк тә җырлар буенча. Алар арасында Н.В. Никольскийның «Идел буе халыкларының халык музыкасы тарихы буенча конспект» («Конспект по истории народной музыки у народностей Поволжья», 1920), В. Виноградовның «Татар халык җыры, аны саклау һәм тикшерү турында берничә сүз» («Несколько слов о татарской народной песне, ее

хранении и разработке», 1921), А. Симаковның «Татар республикасында музыкаль гыйлем» («Музыкальное просвещение в Татарской республике», 1921), А. Эйхенвальдның «Халык җыры һәм Казан татарлары музыкасы» («Народная песня и музыка казанских татар», 1923) мәкаләләрен билгеләп үтәргә була.

Р. Лахның төрки-татар, Кавказ, һәм шулай ук угор-фин халыкларының музыкасы һәм музыкаль фольклоры (1920) [Lach, s. 23–50], Т. Ковальскиның төрки халыкларның шигырь төзелешендәге поэтик формалары (1921) [Kovalski, s. 1–184], Н. Фирсовның Казанга нигез салыну турындагы риваятьләр һәм легендалар (1926) [Фирсов], Н.К. Дмитриев белән О. Чацкаяның татар җырларын җыю, өйрәнү, җырларның көйләре, аларның жанр төрләре һәм шигырь төзелеше [Dmitriev, Chatskaya, p. 301–369] турындагы мәкаләләрен дә билгеләп үтәргә кирәк.

Болардан тыш, Д. Ливитскийның «Татар халык җырлары турында» («О татарских народных песнях», 1928), А. Лининның «Казан-татар поэзиясе: халык поэзиясе формалары турындагы яңа тикшеренүләрдән» («Казанско-татарская поэзия: из новых исследований о формах народной поэзии», 1928), Ф. Маловның «Татар яшьләренең җырлары» да татар халык иҗатын өйрәнеп тикшерүгә багышланган [Миңнуллин, б. 30].

1920 елда Гата Исхакый әдәбият тарихы һәм теориясе буенча «Әдәбият юллары: Рөшди мәктәпләремез өчен дәреслек» китабын бастыра. Аның «Халык әдәбияты» бүлегендә дә татар фольклоры турында кыскача мәгълүмат бирелә.

Фольклорчы Х. Бәдигый 1920 елларның беренче яртысында Казан педагогика техникумында укыта, Академүзәктә эшли, Ленинград Көнчыгышны өйрәнү институтын һәм аспирантурасын тәмамлаганнан соң, 1930 елдан башлап, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасына фәнни хезмәткәр-укытучы буларак билгеләнә, соңрак доцент, аннары профессор вазифаларына ирешә. Аның халык иҗаты өлкәсендәге эшчәнлегенең бер юнәлеше булып татар фольклоры курсын укыту тора. Х. Бәдигый, беренчеләрдән булып, халык иҗаты буенча югары уку йортлары өчен программа төзи [Ярми, б. 63].

Аның фәнни казанышлары, беренчеләрдән булып мәкальләр һәм табышмакларга классификация ясаудан гыйбарәт, ул аларны «Халык әдәбияты. Мәкальләр һәм табышмаклар» (1926) җыентыгында куллана. 1912–1913 елларда дөнья күргән җыентыкларында әлеге жанрларның үрнәкләрен алфавит тәртибендә урнаштырган булса, монда ул аларны тематик төркемнәргә бүлә. Соңрак әлеге принципны Н. Исәнбәт куллана һәм мәкальләр, әйтемнәр, шулай ук табышмаклар буенча үзе төзегән җыентыкларында файдалана.

1920 елларда тел һәм әдәбиятны өйрәнү өлкәсендә генә түгел, татар фольклористикасы тарихында да борылыш була. Татар халык иҗатын фәнни яктан

тикшерү дәүләт оешмаларының (Академүзәк) планына кертелә. Халык иҗатын җыю һәм өйрәнү эше билгеле бер системага салына һәм махсус «Халык әдәбиятын эшкәртү комиссиясе» җаваплылыгына тапшырыла. Монда шуны да әйтергә кирәк, татар фольклоры мәсьәләләре, проблемалары белән дә, нигездә, шулай ук халык иҗаты үрнәкләрен җыю һәм бастыру эшен башкарган галимнәр һәм язучылар шөгыльләнгән.

1926 елда «Безнең юл» журналында Г. Ибраһимовның «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы» дигән җитди мәкаләсе басыла. Әлеге мәкалә шул вакыттагы әдәбият белгечләре өчен кулланма, татар фольклористикасының үзенә күрә бер программасы да була. Анда Г. Ибраһимов халык иҗатының төп әһәмиятен, мәгънәсен күрсәтә [Ибраһимов].

Бу мәкаләсендә автор халык иҗатын шул халыкның тарихы, аның иҗтимагый тормышы һәм социаль-сәяси процесслар белән бәйләп өйрәнү зарурлыгын күтәрә. Шулай ук фольклор әсәрләренең иҗтимагый аңның аерым һәм үзенчәлекле формасы, халык мәдәнияте, сәнгать, әдәбият һәм тел өлкәләренең аерылгысыз, мөһим тармагы булып саналуы ассызыклана. Г. Ибраһимовның мондый карашлары, безнең фикеребезчә, XX гасырның 20 нче елларында татар әдәбият белемендә рус фәне һәм аның мәктәбе тәэсирендә барлыкка килгән **культура-тарих мәктәбенә** караву белән аңлатыла [Галиева, б. 63]. Ул җитәкләгән Академүзәк вәкилләре, шулай ук әлеге фәнни оешма белән хезмәттәшлек иткән әдәбиятчылар һәм фольклорчылар (Г. Рәхим, Г. Газиз, Г. Толымбай, Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Ф. Сәйфи-Казанлы) үзләренең тикшеренүләрендә марксистик идеологиягә туры китереп, культура-тарих мәктәбе принципларына таяналар әлбәттә.

Димәк, шул чордагы татар фольклористикасы билгеле бер дәрәҗәдә культура-тарих мәктәбе йогынтысында булган, дип әйтергә мөмкин. Чөнки Академүзәк үз тирәсенә, культура-тарих мәктәбе тарафдарларын һәм фәндә, әдәбият һәм фольклорны өйрәнүдә, җәмгыятьнең рухи тормышында культура-тарих үзенчәлекләренең үсешен исәпкә алган, язма әдәбиятта да һәм халык иҗатында да милли үзенчәлекләрне һәм алар арасындагы аерманы ачыклау принципларына актив таянган әйдәп баручы галимнәрне берләштергән. Ләкин фольклористика шома гына, каршылыксыз һәм көрәшсез генә үсмәгән. Ул хаталардан да азат булмаган (бигрәк тә идеологик һәм методологик характерындагылардан). Аерым алганда, хөкем сөрүче иделогиянең исбат ителмичә нигез итеп алынган фикереннән чыгып, традицион һәм заман фольклорын сыйнфый көрәш яктылыгында өйрәнергә омтылыш була. Ягъни, сыйнфыйлык принцибын абсолютлаштыру, дини идеология белән сугарылган аерым жанрларны һәм әсәрләрне танымау һ.б. кебек фәндәге зыянлы

тенденцияләргә һәм күренешләргә каршы көрәштә Г. Ибраһимовның алда әйтелгән чыгышы зур роль уйный, һәм татар фольклористикасын яңа дәрәҗәгә күтәрергә ярдәм итә.

Гомумән, 1920 еллар татар фольклористикасы өчен шактый нәтиҗәле чор була. Бу чорда катлаулы теоретик проблемалар күтәрелә һәм алар кыю рәвештә хәл ителә.

## Әдәбият


*Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 12.

*Галиева Э.Р.* Культурно-историческая школа в татарском литературоведении 1920–1930-х годов: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2003. 63 с.

*Ибрагимов Г.* Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы // Безнең юл. 1926. № 5/6.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. Б. 30.

*Толымбай Г.* Татар фольклоры фронтында // Сов. әдәбияты. 1933. № 8/9. Б. 94–95.

*Тулумбайский Г.* Татар фольклоры // Татарстан. 1930. № 6/7. Б. 58.

*Урманчеев Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 20.

*Фирсов Н.* Казань в легендах // Красная Татария. 1926. 21 марта.

*Ярми Х.* Татар фольклористика фәненең күренекле галиме // Совет әдәбияты. 1957. № 12. Б. 63

*Dmitriev N.K. et M-me Chatskaya O.* Chansons populaires Tatares, transcrities et traduites par N.K. Dmitriev, M-me O. Chatskaya // Journal asiaique (Paris). 1926. Avril-Juin. P. 301–369.

*Kovalski Tadeusz.* Le studjow nad formas poezii ludow turkeckich // Prace Komisji Orientalistycznei Polskjei Akademji Umiejetkosci (Krakow). 1921. I. S. 1–184.

*Lach R.* Die Musik der turk-tatarischen, finnischugrischen und Kaukasus-Volker in ihrer entwicklungs – geschichtlichen und psychologischen Bed eutung fur die Entstehung der musikalichen Formen // Mitteilungen der Antropologischen Gesellschagt (Wien). 1920. Bol. 20. S. 23–50.



***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

УДК 398

***Н.Ә. Хөббитдинова,***
***Г.В. Юлдыбаева,***
***Л.Х. Мөхәммәтҗанова,***
***Ә.Г. Салихов***

# МӘДӘНИЯТЛӘР КИСЕШКӘН НОКТА: КУРГАН ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨРКИ ЦИВИЛИЗАЦИЯ

## (фольклор экспедициясе һәм архив материаллары нигезендә)

В статье рассматриваются фольклорные материалы, собранные в разные годы во время экспедиций в Зауралье. Исследуя локальные этнокультурные явления, авторы выявляют единое культурное целое, взятое в общетюркском культурном контексте. Найденные в разные годы во время экспедиций образцы народного творчества – определенная частьи общетюркских фольклорных традиций, отражающая результаты взаимосвязей соседних родственных народов и культур. Словесные памятники, записанные из уст татароязычных и башкироязычных информантов Зауралья – это не только национальный фольклор, они служат ценными источниками для углубленного изучения проблемы истории тюрков в сравнительном аспекте и в контексте Евразийской цивилизации.

**Ключевые слова:** Курганская область, фольклор, экспедиция, татары, башкиры, фонд, архив, материалы, культура.

Курган өлкәсе бик борынгы дәверләрдән үк төрки кабиләләр яшәгән төбәк буларак мәгълүм. Төрки каганлыклар чорыннан алып, бүгенге көнгәчә бу төбәк – элгәрләребезнең чынчынлап тарихи ватаны. Биредә борын-борыннан яшәгән җирле төркиләр, соңгырак чорларда Идел һәм Урал буеннан килеп утырган татарлар һәм башкорт кабиләләре, эреле-ваклы авыллар булып, хәзерге көндә дә исәнимин тереклек итәләр. Халык санын исәпкә алуның 2010 елгы мәгълүматлары буенча, Курган өлкәсендә татарларның саны, руслардан кала, икенче, башкортларныкы исә өченче урынны алып тора. Ике тугандаш халыкның гаять үзенчәлекле катламнарын тәшкил итә торган бу кавем, башкалар белән беррәттән, Курган өлкәсенең социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә үз өлешен кертеп яши.

Электән үк биредә яшәгән татар-башкортларны төрки тамыр, дин берлеге, тел, гореф-гадәтләр якынлыгы берләштергән. Болар гомер-гомергә үзара кыз алып, кыз бирешкәннәр. Курган өлкәсендә яшәүче татарлар йөзендә башкорт чалымнары, телләрендә башкорт теле үзенчәлекләре чагылу һәм, киресенчә, татарлык өстенлек алган башкортлар – бу Урал артында гасырлар буена формалашкан, ике кардәш халыкны этник җәһәттән баета торган табигый күренеш.

Курган өлкәсендә яшәүче төркиләр фольклоры бик бай. Бүгенге көндә регионара һәм мәдәни бәйләнешләр үзара нык керешкән күрше һәм тугандаш ике халыкның – татарлар һәм башкортларның – фольклор мирасын янәшә куеп барлау әлеге халыкларның үзара аңлашу-аралашу чарасы буларак актуаль. Уртак тарихи-мәдәни тамырлар, бердәй менталитет, дөньяга карашларның бертөрлелеге шартларында бер үк регионда көн күрүче ике милләткә хас рухи мираска күзәтү ясауның татар-башкорт фәнни-гамәли һәм мәдәни коммуникацияләр өлкәсендә, шулай ук регионара контактларны ныгыту җәһәтеннән гаять мөһим булуы аңлашыла.

Фольклор традицияләренең бүгенге торышын ачыклауның төп формасы – традицион культураны өйрәнүчеләр тарафыннан теге я бу төбәккә фәнни экспедицияләр уздыру, алып кайтылган материалларны архивларга урнаштыру һәм булганнарын барлау-өйрәнү. Татарстан Фәннәр академиясенең татар телен, аның этник традицияләрен, әдәбиятын, халык авыз иҗатын, кульъязма мирасын, халык музыкасын, эпитафикасын өйрәнә торган фәнни-тикшеренү үзәге саналган Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында бу эш киң колач белән бара. Россиянең татарлар яши торган төрле төбәкләренә элек-электән фольклор экспедицияләре үткәрелгән булса, хәзер төбәктәге халык авыз иҗатын өйрәнү комплекслы экспедицияләр составында башкарыла. Институт экспедицияләр вакытында тупланган материаллардан «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә аерым төбәкләргә багышланган «Милли-мәдәни мирасыбыз» исемле басмалар әзерләп нәшер итә. 2010 елдан алып бүгенге көнгә кадәр әлеге юнәлештә 16 китап дөнья күреп өлгерде инде. Серия теге я бу төбәккә хас булган фольклор әсәрләренең, археография, диалектология материалларының документаль чагылышын тәэмин итә. Түбән Новгород өлкәсе, Марий Эл Республикасының Бәрәңге районы, Удмуртия Республикасы, Омск, Самара, Әстерхан, Оренбург, Томск өлкәләре, Пермь крае, Татарстан Республикасындагы районнарга уздырылган шундый экспедицияләрнең төп нәтиҗәләре буенча чыгарылган китаплар барысы да татар традицион культурасын һәм халыкның мәдәни тормышына тирә-күршеләр йогынтысын тирәнрәк күзалларга ярдәм итә. Ә Курган өлкәсендә яшәүче татарлар һәм күрше халыклар мәдәниятен барлауга багышланган шундый экспедиция Институт тарафыннан 2010 елда үткәрелде (җитәкчесе – Институтның диалектология һәм лексикология бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Дария Рамазанова). Аерым төбәкләргә мөнәсәбәтле һәм гомумән халкыбыз мәдәнияте проблемалары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әнә шулай Евразия цивилизациясе контактларын ачыклау аша карала.

Башкорт галимнәре тарафыннан да төрле төбәкләргә ар-

хеографик, фольклор экспедицияләре даими үткәрелә, экспедиция нәтиҗәләре булып яңа басмалар дөнья күрә, халык иҗатын барлау җәһәтеннән мәдәниятара, регионара бәйләнешләр контекстында фәнни тикшеренүләр алып барыла. Россия Фәннәр академиясенең Уфа федераль тикшеренү үзәге федераль дәүләт бюджет гыйльми учреждениесе Почет билгесе орденлы Тарих, тел һәм әдәбият институты фольклорчылары цифрлы технологияләр ярдәмендә 60–90 нчы елларда тупланган фольклор экспедициясе материалларын аудиодискларга урнаштыруга ирештеләр, бу эш соңгы еллар экспедиция материалларына мөнәсәбәттә дә алып барыла. Мондый эшчәнлекнең нәтиҗәсе мәдәният, уку-укыту, мәгариф һ.б. өлкәләрдә аутентик фольклорга мөрәҗәгать итү мөмкинлеген киңәйтә. Шул исәптән Курган өлкәсенә 1930 еллардан бирле уздырыла килгән фольклор экспедицияләре материаллары да яңа яңгыраш ала.

Курган өлкәсендә тупланган фольклор материаллары мәсьәләсенә якынрак килсәк, узган гасырның җитмешенче елларында Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре бу якларда фольклор экспедициясендә булып, бик күп материал табып алып кайттылар. Төгәлрәк әйтсәк, 1978 елның июлендә Котдус Хөснуллин (җитәкче), Рәшит Ягъфәров, Асия Садыйкова, Кәмәрия Ямалетдиноварлардан торган төркем, 1979 елның июнендә Илбарис Надиров (җитәкче), Ленар Җамалетдинов, Асия Садыйкова, Сәлим Гыйләҗетдинов, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Рәшит Ягъфәровтан торган алты кешелек төркем Урал арты татарлары фольклорын туплау максаты белән бу якларга фольклор экспедициясенә чыккан. Галимнәр татар авылларында йөреп, халык белән әңгәмә корганнар. Шулай ук Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры Фәрит Йосыпов төрле елларда әлеге төбәккә оештырылган фәнни экспедицияләрдә катнаша килә. Биредә шактый берәмлектә халык җырлары, бәетләр, табышмаклар, риваять, мифологик хикәятләр, дастан вариантлары, әкиятләр җыелганлыгы турында мәгълүматлар бар. 2010 елда Курган өлкәсенә татар галимнәре тарафыннан комплекслы экспедиция уздырылды, ягъни эш бу юлы берничә юнәлештә алып барылды, шул исәптән халык авыз иҗаты да исәпкә алынды. Беренчел эшкәртелгән материаллар үзләре бүгенге көндә, башка кульязмалар белән бергә, Казан фәнни үзәкләре архивларында, шул исәптән Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә [Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать нститутының Язма һәм музыкаль мирас үзәге] яхшы хәлдә саклана.

Башкортстан фольклорчыларының Курган өлкәсенә тәүге экспедицияне 1930 елда ук уздырулары мәгълүм. Җыелган

материаллар З. Шәкиров тарафынан Тарих, тел һәм әдәбият институты архивына тапшырылган. 1959 елда исә фольклор экспедициясе өлкәнең Әлмән, Сафакүл районнарына Кирәй Мәргән җитәкчелегендә (экспедиция әгъзалары – С.А. Галин, Н.Д. Шоңкаров) башкарылган. 1970 елда С.А. Галин, Ф.А. Нәдершина әйтелгән өлкәнең Әлмән районын өйрәнсә, 2010 елда исә Г.Р. Хөсәенова җитәкчелегендәге төркем (экспедиция әгъзалары – Г.В. Юлдыбаева, Ф.Ф. Гайсина) Сафакүл, Әлмән районнарында эшли. Ә 2018 елда бу өлкәдә Н. Хөббетдинова, Г. Юлдыбаева, Ә. Салиховлардан торган төркем экспедициядә булып, яңа материаллар туплап кайтты.

Бу як кешеләре үзләре дә фольклорны теркәп һәм теркәтеп калдыруга зур өлеш кертканнәр. XX йөздән башлап татарларда яисә башкортларда халык иҗатының кайсы гына жанры буенча нинди генә җыентык чыкса да, аларда Урал артында гомер итүче халык вәкилләреннән язып алынган яисә аларда саклана торган язмалардан күчерелгән фольклор әсәрләрен очратырга мөмкин.

Татар һәм башкорт фольклорчылары XX йөзнең 30 нчы елларыннан бүгенге көннәргәчә туплап алып кайтып, басылып чыккан яисә архивларга урнаштырылып, фәнни әйләнешкә кертелгән материаллардан күренеүенчә, Курган өлкәсендә үзләренең борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын саклаган, үткәненә битараф булмаган җырлы-моңлы халык яши. Әйтик, әле алтмышынчы-җитмешенче еллар экспедияләрен барлаганда бу төбәктә төрле вариантта мәхәббәт дастаннары, бәетләр, озын һәм кыска көйгә лирик җырлар, мәкальләр, табышмаклар язып алынуы билгеле. Бу җәһәттән татар фольклорчылары бу яклардан табып алып кайтып, архивка тапшырган мәхәббәт дастаннары фольклор экспедицияләренең аерым бер саллы блогын тәшкил итә, шуңа бу истәлекләргә җентеклерәк тукталуны кирәк саныйбыз.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә «Кузы Көрпәч белән Баянсылу»ның Рәшит Ягъфәров тарафыннан магнитофонга язып алынган язмасы [Кузы Көрпәч..., 1979] һәм аның күчермәсе [Кузы Көрпәч..., сак. бер. 19], Асия Садыйкова язып алган «Кузы Күрпәс белән Майсылу» варианты [Кузы Көрпәс..., сак. бер. 33] саклана. Шушы ук Үзәктә дастанның 1966 елда «Кузы-Көрпәс һәм Маян Сылу» исеме белән Фәрит Йосыпов язып алган варианты да бар [Кузы-Көрпәс..., сак. бер. 7–15].

Киң таралган «Йосыф кыйссасы» әсәренең кырыктан артык варианты арасында икесе XX йөзнең 70 нче еллар азагында татар фольклорчылары тарафыннан Курган, Чиләбе өлкәләре информантларыннан язып алынган. Алардан Сабира Гайнетдиновадан (1907 елгы) Рәшит Ягъфәров язып алган вариант [Йосыф – Зөләйха] һәм Фаизә

Гобәйдуллинадан (1877 елгы) «Йосыф» дигән исем белән Асия Садыйкова язып алган текст [Йосыф] икесе дә – дастанның шактый төзек вариантлары.

Исеме мәгълүм тагын бер эпик әсәрнең – «Сәйфелмөлек»нең билгеле вариантларыннан берсен Институт тарафыннан оештырылган фольклор экспедициясендә 1979 елда Фаизә Зәбир кызы Гобәйдуллинадан (1877 елгы) Асия Садыйкова язып алган [Сәйфелмөлек]. Күләмле эпик әсәрнең әлеге вариантын алга таба әле моңа кадәр билгеләре белән чагыштырып өйрәнү перспективасы зур.

Болардан тыш, Урал арты – күп кенә төрки халыклар бик яратып иҗат иткән, бүгенге көндә үзбәк, уйгыр (4), азәрбайҗан (ике дистәдән артык), берничә төрек, казакъ, төрекмән версияләре, башкорт телендәге текстлар, татар вариантлары (дистәдән артык), Таһир белән Зөһрә турындагы популяр сюжетка корылган дастан вариантлары табылган өлкә. Курган өлкәсе татарларының да аңа бик борынгыдан ук битараф булмавы күп нәрсә хакында сөйли. Бу төбәктә 1966 елда Сабира Шәфикъ кызы Гайнетдиновадан (1907 елгы) Ф. Йосыпов [Таһир – Зөһрә], 1978 елда Сабира Гайнетдиновадан (1907) Рәшит Ягъфәров әлеге дастанның фабула характерындагы берәр вариантын язып алганнар [Таһир белән Зөһрә]. Моннан тыш, Институт архивында Фаизә Гобәйдуллинадан Асия Садыйкова язып алган вариант та саклана [Таһир белән Зөһрә, кассета № 1].

Фольклорчы Р. Ягъфәров 1978 елда хәзерге Курган өлкәсенә керә торган Сафакүл районында Нәгыймә Мөстәкыймовадан (1906 елгы) «Бүз егет»нең бер вариантын магнитофон тасмасына язып алган [Бүз егет, кассета № 2], аның язмача күчермәсен дә эшләгән [Бүз егет, сак. бер. 19–22].

Башкорт фольклорчылары туплаган материаллар арасында да эпик әсәрләр шактый, мәсәлән, 1970 елгы кыр тикшеренүчеләре «Йосыф менән Зөләйха», «Таһир менән Зөһрә», «Ләйлә менән Мәҗнүн», «Кузы Көрпәч менән Маянһылыу», «Бүз егет», «Таргын менән Кужак» һ.б. дастан вариантларына юлыгып, аларны яздырып алып кайтуга ирештеләр. Моннан тыш, Тарих, тел һәм әдәбият институты галимнәре Курган өлкәсенә уздырылган фольклор экспедицияләреннән шактый әһәмиятле кыйссалар, әкият, халык җырлары, мәкаль-әйтемнәр, туй йолалары, халык медицинасы, ышанулар, ырым-юраулар, төрле истәлек-тарихларга юлыгып торалар, әлеге жанр әсәрләрен халык сөйләменнән күпләп яздырып алып кайтуга ирешәләр.

2018 елның җәендә Курган өлкәсендә яшәүче төркиләрне, аерым алганда татар һәм башкорт авылларын барлап уздырылган экспедициянең максатын хәзерге буын кешеләрендә халык иҗатының ни рәвешле саклануын, аның яшәешен билгеләү, аларны үткән гасыр язмалары белән чагыштырып өйрәнү, башкорт һәм татар традицион фольклорын үзара мәдәни диалогта күзаллау тәшкил итте. Экспедициядә

катнашучылар Сафакүл районының Субботино, Мыррабай, Аккүл, Калмык-Әбдрәш, Абултай авылларында, Әлмән районының Тәңрекол, Шәрип, Падияс, Зәйнәкәй авылларында эш алып бардылар.

Экспедициядә башкорт галимнәре ясаган иң аянычлы нәтиҗә – Курган өлкәсендә күп кенә башкорт авылларының юкка чыгуы һәм әле исән дигәннәренең дә әкренләп бетә баруы. Элекке башкорт авыллары урынында бу урында авыл булганлыгы хакында мәгълүмат язылган ташлар гына тора. Бу, әлбәттә, кызганыч күренеш. Шунысы күңелдә өмет уята: биредә әле дә тереклек итүче башкорт телле халыкның күңел дәфтәрендә сакланып калган рухи хәзинәләр саегып беткән дия алмыйбыз. Иң күп җыелган жанр төре дип җырлар, такмаклар, туй йолалары, чеңләүләр, им-том, тыюлар, ышануларны санарга мөмкин. Әлбәттә, өлкән буын фольклорчылары язып алган мәгълүматлар белән чагыштырганда, халык иҗатының безнең гасыр башына килеп җиткән өлгеләре күпкә кайтыш. Күп жанрларның инде югалганлыгы күңелне борчый. Мәсәлән, ялан-катай башкортларында борынгы легенда, риваять сөйләрлек башкорт телле информантлар очрамый диярлек. Информант, иң күп дигәндә, җир-су атамаларының, авылларның исемнәрен әйтә, ә алар белән бәйле риваятьләрне инде хәтерләми. Алай да Зөһрә кыз турындагы легенданы искә алучылар бар. Халык иҗатының афористик төрләреннән табышмак, мәкаль, әйтемнәрне халык бик сирәк куллана. Бу – телнең ярлылана баруына бер ишарә. Башкортлар арасында күләмле эпик әсәрләрнең сакланышына килсәк, бүгенге көндә халык телендә бу жанрның кайбер сюжетлары гына яшәгәнлеге ачыкланды. Мәсәлән, 1959 елда Кирәй Мәргән тарафыннан Сафакүл районы Әптерәш авылында Әфләтунова Бәдернисадан язып алынган «Кузыйкүрпәс менән Маянһылыу» эпосын алыйк. Сафакүл районы Субботино авылында яшәүче информант – 1959 елгы Ратауллина Рәфүрә Әхмәдулла кызы (11 сыйныф белемле, 3 бала әнисе, мәдәният бүлегендә эшли) 2010 елда бу әсәрнең «аны элек олылар кичләрен җыелып утырганда сөйли торганнар иде», дисә дә, үзе эпосның кыскача эчтәлеген генә сөйләде. Шушы хәлдә булса да, мондый эпик истәлекнең халык телендә яшәве бик куанычлы күренеш. Моннан тыш, әле «Таһир менән Зөһрә»не дә белүче, дастаннан эпик җыр өзеген искә төшерүче, әсәрнең эчтәлеген сөйләп бирүче информантлар да очрый. Кайберләре, сөйли башлап та, «шуннан артыгы хәтеремдә калмаган», дип, сүзен тәмамлый. Сафакүл районы Ялан авылыннан Кадирова Бәдийән Сәйфелмөлөк кызы (1936 елгы) «Таһир менән Зөһрә»нең кыскача эчтәлеген сөйләп, кайбер урыннарын көйләп тә ишеттерде (2 сыйныф белемле, 7 бала әнисе, сыер савучы булып эшләгән).

Кызганычка каршы, элек язып алынган «Бүз егет», «Таргын менән Кужак» кебек эпик

әсәрләрне исенә төшерүче өлкән буын вәкилләре инде бу гасырга калмаган.

Монда шунысын искәртү мөһим: Курган өлкәсендә башкорт телле информанттан язып алынган фольклор ядкәренең, кагыйдә буларак, татар варианты да мәгълүм. Бер үк сюжетка корылган эпик әсәрне татарлар да, башкортлар да белә. Бу – телләрнең үтә якынлыгы, мәдәниятләр охшашлыгыннан килә торган нәтиҗә.

Курган өлкәсе башкорт халкы телендә «Һак менән Һук» (кайбер информант бәетне «Сак-Сук» тип тә исемли, бу – татарлар белән башкортларның тирән багланышта яшәп, телләрнең фонетик үзенчәлекләре ике тел өчен дә уртакка әверелүеннән килә булса кирәк) бәете яшәвен дәвам итә. Олы буын информантлар аны зур канәгатьлек белән кинәнеп көйләп башкаралар. Бу якларда бәетнең башкорт телле ике варианты кәгазьгә теркәлде. Мәсәлән, Сафакүл районы Субботина авылында Зарипов Хади Шәрит улыннан (1930 елгы, 3 сыйныф белемле, 3 бала атасы, тракторчы булып эшләгән) язып алынган вариант:

Елама, энкәй, нигә елайсың,
Үдең каргагач, үдең чыдайсың.
Калган киемне алып куярсың,
Исеңә төшкәч, алып иснәрсең.
Ишек алдында кошлар сайрыйдыр,
Балам кайда? – дип, эткәй сорайдыр.
Безне сорагач, энкәй елады,
Каргадым, дигәч, эткәй егылды.
Ни өчен? – диеп, эткәй сорады,
Ходай кушкандыр, дип, энкәй
уйлады.
Урман эчендә аю үкерә,
Ник каргадым? – дип, әнкәй үкенә.
Ризык ташыйлар кошлар басудан,
Әнкәй каргады, безне ачудан.
Каргап җибәрде, эшен бетерде,
Безләр кош булгач, үде үкенде.
Без киттек, энкәй, бәхил булыгыз,
Намаз артыннан дога кылыгыз.
Балам, балам, дип, энкәй елайдыр,
Ник каргадың, дип, эткәй әрләйдер.
Иртәдән очтык, кундык агачка,
Ниләр килмәде безнең бу башка.
Агачка кунгач, ярылды канат,
Эткәй, энкәйләр калдылар карап.
Алты яшьләрдә уйнап йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сук булдык без.
Су буйларында уйнап йөрдек без,
Сак-Сук булгач та дөнья гиздек без.
Аклы күлмәкне туя кимәдем,
Газиз энкәмне туя күрмәдем.
Кичләр дә була, иртә дә була,
Газиз энкәем, ни эшләдең, бичара.
Самавыр куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.

Башкорт фольклорчылары соңгы еллар экспедицияләрендә борынгы җырларга мөнәсәбәтле кызыклы мәгълүматларга тап булдылар. Информант җырны башкарып кына калмый, ә аның тарихын да сөйләп бирә. Мәсәлән, «Ашказар» җырының тарихы болай: Миәс аръягыннан бер сунарчы егет кәләш алып кайткан. Бердәнбер көнне ул, яшь кәләшен өйдә калдырып, ак бурзаен ияртеп, Ашказар күленә чәшкегә сунарга киткән. Көз көне булган бу хәл. Егет күлнең тобасына (туңмый калган урын) эләгеп, батып үлгән. Өйгә ак бурзае үзе генә кайтып килгән. Кайгысыннан яшь кәләш ни эшләргә дә белмәгән. Йөрәк әрнүенә түзә алмаенча, туганнарыннан егетенә

җыр багышларга рөхсәт сораган. «Ашказар» җыры – яшь киленнең җыры ул:

Яныкаем китте, әй, сунарга,
Әй-й-й-й, Ашказаркай күлгә лә
чәшкегә.
Чәшкеләргә китеп вафат булды,
Әй-й-й-й, башкынаем калды ла яшь
кенә.
Ашказаркай күлнең, әй, тобаһы,
Әй-й-й-й, аяз гына ла көндә туңсачы.
Бу хәсрәткәйләрне лә, әй, күргәнче,
Әй-й-й-й, бергә генә төшеп мин
үлсәмче.
Ашказаркай күлнең әй тобаһы,
Әй-й-й-й, Акбурзае килә лә, үзе юк.
Койрыкларын болгай, башын чайкай,
Әй-й-й-й, сөйләп кенә бирергә теле юк.
Иртәнчәккәй торып, чәйләр куйдым,
Әй-й-й-й, самавырым кайнай бит ел
белән.
Самавырым кайнап чәйләр салсам,
Әй-й-й-й, аны эчәрмен лә кем белән.

Җырны көй белән ишеттерүче һәм тарихын сөйләп бирүче – Сафакүл районы Ялан авылында яшәүче Бәдийән Сәйфелмөлөк кызы Кадирова (1936 елгы).

Бүгенге көндә мәдәни өлкәдәге уртак байлыклардан аерылган хәлдә яши торган бер генә халык та юктыр мөгаен. Бу мәсьәләдә татарлар һәм башкортлар гына чыгарылма була алмый, шуңа да бу ике тугандаш халыкның традицион мәдәниятен үзара бик нык керешкәнләгән танып, аларны ныклы бергәлектә генә карарга мөмкин. Россиянең Курган өлкәсендә яшәүче татарлар да, башкортлар да – бер-берсенә бик нык йогынты ясап яшәүче тугандаш ике милләт. Милли мәдәният, рухият, тел, гореф-гадәт, тарихи тамырлар – болар барысы да татарлар һәм башкортлар өчен уртак. Татарда булган фольклор жанры үрнәгенең гадәттә башкорт версиясе булмый калмый, бу – гаять табигый хәл. Хәлбуки, бу күренеш һәр халыкның рухи мирасын фәкать баета гына. Шуңа да безнең уртак сюжетлы дастан вариантларыбыз бик күп, бер үк бәетне татарлар үзләренчә, башкортлар яңа милли төсмерләргә баетып сөйли, бер үк җырлар җырлана, мәкаль-әйтемнәребез дә уртак һ.б. Фольклор жанры әсәрләренең татарлар өчен дә, башкортлар өчен дә үз милли версия-вариантлары булу – һич бәла түгел, бәла – боларның онытыла баруы. Фольклорчының бурычы – булганны бөртекләп җыеп, саклап калу, өйрәнеп, киләчәк буынга ирештерү.

Югарыда телгә алынган, татар һәм башкорт фольклорчылары тарафыннан төрле елларда экспедиция вакытында туплап алып кайтылган материаллар – барысы да фәнни оешмаларның архив фондларына тапшырылганнар. Ул төбәкләрдәге информантлардан язып алынган фольклор материалларының бер өлеше китап булып басылып чыккан, әлегәчә язып алып кайтылган килеш беренчел кульъязма хәлендә саклана торган истәлекләр дә бар. Курган өлкәсендә һәм аңа якын территориядә яшәүче яисә яшәгән милләттәшләребез иҗаты – гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөргән идеяләр белән сугарылган милли фольклор ядкәрләре. Шушындый истәлекләрнең Урал

арты информантлары авызыннан язып алынган булуы, һичшиксез, әлеге төбәк белән бәйле төркиләрнең уртак тамыры тирән, мәдәниятенең бердәй булуы хакында сөйли.

**Әдәбият**

Бүз егет // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, 1979, кассета № 2.

Бүз егет // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 90, папка № 2, сак. бер. 19–22.

Йосыф – Зөләйха // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, 1979, кассета № 2.

Йосыф // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сак. бер. 21 а.

Кузы Көрпәч белән Баянсылу // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, 1979, кассета № 1.

Кузы Көрпәч белән Баянсылу // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 90, папка 2, сак. бер. 19.

Кузы Күрпәс белән Майсылу // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сак. бер. 33.

Кузы-Көрпәс һәм Маян Сылу // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, колл. 99, сак. бер. 7–15.

Сәйфелмөлек // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сак. бер. 21.

Таһир белән Зөһрә // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сак. бер. 1–12, 13, 14, 15, 16–18, 18–21, 30–35, 36–37, 38; папка 2, сак. бер. 19–65; колл. 90, папка 1, сак. бер. 1–2, 19–65; колл. 99, сак. бер. 7–15 һ.б.

Таһир – Зөһрә // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, колл. 99, сак. бер. 7–15.

Таһир белән Зөһрә // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 91, папка 1, сак. бер. 21.

Таһир белән Зөһрә // Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 93, папка 1, сак. бер. 21, кассета № 1.

*Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ и Республики Башкортостан в рамках научного проекта № 18-412-020006 р_а «Межрегиональные контакты и диалог культур в материалах фольклорно-археографических экспедиций в регионах РФ»*

*Тикшеренү Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының һәм Башкортстан Республикасының финанс ярдәме белән «РФ регионнарына уздырылган фольклор-археографик экспедицияләр материалларында регионара контактлар һәм мәдәниятләр диалогы» дигән 18-412-020006 р_а номерлы фәнни проект кысаларында тормышка ашырылды*

***Хөббитдинова Нәркәс Әхмәт кызы,***
*филология фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе Уфа федераль тикшеренү үзәге федераль дәүләт бюджет гыйльми учреждениесе Почет билгесе орденлы Тарих, тел һәм әдәбият институтының әйдәп баручы гыйльми хезмәткәре*
*E-mail: narkas08@mail.ru*

***Юлдыбаева Гөлнар Вилдан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясе Уфа федераль тикшеренү үзәге федераль дәүләт бюджет гыйльми учреждениесе Почет билгесе орденлы Тарих, тел һәм әдәбият институтының өлкән гыйльми хезмәткәре*
*E-mail: nargul1976@list.ru*

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре.*
*E-mail: lilmuhat@mail.ru*

***Салихов Әхәт Гобәй улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясе Уфа федераль тикшеренү үзәге федераль дәүләт бюджет гыйльми учреждениесе Почет билгесе орденлы Тарих, тел һәм әдәбият институтының Көнчыгыш кульязмалар бүлеге мөдире*
*E-mail: ahatsalihov@mail.ru*

УДК 94

*Э.Г. Сәйфетдинова*

# АЛТЫН УРДА ПРИНЦЕССАСЫ ТУЛЫНБАЙ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

В статье рассматривается история брачного союза между мамлюкским султаном Мухаммадом ан-Насиром и княжной чингзидского рода Тулунбай и дальнейшая ее судьбе в мамлюкском Египте. Вопрос о политическом значении династических связей мамлюкских и золотоордынских правителей остается недостаточно изученным. Этот династический брак являлся скорее политическим актом с целью укрепления влияния одной страны на другую. В статье раскрываются основные моменты заключения этого брака и причины его распада согласно сведениям средневековых арабских летописей.

**Ключевые слова:** история, Золотая Орда, Египет, брачный союз, ан-Насир, Тулунбай.

Алтын Урда тарихында берничә династия никах белән бәйләнә. Алар арасында иң тантаналысы һәм серлесе мәмлүкләр солтаны ән-Насыйр һәм Алтын Урда кенәзе кызы Толынбай (Тулыбай) никахы була. Мисыр мәмлүкләре белән Алтын Урда арасында дипломатик мөнәсәбәтләр Алтын Урда белән Бәркә хан идарәлек иткәндә башлана. Мисыр белән ул вакытта төрки Барлы нәселеннән чыккан Бәйбарс исемле солтан хакимлек итә [Мохи ад-дин Албуллах…, с. 3].

Алтын Урда белән Үзбәк хан идарәлеге вакытында бу ике дәүләт арасындагы элемтәләр дипломатик яктан да, мәдәният өлкәсендә дә көчәя төшә. Мисырдан Алтын Урдага ислам белеме таратырга голәмәләр килсә, Алтын Урда кешеләре Мисырга белем алырга баралар. Үзара мөнәсәбәтләрне тагын да ныгыту өчен Алтын Урда әмирләре (аерым алганда Котлыг Тимер) үз ханнарына күрше дәүләтләр белән никах элемтәләре урнаштырырга тәкъдим итәләр. Әмма Үзбәк хан бу адымны тиз генә хәл итми, һәм шундый тәкъдимны Мисыр ягы үзе күтәрә. 1316 елда мәмлүкләр солтаны ән-Насыйр Чынгызханнар нәселеннән булган кайсы да булса бер кенәзнең кызын кодаларга Үзбәк ханга вәкил җибәрә. Алтын Урда ханы Үзбәк һәм илнең идарәче элитасы башта бу тәкъдимне кире кагалар, әмма, солтанның бүләкләрен алгач, ризалашалар һәм «1 000 000 динар, 1000 ат һәм тулысынча коралландырылган 1000 сугышчы» күләмендәге калым сорыйлар, шулай ук кәләшне озатканда аның белән бергә әмирләр һәм аларның хатыннары катнашында зур тантана оештырылырга тиешлеген дә белдерәләр [Тизенгаузен, с. 517]. Бу дәрәҗәдәге үк таләпләрне ишеткәч, мәмлүкләр солтаны ән-Насыйр кодалашудан баш

тарта һәм Алтын Урда илчеләре белән очрашканда бу хакта бүтән сүз кузгатмый.

Үзбәк хан Мисыр илчеләре белән бер очрашуында солтанга кенәз кызын бирергә ризалыгын белдерә һәм, шунда ук, сәүдәгәрләрен чакырып алып, алардан бурычка 20 000 динар ала. Тагын 7000 динарны илче Утуҗи Алтын Урданың күренекле шәхесләренә мәҗлес оештыру өчен ала. Кәләш итеп Тулынбай (Чынгызханның улы Җүчи, аның улы Чимбай, Чимбайның улы Хинду, аның улы Яку, аның улы Тукаҗиның кызы Дулынба һәм Тулыбай) билгеләнә [Тизенгаузен, с. 438–439]. Тулынбайның шәҗәрә чылбырын өйрәнүдән без шундый нәтиҗәгә килдек: ул Үзбәк ханның туганының кызы түгел, ә аның ике туганының кызы була. Аның әтисе – Үзбәк хан әтисенең ир туганы. Токты идарәлеге чорында ул җәзалап үтерелә, ә аның гаиләсе һәм милке Токтының ир туганы Бурлукка бирелә, шуңа күрә кайбер галимнәр Тулынбайны Бурлук кызы дип белдерәләр [Сабитов].

Туй тантанасына алар 1319 елның көзендә юнәләләр, әмма һава торышы яхшырганчы Константинополь хакиме Ласкарис янында тоткарланырга мәҗбүр булалар. Мисыр җиренә 1320 елның май аенда гына барып җитәләр. Тулынбай Мисыр шәһәре Александриягә үз даирәсендәге 400 кеше белән килеп төшә. Корабльдән Тулынбайны алтынсу йөгертелгән арба чатырга күчереп утырталар һәм Каирдагы солтан замогына китерәләр. Анда аңа солтан, гарәп тарихчысы ән-Нувәйри сүзләренә караганда, үзе уйлап, мөселман дәүләтендә әлегә кадәр тиңе булмаган чатыр төзеткән була [Тизенгаузен. с. 438–439]. Шул ук көнне никах килешүе төзелә, бик зур мәҗлес оештырыла һәм бүләкләр таратыла.

«Шул ук төнне ул аның белән никахка керә, әмма кызны ошатмый», – дип яза гарәп елъязмачысы әл-Мәкризи [ал-Макризи, с. 366]. Солтан иртүк торып Мисырның көньягындагы Сәгыйдкә китә. Солтанны бу адымга китергән сәбәп аңлашылмый, монда, мөгаен, ән-Насыйр солтанның Тогай исемле беренче хатыны үз ролен уйнаган булса кирәк.

Тулынбай ән-Насыйр солтан белән 8 ел яши һәм алар никахны өзәләр. Үзбәк хан биләмәләреннән әмир силахдар Сәйфетдин белән килгән Тулынбия хатын 1328 елның 6 сентябрендә солтан белән Миңлебуга никахы турында килешү төзи. Яңа никахка керү вакыты җиткәч, 1328 елның 14 сентябрендә солтан Миңлебугага өйләнә. Әмма бу никах озын гомерле булмый. Миңлебуга өч елдан, 1331 елда вафат була. Йола-гадәтләр буенча ирдән аерылган хатын никахсыз яши алмый, шуңа күрә Тулынбайны әмир Сусунга кияүгә бирәләр (аның туганы Кусун Мисырга Тулынбайның туй процессиясе составында килеп, югары дәрәҗәләр яулап өлгергән була).

Әмир Сусун вафатыннан өч ел үткәч, Тулынбайны солтанның наместнигы Аргун улы Гомәргә кияүгә бирәләр һәм ул аның белән гомеренең соңгы

көннәренәчә яши. Аргун Мисырның хакимлек итүче даирәсе төркемендә Александриядә Тулынбай процессиясен каршы алуда катнашкан була, шуңа күрә кенәз кызын яхшы белә. Шунысы гаҗәп, Тулынбай берничә мәртәбә никахта булып та, бала тапмый (күрәсең, ул бала тудыруга сәләтсез була). 1335 елда Үзбәк хан Алтын Урдадан Мисырга илчеләр җибәрә, ул ән-Насыйр солтанны кызы Тулынбайны аеруда гаепли, аны кире үз иленә кайтаруын таләп итә. Ән-Насыйр солтан аңа, Тулынбай вафат булды, дигән хәбәрне һәм Үзбәк ханга бүләкләрен җибәрә. Мондый җавап солтанның Алтын Урда белән мөнәсәбәтләрне катлауландырырга теләмәве беләнме, әллә Тулынбайның үзенең Алтын Урдага кире кайтасы килмәүдән бирелгәнме – билгеле түгел. 1939 елда Алтын Урдадан Мисырга тагын илчеләр килә, бу юлы алар ән-Насыйр солтаннан, Үзбәк ханга никахлашу өчен, кызын сорыйлар, мондый бәйләнеш ике ил арасында алга таба туганлык һәм дуслыкны ныгытырга ярдәм итәр дип уйлыйлар. Солтан аларның да үзе кебек гамәл кылу ниятен аңлап ала. Берничә көннән ул ханның илчеләрен үзенә чакырып китерә, һәркайсына чапан бүләк итә һәм шундый җавап яза: «Минем кызларым әле кечкенәләр, аларның иң өлкәненә дә алты гына яшь әле; никах яше җитүгә, Бөек Аллаһ кушкан булса, без аны киендереп аның (Үзбәкнең) ихтыярына җибәрәчәкбез». 1341 елда – ән-Насыйр, ә 1342 елда Үзбәк хан вафат булмаса, Тулынбай белән бәйле тарихи вакыйгалар ничек дәвам иткән булыр иде икән?..

Тулынбай үзе 1364 елның 20 гыйнварында вафат була, моны Каһирәдә саклanган кабер ташы дәлилли. Профессор Мерен сүзләренә караганда, бу һәйкәл, Тулынбай үзе исән чакта әйтеп калдырганча, мәрмәрдән эшләнгән [Melanges…]. Ул әл-Бәкри капкасы артына, ән-Насыйр солтанның беренче хатыны Тогай гыйбадәтханә янәшәсенә җирләнгән. Шулай итеп, Тулынбай Каһирәдә шактый озак еллар яши, аның заманында Мисырда да, Алтын Урдада да хакимнәр күп алышына.

Тулынбайның язмышы турындагы мәсьәлә ачык кала, аның мәмлүкләр Мисырындагы тормышы тәфсилләбрәк өйрәнүне көтә. Әмма Тулынбайның югары һәм хөрмәткә ия статусы аның «хонд» титулын йөртүе белән дә дәлилләнә, фарсы теленә тәрҗемә иткәндә ул бикә (байбикә) дигәнне белдерә (мәмлүкләр солтаны хатыннарын шулай атаганнар).

### Әдәбият


*ал-Макризи.* Китаб ас-сулук ли магрифат дувал ал-мамлюк. Каир, 1936. Т. 3. 566 с.

*Мохи ад-дин Абдуллах бин Абд аз-захир бин Нишван ал-Хазами ал- Масри.* Ар-рауда аз-захир фи сира ал-малик аз-Захир. Ар-Рияд, 1976. С. 3

*Сайфетдинова Э.Г., Гамаль Абдель Рехем И.Х.* Династический брак мамлюкского султана Египта ан-Насира и царевны Тулунбай по данным

средневековых арабских летописей // Zolotoordynskoe Obozrenie=Golden Horde Review, Vol.5, no.2 2017. pp. 116-125 DOI: 10.22378/2313-6197.2017-5-1.116-125

*Сабитов Ж.М.* Улусы джучидов в 1242–1266 годах // https://www.proza.ru/2012/03/20/1068

*Тизенгаузен В.Г.* Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т. I. Извлечения из сочинений арабских. СПб., 1884. 564 с.

Mélanges asiatiques, tirés du Bulletin de l'Académie impériale des sciences de St. Pétersburg. T. I–XVI. St.-Pbg., 1852–1892.

***Сәйфетдинова Эльмира Гаделҗан кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*М.Г. Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханнарын*
*тикшерену үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

***А.Ә. Зиннәтуллина***

# XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР БАЛАЛАРЫ АРАСЫНДА МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ УЗДЫРУ ТАРИХЫННАН

Настоящая статья посвящена мусульманскому национальному празднику Мавлюд. В статье дается краткий обзор истории проникновения праздника в Россию. Освещаются положительные и отрицательные моменты проведения его с детьми школьного возраста, влияние данного праздника на формирование личности. Учитывая тот факт, что в татарской среде такого рода детские праздники были организованы впервые, приводятся оценки и пожелания современников.

**Ключевые слова:** Мавлюд, пророк Мухаммед, Г. Исхаки, газета «Вакыт», джадидское движение, Багбостан, Восточный клуб, труппа «Сайяр».

Соңгы елларда совет дәверендә онытыла башлаган күп кенә милли йолалар, дини бәйрәмнәр, халык традицияләре торгызыла башлады. Шуларның берсе – Мәүлид бәйрәме.

Мәүлид бәйрәме (Мәүлид эн-Нәби) – мөселман дөньясында Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне буларак уздырыла торган бәйрәм. Мәүлид – гарәп сүзе, туу дигән мәгънәне аңлата. Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне билгесез булганлыктан, әлеге бәйрәмне аның үлгән көненә туры китереп үткәрәләр. Ул мөселман календаренең 3 нче ае – рабигыл-әүвәлнең 12 нче көненә туры килә [Мәүлид бәйрәме, б. 416]. Гомумән, «мәүлид» сүзе белән Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көненә бәйле булган чараларны атау гадәткә кергән. Мәсәлән, Рәсүлуллаһның тууына багышланган әсәрләрне «мәүлид», ул туган айны «Мәүлид ае», төнне «Мәүлид кичәсе» диләр.

Хәзерге көндә әлеге бәйрәм дәүләт җитәкчеләре, дин әһелләре, киң җәмәгатьчелек катнашында зурлап, тантаналар, концертлар, җыелышлар рәвешендә уздырыла. Дин белгечләре билгеләвенчә, революциягә кадәр Мәүлид бәйрәме башкачарак үткәрелгән. Ул, нигездә, өйдә узган, күбрәк анда хатын-кызлар катнашкан. Аның үз тәртибе, үз сценарие булган. Әлеге бәйрәмдә мәҗбүри үтәлергә тиешле төп шартларның берсе булып Мөхәммәд пәйгамбәргә мәдхия уку саналган.

Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә [Миңнегалиев, б. 102–106], Мәүлиднең чишмә башын Хәлифә хәзрәте Гомәр дәвереннән (634–644 еллар) үк эзләргә кирәк. Бу чорда Пәйгамбәрнең туган көненә багышлап, искә алу йолалары рәвешендәге чаралар уздырылмаса да, Пәйгамбәрнең «туган көне» төшенчәсен көн тәртибенә куеп, бу уңайдан аерым гамәлләр кылу

омтылышлары булган (мәсәлән, яңа календарь кертү уңаеннан булган сөйләшүләр вакытында ел башы итеп Пәйгамбәр «туган көн»не тәкъдим итү һ.б.).

Күпчелек мәгълүматларга караганда, Пәйгамбәребезнең туган көнен беренчеләрдән булып XII–XIII гасырларда Ирбил падишаһы Мәлик Мозаффар әбү Сәгыйть бине Гали билгеләп үтә башлаган. Ул Рәсүлуллаһка булган олы ихтирамы һәм мәхәббәте йөзеннән зур мәҗлесләр әзерләп, күп халык җыеп, кунак итүне һәм ярдәм йөзеннән сәдакалар бирүне гадәткә керткән. Шул мәҗлесләрдә Рәсүлуллаһны хөрмәт белән искә төшереп, «Мәүлид шәриф» касыйдәсе укып, салаватлар әйтә торган булганнар. Шушы күркәм гадәт күп кенә мөселман илләренә таралып, изге бәйрәмнәрнең берсенә әйләнеп киткән [Мәүлид бәйрәме, http://www.igelek.ru].

Россия мөселманнары арасына исә әлеге бәйрәмне үткәрү гадәте күпкә соңрак килеп кергән. Әлеге бәйрәм татарларда кайбер дин әһелләре Истанбулга, Мисырга барып укып, андагы мөселман гадәтләрен күреп кайткannан соң үткәрелә башлаган һәм ул, башлыча, төрек йолалары буенча уздырылган.

Белгәнебезчә, XX гасыр башында киң колач җәйгән җәдидчелек хәрәкәте нәтиҗәсендә татар мәгариф системасы зур үсеш ала, белем һәм тәрбия бирүнең яңа алымнары кулланыла башлый. Ял итү һәм белем эстәү максатыннан чыгып, балалар белән күмәк төстә милли бәйрәмнәр, әдәби кичәләр уздыру шундый яңалыкларның берсе булып тора. Балалар катнашында уздырылган әлеге чаралар, иң беренче чиратта, милли йолаларны торгызу, булганнарын саклап калу, татар халкында милли үзаңны һәм дини хисләрне ныгытуга булышлык иткән. XIX–XX гасырлар чигендә чит илләр, башка милләт халыклары белән икътисад һәм сәнәгать өлкәсендәге бәйләнешләр, җәдидчелек хәрәкәте киңрәк җәелгән саен арта барган мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге тәҗрибә алмашы һәм башка төрле күп кенә замана үзгәрешләре, милләтнең алгарышына этәргеч бирү белән бергә, күпмедер дәрәҗәдә милли ныклыкның йомшаруына, халыкларның көнкүрешенә башка илләрнең, башка милләтләрнең гореф-гадәтләре үтеп керүгә дә юл ачкан. Г. Исхакый [Исхаков, б. 6-7], мәсәлән, милли ныклыкның йомшаруының беренче сәбәбен татар халкының бөтен Россия территориясенә җәелеп, башка милләт халыклары белән аралашып яшәвендә күрә. Әлеге факторларның шәһәр халкына, бигрәк тә, шәһәр баласына йогынтысы зур дип саный. Язучы фикеренчә, «шәһәр балалары хәзер теле чыккач та, үзе кебек татар, мөселман балалары белән бергәләшеп «ат-ат», «куян куыш» уеннары уйный алмый, [...] гарәфә, кадер кичләрендә әнисенең чабуына тотынып, мулла абзыйларга китап ишетергә, вәгазь тыңларга бара алмый, [...] зур чалмалы, мәһабәт кыяфәтле мулла абзыйны еш-еш өендә күрә алмый. Ул гына да түгел, зур шәһәрләрдәге мөселман

баласы бик озакка кадәр азан тавышын ишетә алмый. [...] ул тирә-юнендәге башка халык бәйрәмнәрендә аларның балаларының матур киенүләрен, тәмле әйберләр берлән сыйлануларын күреп, аларның бәйрәмнәре аның күңелендә матур хис калдыра, баладагы иярченлек хисе берлән ул диндә башка балаларның дини гадәтләренә, дини горефләренә ияра башлый. Шулай итеп, аның күңелендә элгәреге әти-бабасындагы ныклык кими».

Әлбәттә, әйләнә-тирәдә яшәгән милләтләрнең йолаларын, гореф-гадәтләрен белү, алар белән дус-тату яшәү уңай күренеш. Ләкин бала үз халкының йолаларын онытмаска тиеш. Әлеге күренешне булдырмас, балага кече яшьтән дини рух, милли хис сеңдерү өчен XX гасыр башы татар зыялылары балалар белән дини бәйрәмнәр үткәрүне, олуг кешеләребезнең үлгән һәм туган көннәрендә балалар кичәләре ясауны бик отышлы күргәннәр [Әхмәрев].

XX йөз башында татар мәдәниятен таратуда иң якты эз калдырган оешмаларның берсе булып Казанда 1906 елның 21 декабрендә оешкан Шәрык клубы санала. Татар халкы өчен моңа кадәр хас булмаган күп кенә мәдәни-агарту чаралары беренче булып нәкъ әлеге клуб кысаларында оештырыла башлый. Мәүлид бәйрәме уңаеннан балалар кичәсе ясау гадәтен дә әлеге оешма башлап җибәрә. 1912 елның 16 февралендә клубта 260 бала катнашында шундый беренче кичә үтә [Миңнуллин, б. 54–55]. Алдагы елларда, Шәрык клубыннан үрнәк алып, мондый кичәләр Мәскәү, Оренбург, Троицк, Ташкент һ.б. шәһәрләрдә дә уздырыла башлый.

Әлеге кичәләр яшь бала күңеленә үтеп кереп, тирән эз калдырсын өчен оештыручыларга зур гына тырышлык куярга туры килгән. Бәйрәмгә берәр ай алдан әзерләнә башлаганнар. Өлкәннәр пьесалар өйрәнгән, балалар шигырьләр ятлаган. Бәйрәм узачак бүлмәләр төрле төстәге фонарьләр һәм флаглар белән бизәлгән. Стенага ай һәм йолдыз сурәтләре, котлау сүзләре язылган плакатлар эленгән [Оренбург хәбәрләре]. Бәйрәмгә балалар матур итеп киенеп килгәннәр. Мәсәлән, Оренбургта узган бәйрәмдә кыз балалар һәркайсы ак киемнәр киеп, бер төстәге бантлар такканнар [Оренбург хәбәрләре]. Тагын шунысы игътибарга лаек: төрле оешмалар тарафыннан оештырылган Мәүлид бәйрәмендә ир һәм кыз балалар бергә катнашканнар. 1915 елда Мәскәүдә беренче тапкыр үткәрелгән балалар кичәсендә 250 ир һәм кыз бала катнашуы билгеле [Хәтимә-Нәзифә].

Бу чорда кызлар өчен җәдиди мәктәпләр киң таралу сәбәпле, мәүлид кызлар мәктәпләрендә дә билгеләп үтелә башлый. Ул тиз арада халык арасына таралып, зур бәйрәм төсен ала. Мәсәлән, Оренбург шәһәренең танылган мөгаллимәсе Багъбостан ханым 1915 елның 15 гыйнварында, Мәүлид бәйрәме уңаеннан, уку мәҗлесе һәм балалар ахшамы үткәрә. Әлеге чара, иртәнге сәгать унда башланып, соң кичкә кадәр дәвам итә.



Оренбургта атаклы мөгаллимәләребездән Багъбостан ханым кызлар мәктәбенең «Мәүлид» бәйрәме мөнәсәбәтилә уку мәҗлесенә иштирак иткән ибтидаи талибәләрнең бер бүлеге // Сөембикә, 1915. № 11. Б. 9

Иртән өлкәнрәк яшьтәге ханымнар өчен уку мәҗлесе була. Монда Багъбостан ханым Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрҗемәи хәле, кылган изгелекләре турында сөйли, ә ярдәмче мөгаллимәләр башка дини һәм гамәли чыгышлар ясыйлар. Соңыннан мәктәп шәкертләре бу көн өчен махсус өйрәнгән шигырьләр һәм декламацияләр укыйлар. Кич сәгать алтыдан сигезгә кадәр балалар ахшамы ясала. Ахшам вакытында да алдан Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрҗемәи хәле һәм аның мактаулы эшләре турында сөйләнә, балалар хор белән дә, аерым-аерым да бу көнгә багышланган шигырьләр укыйлар. Ахырдан Мәрьям Габидуллина һәм Рабига Камаловалар мәктәптә укыган балалар өчен чәй мәҗлесе оештыра [Оренбург хәбәрләре].

Мәгълүм булганча, әлеге кичәләр, бәйрәм рухыннан тыш, өстәмә белем бирү формасын алып, укучы балаларга, аларның әниләренә, мәктәп яшеннән узган туташ һәм ханымнарга файдалы гыйлем тарату чарасына да әверелгәннәр. Мондый кичәләрне халык көтеп алган һәм бик теләп йөргән. «Сөембикә» журналы хәбәр итүенчә, Багъбостан ханым уздырган әлеге мәҗлескә килүче ханымнар шул кадәр күп булган ки, кунаклар арасында мәктәп бинасына сыймыйча, бәйрәмнән мәхрүм булып китүчеләр дә булган [Оренбург хәбәрләре]. Хатын-кызларның мондый төр фәнни-гамәли мәҗлесләргә йөрүе киң җәмәгатьчелек тарафыннан да хуплана, газета битләрендә түбәндәге эчтәлекле мәкаләләр бастырыла: «Хәзер инде алар [хатын-кызлар – *А.З.*] үзләренең кызлар мәктәпләрендә аерым мәүлид укыйлар [...], үзләрен гыйльми бер мәҗлесләрдә күрәләр.



Оренбургта атаклы мөгаллимәләребездән Багъбостан ханым кызлар мәктәбенең «Мәүлид» бәйрәме мөнәсәбәтилә уку мәҗлесенә иштирак иткән рөшдия талибәләренең бер кыйсеме // Сөембикә, 1915. № 11. Б. 11

Үзләренең бүлмәләреннән чыгып өйрәнмәгән татар хатыннарының бәйрәмнәргә иштирак итеп *(бергәләшеп)* өйрәнүләре, тәртип вә тәрбия күрүләре, үзләренең укыган кызлары белән бер сафта торып Рәсүлуллаһка ихтирам итүләре, әлбәттә, боларның рухларына тәэсирсез калмас» [Уфадан].

Әлеге изге эштән хәйрия җәмгыятьләре дә читтә калмаган. Мәсәлән, 1915 елның 14 гыйнварында Мәскәүнең «Хатын-кызлар хәйрия җәмгыяте», Мәүлид бәйрәме уңаеннан, Татар мәктәбендә әдәби кичә үткәрә. Әлеге мәҗлес хакында Г. Исхакый үзенең уңай фикерен белдерә, ләкин шул ук вакытта: «кичәгә башка мәктәп балалары да чакырылса иде. Һәм дә мәктәп күрүдән мәхрүм булган мөселман баласына кичәнең ишеге ачык ителсен иде вә аларның да боек, мескин тормышларында шул газиз көн аллы-гөлле матур, якты хис калдырсын иде», – дигән тәкъдимнәрен дә җиткерә [Исхаков, б. 7].

XX гасыр башы галимнәре, Мәүлид бәйрәменең татарлар арасына чагыштырмача яңа килеп кергән гадәт булуын ассызыклап, мәүлид көннәрен билгеләп узу гадәтенең әлегә формалашып кына килүен искәртәләр. Бу көннәрдә мәчет-мәдрәсәләрдә укырга гарәп, төрек телләрендә язылган әдәбият булса да, татар балалары өчен татар телендә язылган «шигырьләребез [...], халыкка рух бирерлек махсус китапларыбыз, махсус вәгазьләребез юк», – диләр [Шәрәф, б.30]. Әлеге сүзләрне дәлилләп, түбәндәге мисалны китерергә була. 1915 елда Мәүлид бәйрәме уңаеннан Шәрык клубында үтәчәк балалар кичәсенә әзерлек вакытында



Троицкида Мәүлид мөнәсәбәте белән Йосыфҗан әфәнде Учаров өендә ясалган балалар кичәсенә иштирак итүче туташларның рәсемедер. Арада берничә ир балалар да бар // Сөембикә, 1915. № 8. Б. 10

«Сәйяр» труппасы, балалар өчен татар пьесалары булмау сәбәпле, бер айга якын русчадан тәрҗемә ителгән «Среди цветов» пьесасын өйрәнә. Ләкин кайбер дин әһелләре әлеге пьесаны уйнарга рөхсәт бирмиләр. Нәтиҗәдә, труппага бер-ике көн эчендә «Кызлар шулай кызык итә» пьесасын балалар карарлык дәрәҗәдә үзгәртеп, шуны куярга туры килә [Фоад]. «Мәктәп» газетасы битләрендә «Мәүлид ае мөнәсәбәте илә» исеме белән басылып чыккан мәкалә авторы, татарларга бу бәйрәмнең үз йолаларын булдырырга кирәк, дигән фикердә тора. Бу эштә иң зур файда китерерүче кешеләр сыйфатында ул яшь имамнарны һәм дөньяви белем бирүче мөгаллимнәрне күрә. «Мөгаллимнәр кул астында булган балаларны җыеп Коръәннән бәгъзе аятьләрне, салават шәрифне, Мәүлидкә мөнәсәбәтле милли шигырьләрне вә шул көнгә муафыйкъ вәгазь вә хөтбә сөйләргә тиешләрдер. Имамнарга ошбу хөрмәтле көндә халыкны мәчетләргә җыеп Рәсүлуллаһ(с.г.в.)ка, исламга мәхәббәт арттырырлык, дини хисләрне кузгатырлык, халыкка вә гайрәт бирерлек вәгазьләр сөйләргә тиешдер», – ди автор [Шәрәф, б. 30].

Милли газета-журнал битләрендә алда искә алынган мәкалә авторына кушылып, бәйрәмгә тагын да миллилек өстәү максатыннан чыгып язылган башка мәкаләләр дә очрый. Мәсәлән, Мәскәү шәһәрендә яшәүче мөгаллимә, Мәскәү мөслимәләр комитеты рәисе Хәтимә-Нәзифә ханым мондый мәҗлесләрдә күбрәк үз халкыбызның гореф-гадәтләрен кулланып, хәтта табын әзерләгән вакытта да милли ашларга, милли ризыкларга өстенлек бирүне хуп күрә.

Мәскәүдә узган Мәүлид бәйрәмендә әлеге мәсьәләгә игътибар бирелмәгәнгә пошынып ул: «Казан, Уфа кебек шәһәрләрне алсак, анда бәгъзе һиммәтле *(кайгыртучан)* ханымнар кулларыннан килгән кадәр ни дә булса шундый милли мәҗлесләргә берәр нәрсә пешереп китерәләр. Шунлыктан милли мәҗлесләр үземезнең кулдан чыккан милли аш исенә буялып, бигрәк тә нур өстенә нурлы булып чыга. Әгәр безнең Мәскәү ханымнары да бу юлда бераз үзләренең хезмәтләрен кызганмый ни дә булса хәлдән килгәнчә: кайсы алма бәлеше, кайсы варенье, кайсы башка нәрсәләр китергән булсалар, балалар кичәмез дә тәнкыйтькә хөҗҗәт төшмәслек *(дучар булмаслык)* дәрәҗәдә матур, рухлы чыккан булыр иде. [...] балалар да [...] үземездә пешкән ашларны ашап кичә хакында үзләрендә әлегә караганда әллә ничә өлеш артык хатирә калдырырлар иде. «Филипповлар» берлә «Чуевларның» күмәч-сохарилары никадәр яхшы булса да, үзеңдә пешкән аш ләззәтен бирә алмый», – дип яза. Шул ук вакытта, мәҗлес үткәрүнең финанс ягын да истә тотып, үз кулың белән пешергән әйберләрнең ике тапкыр арзангарак төшәчәген дә искәртеп уза [Хәтимә-Нәзифә].

Шулай итеп, XX гасыр башында татар халкы арасында Мәүлид бәйрәме уздыру гадәте, акрынлап, балалар аудиториясенә дә үтеп керә башлый. Әлеге кичәләр, әйләнешкә яңа гына керә башлаган гадәт булуга карамастан, балалар арасында милли гореф-гадәтләрне таратуда, милли үзаңны уятуда зур роль уйныйлар һәм, шул ук вакытта, өстәмә мәгълүмат тарату үзәкләренә дә әвереләләр.

**Әдәбият**

*Әхмәрев Ш.* Балалар кичәсе // Йолдыз, 1912. 3 гыйнвар.

*Исхаков М.Г.* Мәүлед бәйрәме: Әсәрләр: 15 томда. Т. 7. / төз.: Ф. Ибраһимова, З. Рәмиев, Э. Галимҗанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 366 б.

Мәүлид бәйрәме тарихы http://www.igelek.ru/мәүлид-көне/ (05.07.2018)

*Миңнегалиев Р.* Мәүлид бәйрәме һәм аның тарихы // Чын Мирас, 2013. № 2. Б. 102–106.

*Миңнуллин Җ.* Шәрык клубы: тарихи очерк. Казан: Заман; Татар. кит. нәшр., 2013. 95 б.

Оренбург хәбәрләре. Багъбостан ханым мәктәбендә уку мәҗлесе һәм балалар ахшамы // Вакыт, 1915. 20 гыйнвар.

Мәүлид бәйрәме // Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедиясе Институты, 2002. Б. 416.

Уфадан // Ил, 1915. 23 гыйнвар.

*Фоад М.* Казанда балалар кичәсе // Ил, 1915. 21 гыйнвар.

*Хәтимә Нәзифә.* Мәскәүдә балалар кичәсе // Ил, 1915. 18 гыйнвар.

*Хәтимә-Нәзифә.* Балалар кичәсендә җитешмәгәнлек // Ил, 1915. 28 гыйнвар.

*Шәрәф Ш.* Мәүлид ае мөнәсәбәт илә // Мәктәп, 1914. № 2. Б. 29–31.

***Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы,***

*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*

*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 372.8

*Л.Р. Мортазина*

# МӨХӘММӘТЗЫЯ БӘХТИЯРОВ – ДӘРЕСЛЕКЛӘР ҺӘМ КУЛЪЯЗМА КИТАПЛАР АВТОРЫ

В статье анализируются рукописные и печатные книги , а также учебники педагога и религиозного деятеля Мухамметзии Бахтияровича Бахтиярова (1877–1974). Определяются теоретические и методологические основы составления учебников арифметики, астрономии, написанных для татарских медресе, также их новизна. Описывается основное содержание ранее неизвестных рукописных учебников М. Бахтиярова (букваря и книги по истории Новой Смаили). В статье также дается краткая информация о жизнедеятельности автора.

**Ключевые слова:** просвещение, учебники, татарское медресе, арифметика, астрономия, медицинские знания, календарь, рукописная книга, букварь.

Күпгасырлы тарихка ия булган татар мәдрәсәләрендә шактый нигезле һәм төпле белем бирелүе яхшы билгеле. Аларда, дини гыйлемнәр белән беррәттән, дөньяви белемгә дә зур игътибар мәгълүм. Югарырак сыйныфларда укучылар үзләре дә педагогик процесста катнашу, түбәнрәк сыйныф укучыларына белем бирү мөмкинлегенә ия булганнар. Күп кенә мәдрәсә шәкертләре кулъязма китаплар күчереп язу белән шөгыльләнгәннәр. Татар хаттатларының даны ерак кыйтгаларга таралган. XIX гасыр ахырларында, җәдитчелек хәрәкәте таралу белән, шәкертләр арасында фәнни һәм көндәлек тормышның төрле якларын яктырткан кулъязма китап һәм дәреслекләр язучылар да күренә башлый. Татарларда аеруча медицина гыйлеме белән кызыксынучылар күп булган. Мисал өчен, Казан губернасының Юртыш авылыннан Сәгыйдь бине Мостафа Юртышиның шәкертлек чорында ук кулъязма



Мөхәммәтзыя Бәхтияров

«Тыйбб китабы» язуы билгеле [Мөсәгыйдь]. Кайбер шәкертләрнең дәреслекләре хәтта басылып та чыккан, бу исә аларны аерым мәдрәсәләрдә генә түгел, бәлки гомумән уку-укыту барышында киңрәк куллану мөмкинлеген тудырган. Мәдрәсәдә уку чорында ук дәреслекләр язып бастырган шундый авторларның берсе – Мөхәммәтзыя Бәхтияров.

Мөхәммәтзыя Бәхтияр углы Бәхтияров 1877 елның 28 февралендә Казан губернасы һәм өязе Мәмдәл авылының мәшһүр имам-хатыйбы, Казан һәм Чар (Царевококшайск) өязләре татар авылларында яхшы билгеле мулла, дин гыйлеме буенча китап авторы Бәхтияр әл-Мәмдәли (Бәхтияр Габделҗәлилов әл-Мәмдәли; бу авторның моннан тыш та кулъязма китаплары булганлыгы мәгълүм, ләкин, кызганычка каршы, алар сакланмаган) һәм Бибифаизә Мөхәммәтсадыйк кызы гаиләсендә дөньяга килә [Татарстан..., б. 176]. 1899 елда Түнтәр мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (Ишмөхәммәт әт-Түнтәридә белем ала) [Бәхтияр, 1898, б. 68], Уразай авылында Гариф хәзрәттән русча белем алып, шуның буенча 1900 елда Казанда имтихан тота, 1901 елда Вятка губернасы Малмыж өязе Сәрдекбаш волосте Яңа Смәил авылының (хәзерге көндә бу авыл Киров өлкәсенең Малмыж районына карый) имамхатыйбы итеп билгеләнә. 1903 елның 7 октябрендә Вятка губерна идарәсендә 1267 номерлы «указ» алып [Киров, б. 48], Мөхәммәтзыя Бәхтияр улы 25 октябрьдән муллалык итүгә керешә. Һәм 70 елдан артык гомерен әлеге вазифаны үтәүгә багышлый, авылдашлары арасында гына түгел, тирә-юнь авылларда да үзен белемле, мәгърифәтле дин белгече, мөгаллим, тәрбияче һәм табиб буларак таныта, берничә китап һәм дәреслек авторы буларак XX гасыр татар мәгарифе тарихында эз калдыра.

Түнтәр мәдрәсәсендә укыган дәверендә Мөхәммәтзыя Бәхтияров ике китап язып тәмамлый (берсенең кулъязмасы КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана) [Бәхтияр, 1897], озакламый аларны бастырып та чыгара. 1898 елда Казан университеты типо-литографиясендә «Каванин әл-хисаб» (арифметика) [Бәхтияр, 1898], 1903 елда бертуган Кәримовлар типографиясендә «Горрәи даими» («Мәңгелек календарь») [Бәхтияр, 1903] исемле китаплары дөнья күрә.

«Каванин әл-хисаб» – башлап өйрәнүчеләр өчен татар телендә язылган арифметика китабы. Альберт Фәтхи тарафыннан әзерләнгән «Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары» тасвирламасына кертелгән [Кулъязмалар..., б. 77] әлеге дәреслекнең методик һәм бер үк вакытта фәнни яктан да нигезле, камил булуы шик тудырмый.

Китап ике мөстәкыйль өлештән – хезмәттән гыйбарәт. Беренче өлеш «Каванин әл-хисаб» дип атала һәм шәкертләргә арифметика буенча белем бирүне максат итә. Ул шактый катлаулы, фәнни дәрәҗәдә язылган булуы белән аерылып тора. Гомумән алганда, дәреслек татар телендә булса да, төп төшенчәләр гарәп телендә бирелгән. Шуңа күрә аны гарәп телен азмы-күпме белгәннәр генә файдалана алган, димәк, дәреслек белән эшләү өчен билгеле бер дәрәҗәдә тел ягыннан әзерлекле булу таләп ителгән. Дәреслектә бөтен саннар, кушу, алу, тапкырлау, бүлү, тамыр, вакланмалар, пропорция, градус, дуга

кебек төп математик терминнар аңлатылган, мәсьәләләр һәм күнегүләр тәкъдим ителгән. Арифметиканың беренче дүрт гамәле европача түгел, ә бәлки бу чорда мөселманнарда кабул ителгәнчә борынгы гарәп ысулы белән тасвир ителә. «Авторның төп максаты, – дип яза татарларда математика белеме үсеше тарихын өйрәнгән галим В. Беркутов, – арифметиканың әзер, күп очракта берни белән дә аңлатылмый торган ысул һәм кагыйдәләрен көндәлек тормышта кирәкле иң гади биремнәрне чишүдә файдаланырга өйрәтүдән гыйбарәт» [Беркутов, б. 61]. Димәк, әлеге әсбап мәдрәсә шәкертләренең алган гыйлемнәрен тормышта файдалану мөмкинлеген дә арттырган.

Китапның икенче өлеше «Рисаләи зыяия фи гамәле би-р-робгъ әд-дәстүрият» (астрономия) дип исемләнгән. Автор үзе аны рисалә дип атый. Бу китап М. Бәхтияровның шәкертлек чорында астрономия белән фәнни кызыксынуларының үзенчәлекле нәтиҗәсе булып тора. Чөнки, билгеле булганча, Түнтәр мәдрәсәсендә астрономиягә шактый зур игътибар бирелгән. Мәдрәсә мөдәррисе Шәмсетдин хәзрәтнең телескопы булуы, аның шәкертләре белән ай-йолдызларны күзәтергә яратуы, һәйят (астрономия) дәреслекләре алдыруы турында хатирәләр сакланган [Балтач..., б. 409].

«Рисаләи зыяия фи гамәле би-р-робгъ әд-дәстүрият» хезмәтендә «робгы мөҗиб» исемле җиһаз (почмак үлчәгеч) ярдәмендә вакытны ничек билгеләү хакында сөйләнә, һәм, иң әһәмиятлесе, татарча язылган астрономия дәреслекләрендә беренче тапкыр буларак, аның рәсеме бирелә. Китапта төш вакыты, кояш чыгу, кояш бату кебек күренешләргә аңлатма бирелә. Моңа кадәр дөнья күргән арифметика дәреслекләрендә мондый геометрик һәм астрономик мәгълүматлар очрамый [Беркутов, с. 61]. Рисалә кереш сүздән (мөкаддимә), 10 бүлектән (баб) һәм соңгы сүздән (хәтимә) тора. Бу әсбап фәнне тормышка яраклаштыру, якынайту принцибына хезмәт итүе ягыннан кыйммәтле.

М. Бәхтияровның алдагы ике хезмәте белән бәйле рәвештә дөньяга килгән тагын бер китабы – «Горрәи даими» («Мәңгелек календарь»).

Календарьлар, билгеле булганча, кешелек тарафыннан уйлап табылган иң борынгы хикмәтләрнең берсе. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында календарьларны «горрәлек» (гарәп теленнән «яңа ай туу, таң» дигән мәгънәне аңлата) дип атаганнар. Горрәлекләр яңа ай туу һәм, гомумән, елның теләсә кайсы көнен (кояш чыгышын, көн озынлыгын һ.б.ны) билгеләргә мөмкинлек биргән [Зайни, с. 46]. Халык арасында бу төр басмалар бик популяр була.

Календарьлар төзү һәм аларны бастырып чыгару белән гадәттә муллалар, язучылар, типография хезмәткәрләре шөгыльләнгән. Билгеле булганча, беренче татар календаре 1841 елда басылып чыга. «Горрәлек» дип аталган әлеге кулланманың авторы Рәхмәтулла Әмирханов була [Татар..., б. 306]. Ул 40 елга

исәпләп төзелгән. Хәзерге календарьлардан аермалы буларак, XX гасыр башында татар календары 40 елга, 25 елга, 12 елга, 1 елга һәм 1 айга төзелгән [Миңнуллина, б. 15]. Шулай ук даими календарьлар да булган. Башка төр басмалардан (мәсәлән, К. Насыйриның фәнни-популяр, Ш. Шәһидуллин яки Ф. Халидинең әдәби, тарихи, шәхесләргә һ.б.га багышланган материаллар кертелгән гамәли календарьларыннан) аермалы буларак, даими (мәңгелек) календарьларда өстәмә мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә, һәм алар, беренче чиратта, вакыт исәбен дөрес билгеләүне максат итәләр. Мондый календарьлар бигрәк тә намаз вакытын билгеләү өчен кирәк булган.

М. Бәхтияровның искә алынган календаре вакыт исәбен күрсәтүче җәдвәлдән гыйбарәт. Анда һәр айга (ел март аеннан башлана) махсус бит билгеләнгән. Көн хисабы таң беленү, кояш чыгу, икенде вакыты керү, кояш баю, ясигъ вакыты керү дигән бүлекләрдән гыйбарәт. Соңгы баганада көн озынлыгы күрсәтелгән. Календарьга кереш сүзендә автор намаз вакытларын дөрес билгеләүнең әһәмиятен ассызыклый. Автор намазның төгәл вакытын белми торып (ягъни, үзе әйткәнчә, «бу фәнне игътибарга алмыйча»), фәкать башкаларга ияреп кенә укуга тискәре карашын белдерә. «Сәгатьне дөрес итмичә, горрәлектән файда алып булмаячагын» искәртеп, үзенең моңарчы дөнья күргән «Каванин әл-хисаб» китабында тасвирланган «робгы мөҗиб» җиһазын искә ала, аның ярдәмендә кояшның биеклеген белеп, шул тәртип белән сәгатьне дөресләү мөмкин, ди [Бәхтияр, 1903, б. 2]. М. Бәхтияров, зәвәл, ягъни кояш баюга авышу вакытын робгы мөҗиб ярдәмендә белеп, вакытны билгеләргә мөмкин, ди. «Ләкин, – дип яза ул, – зәвәл вакыты озынрак булып, моны бик дикъкать белән белмәк мөмкин була. Кояшның югарылыгын, ягъни тәмам күтәрелеп җиткән вакытын дикъкать белән карап торылыр». Әмма бу календарьда ул зәвәл вакытын күрсәтми, бу мәсьәләдә фикерләр төрле булуны искәртә, һәм аны икенче китабында ачыкларга вәгъдә бирә [Бәхтияр, 1903, б. 3]. Кызганычка каршы, мондый календарь дөнья күрми. Кабат бу мәсьәләгә автор 1961 елда язып тәмамланган кулъязма китабында туктала.

Бу китапларны язган вакытта Зыя Бәхтияров, кирәкле киңәшләр алу максаты белән, Казанга атаклы гыйлем иясе, энциклопедик галим, педагог Каюм Насыйри янына килеп йөри. Каюм баба (укучылары аны шулай йөрткәннәр) гыйлемнең бик күп өлкәләреннән хәбәрдар, күп укыган, Шәрык һәм Европа галимнәренең фәнни трактатлары, мөселман мәдәниятенең гуманистик традицияләре һәм әл-Фәраби, Әбүгалисинә, Ибне Рөшд, Алишер Нәваи кебек бөек акыл ияләренең хезмәтләре белән яхшы таныш була. Насыйри татарларга дөньяви белемнәр бирүне алга сөрә. Шул максаттан фәннең төрле тармаклары – математика, география, химия,

астрономия, медицина, тел гыйлеме, фольклор һ.б. буенча дәреслекләр язып бастыра, сүзлекләр төзи. К. Насыйри Көнчыгыш галимнәренең һәм язучыларының хезмәтләрен, әдәби әсәрләрен өйрәнеп, аларны татар теленә тәрҗемә итә, шуларга ияреп, китаплар яза. Аның медицина белән тирәнтен кызыксынуы да, беренче чиратта, әлеге хезмәтләр тәэсирендә булырга мөмкин. Ләкин ул шул фәнни белемнәрне популярлаштыра, халык арасында тарата алган, шулай итеп, беренчедән, татар фәне үсешенә өлеш кертсә, икенчедән, бу белемнәрне көндәлек тормышта файдалануга юл ачкан.

К. Насыйри янына белем эстәү нияте белән бик күп шәкертләр, акыл ияләре килеп йөри торган булган. Түнтәр мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәтзыя Бәхтияринең Каюм Насыйри янына килүе дә, әлбәттә, киңәш һәм инде шактый язылган китабын тәмамлап, аны дөньяга чыгаруга хәер-фатыйха алу белән бәйле була. Белем, мәгърифәт нурын таратуны төп бурычы итеп алган Габделкаюм ага үзе янына белемгә сусап килгән яшь шәкертне бик теләп, шатланып каршы ала. Мөхәммәтзыя Бәхтияров бу турыда үзе дә: «Гыйльми мәсьәлә турында үзеннән киңәш сорап килүемә бик кәефе килде. – Менә бу “Фазаиле мадани” дигән китап. Син үзеңә кирәкле мәсьәләләр турында шуннан җавап таба аласың, – дип, китапның аерым битләрен миңа укып һәм аңлатып бирде», – дип истәлекләрендә язып калдыра [Зыя..., б. 145].

К. Насыйри янына ул беренче китабы басылып чykканнан соң да килгәләгән. Аны бигрәк тә К. Насыйриның календарьлар язу һәм медицина (тыйбб белеме) өлкәсендәге гыйлемнәре кызыксындыра. М. Бәхтияринең «Горрәи даими» календаре басылып чыкканда К.Насыйри үзе исән булмый инде.

Фаразлавыбызча, Мөхәммәтзыяның тыйбби кызыксынулары формалашу аның мәдрәсәдә укыган чоры белән бәйле. Түнтәр мәдрәсәсендә медицина белемнәренә игътибар шактый зур була: мөдәррис Гали Сәйфуллинның Бохарада укуы, Әфганстан, Һиндстан, Тибет якларында булуы [Мәрҗани, б. 339], үләннәр белән дәвалау ысулларын яхшы белүе, үләннәрдән төрле кайнатмалар һәм майлар ясавы, янына дәвалану өчен ерак җирләрдән килүләре, оныгы Мөхәммәтнәҗипнең дә шулай ук медицина белән кызыксынуы, бабасының эшен дәвам итүе билгеле [Зарипов, б. 7]. Икенче бер мөгаллим – Шәмсетдин мулланың исә, башка өлкәләр белән беррәттән, тыйбб белеме (медицина) буенча да бик күп фәнни китаплар, дәреслекләр туплавы, Төркиядән, Урта Азиядән газеталар алдыруы турында мәгълүматлар сакланган. Алар киңкырлы белемнәрен шәкертләренә дә тапшырырга тырышканнар [Балтач..., б. 409].

Каюм Насыйри, икенче бер бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани кебек үк, фәнни медицинаның файдасы турында язган, төрле авыруларны дәвалау юлларын эзләү белән дә шөгыльләнгән. Иң үтемле дәва

чарасы итеп дару үләннәрен санаган. 17 ел дәвамында басылып килгән календарьларында галим анатомия, физиология, гигиена турында шактый җентекле мәгълүматлар биреп барган, төрле шифалы үләннәрнең сихәте һәм аларны төрле авырулардан дөрес файдалану турында киңәшләр урнаштырган.

Каюм Насыйри белән аралашкан елларда яшь Зыя (Мөхәммәтзыя) мулла авыруларны дәвалау ысуллары, шифалы үләннәрне файдалану буенча шактый бай белем туплый, остазы биргән китапларны җентекләп өйрәнә. «Аерым авыруларны ничек дәваларга кирәклек турында ул авыл врачлары белмәгән нәрсәләрне белә һәм шул турыда бик яхшы киңәшләр бирә иде. Күбрәк үләннәр белән дәвалау кирәклек турында сөйли иде», – дип искә ала ул остазы турында [Зыя..., б. 145].

Ләкин медицина буенча белемнәрне М. Бәхтияров К. Насыйридан гына алгандыр дип уйлау бик үк дөрес булмас. Татарларда тыйбб белеме белән кызыксыну бик борынгы заманнардан килә. Идел Болгарында ук авыруларны төрле үләннәр белән дәвалаганнар, Көнчыгышның атаклы галиме Әбугалисинаның медицина буенча язган китапларын өйрәнгәннәр. Болгар табиблары Таҗетдин һәм Хәсән бине Юныс әл-Болгарилар һ.б.ның фәнни хезмәтләре чит җирләрдә дә (мәсәлән, Көнчыгышта) популяр булган [Давлетшин, с. 131–132]. Бүгенге көндә төрле чорларда, төрле авторлар тарафыннан язылган дистәләрчә кулъязма тыйбб китаплары булуы билгеле [Мөсәгыйдь].

Медицина буенча алган белемнәрен М. Бәхтияри Яңа Смәилдә төпләнгәннән соң файдалана. Зыя мулла (авылдашлары аны шулай йөрткәннәр) авыл халкын озак еллар дәвамында үләннәр белән дәвалый. Башка күп кенә «барысы да Ходай кулында» дип фикер йөрткән муллалардан аермалы буларак, ул дини белемнәр белән фәнни (рәсми медицинага караган) белемнәрне бергә бәйләп, авыруларга тиешле ярдәмне күрсәтә алган. Казан шәһәренең атаклы яһүд, рус аптекарьлары белән дус булуы, хезмәттәшлек итүе дә (ул еш кына Казаннан дарулар кайтарткан) эшен нәтиҗәле башкарырга мөмкинлек биргән [Мортазина, б. 37].

Истәлекләрдән күренгәнчә, Зыя хәзрәтнең авыруларны дәвалауга багышланган махсус китабы да булган. Шулай ук үз тәҗрибәсенә нигезләнеп төзегән кулъязмалары да булуы ихтимал. Ләкин, кызганыч, әлегә алар табылмады.

Яңа Смәилдә муллалык итү чорында Мөхәммәтзыя Бәхтияри тагын берничә кулъязма китап язган. Шуларның берсе – кулыбызга килеп ирешкән әлифба кулланмасы. Ул аны 1968 елда Яңа Смәил мәктәбенең физкультура укытучысы, комсомол секретаре, университетның татар бүлегенә укырга керергә әзерләнүче Эдуард Исламовны (1942 елда туган) гарәп хәрефләре белән укыргаязарга өйрәтү өчен төзегән була. Универстет укытучысы Мостафа Ногман аңа алдан ук гарәп әлифбасын үзләштерергә киңәш итә.

Әлифбада гарәп хәрефләренең төрлечә язылышы тәкъдим ителә, аерым сүзләр, җөмләләр, кыска текстлар, Г. Тукай шигырьләреннән өзекләр бирелә. Ул, мөкәммәл уку әсбабы булудан бигрәк, беренче чиратта адреслы, ягъни шәхси, аерым шәхескә атап язылуы ягыннан игътибарга лаек. Бүгенге көндә бу әлифба Киров өлкәсендә танылган журналист, берничә китап авторы Э. Исламовта саклана.

Мөхәммәтзыя Бәхтияри, шул заман мәгърифәтчеләренә хас булганча, дин һәм фәннең төрле өлкәләре белән кызыксынган. 1961 елда ул «Смәил тарихы» дигән кулъязма китабын төгәлли [Бәхтияри]. Бәхетебезгә, әлеге кулъязма белән танышу, аны өйрәнү, хәзерге татар графикасына күчерү мөмкинлеге туды. Ул бүгенге көндә М.Бәхтияринең оныгы, Казан шәһәрендә яшәүче Римма Карапаевада саклана.

«Смәил тарихы» китабын шартлы рәвештә ике бүлеккә бүлеп карарга мөмкин. Аның беренче өлешендә автор намаз вакытын дөрес билгеләү өчен җәдвәл (таблица), ягъни календарь төзеп урнаштыра. Үзенең әйтүенчә, ул әлеге мәгълүматны әзерләгәндә Ш. Шәһидуллинның 1912–1915 елларда дөнья күргән «Заман календаре»ннан файдалана. Әлеге җәдвәлне әзерләгәндә «бу (ягъни 1961) елда, февральнең 28 көннән килүенә игътибар ителде» дигән искәрмә урнаштыра.

Китапның икенче бүлеген тарихи өлеш дип атап, аны үз эчендә өч кисәккә – гомумән татар халкы тарихына, Яңа Смәил авылы тарихы һәм авторның үзенең гаилә тарихына аерып карарга мөмкин.

Мөхәммәтзыя Бәхтияринең тарих белән кызыксынуы, китабында тарихи сәхифәләрне яктыртырга омтылуы, мөгаен, аның XIX–XX гасырлар чигендә дөнья күргән татар календарьларына ияргә тырышуыннандыр. Чөнки, билгеле булганча, ул заманның күп кенә календарьларында татар халкы тарихына караган аерым вакыйгаларны һәм шәхесләрне сурәтләгән материаллар урнаштырыла. Татар календарьлары белән яхшы таныш булган М. Бәхтияров Казан шәһәре тарихы, шәһәрне Явыз Иван яулап алган заманнар, аннан соңгы авыр еллар, афәтләр (янгыннар, корылык, ачлыктан күпләп халык корылу, мәсәлән, 1782 елның 19 декабрендә Казанда көчле яңгырдан соң, су басып, 200 дән артык кеше агып китү вакыйгасы һ.б.) турында да тәфсилле генә сөйләп, шактый бай мәгълүмат бирә. Моңа охшаш материаллар К. Насыйри календарьларында да байтак. Әйтик, мәгърифәтченең 1881 ел өчен әзерләгән календарендә Казан шәһәре өчен барган аяусыз көрәш, мөселманнарның соңгы көчләрен куеп явыз дошманга каршы торулары, кычкырып намаз укыганнан соң, киемнәрен салып, рус гаскәрләренә таба ыргытулары, шуннан көчле җил чыгып, басып алучыларның Иделгә төшеп һәлак булулары һ.б. сурәтләнә [Насыйри, б. 34]. Моннан тыш, М. Бәхтияров үз басмаларында аерым шәхесләр, мәсәлән, атаклы татар шагыйре, акыл иясе

Г. Утыз Имәни һәм аның эшчәнлеге, хезмәтләре турында материаллар, шагыйрь Г. Тукайның шигырьләрен дә бирә. Күп кенә тарихи вакыйгаларның шактый җентекле һәм тулы сурәтләнүе М.Бәхтияровның бу өлкәдә мәгълүматлы булуын дәлилли.

М. Бәхтияринең Яңа Смәилнең барлыкка килүе, аңа нигез салучылар, авылдагы мәчет-мәдрәсә тарихы, муллалар һәм мөәзиннәр турындагы язмалары да шактый кызыклы, алар авыл тарихын өйрәнүчеләргә кыйммәтле чыганак була ала. Мәчет-мәдрәсә тарихын яктыртуга караган уникаль материаллар – мөәзиннәр исемлеге, «мәчеткә йөрүче гарәп язуын белүчеләр» (ягъни төрле елларда үзендә белем алган шәкертләр) исемлеге, XX гасыр башында авылда булган вакыйгалар (мәктәпне ябу, халыкның ризасызлык күрсәтүе, шул сәбәпле кулга алынучылар исемлеге һ.б.) игътибарны аеруча җәлеп итә. Бүгенге заман тарих фәнендә иң актуаль юнәлешләрнең берсе саналган авыллар тарихы, аерым алганда, Яңа Смәил авылы тарихын тулыландыруда мәгълүмати яктан бай һәм кызыклы ярдәмче ролен үти ала. Бу китап шулай ук Бәхтияр әл-Мәмдәли һәм Мөхәммәтзыя Бәхтияриләрнең тормышын (чыгышлары, нәсел тарихы һ.б.) һәм педагогик эшчәнлекләрен ачыклауда бай чыганак булып тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар мәдрәсәләрендә белем алган шәкертләр арасында шактый бай педагогик мирас калдырган шәхесләр байтак. Бик күпләренең китап-дәреслекләре әлегәчә фәнни әйләнешкә кертелмәгән. Югалган, юкка чыккан хезмәтләр белән беррәттән, аерым кешеләр кулында истәлек буларак сакланган кулъязмалар да шактый. Аларны туплап, өйрәнеп, заман укучысына тәкъдим итү – бүгенге көндә татар фәненең иң төп бурычларының берсе булып тора. Мөхәммәтзыя Бәхтияровның алда искә алынган китап һәм дәреслекләре тарихтагы әлеге ак тапларны бетерүдә бер адым дип санарга мөмкин.

**Әдәбият**

Балтач энциклопедиясе. 2 т. Казан: 2010. 530 б.

*Бәхтияр әл-Мәмдәли.* Рисаләи тәүхид. Казан: 1904. 8 б.

*Бәхтияр М.* Каванин әл-хисаб. Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1898. 88 б.

*Бәхтияр М.* Каванин әл-хисаб. Рисаләи зыяия. Түнтәр авылы. 1897. Автограф. 34 кгз. 1502 т. (э. № 5393)

*Бәхтияр М.* Горрәи даими. Казань: Тип. Лит. и Словолитня Т.Д. БР. Каримовых, 1903. 23 б.

*Бәхтияри М.* Смәил тарихы. Кулъязма китап. Яңа Смәил, 1961.

*Беркутов В.М.* Развитие математического образования булгаро-татар. Казань: 1997. 193 с.

*Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура (Домонгольский период, X – нач. XIII в.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 190 с.

*Зайни Р.* Татарские печатные календари: становление и развитие. Казань: КГУ, 2005. 153 с.

*Зарипов Р.Ш.* Гали ишан, Ишми ишан һәм Түнтәр мәдрәсәсе. Казан: Иман, 2002 / 1423. 32 б.

Зыя Бәхтияров истәлеге (Истәлекне язып алучы: М. Гали) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 145.

Киров өлкәсе дәүләт архивы. 583 ф. 604 тасв. 149 эш.

Кульязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш: Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. Өченче бүлек / төз. А. Фәтхи. Казан: 1968. 83 б.

*Мәрҗани Ш.* Мостәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

*Миңнуллина Л.З.* Татарские печатные календари XIX – начала XX в. как памятник культуры. Автореф. дис. ... канд. ист. наук. Казань: 2006. 28 с.

*Мортазина Л.Р.* Татар авыллары мәгарифе: Бәхтияр әл-Мәмдәли һәм Бәхтияровлар нәселе. Казан: ТФАнең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2016. 92 б.

*Мөсәгыйдь бине Мостафа Йортыши.* Тыйбб китабы // Мирас. 1992. № 6, 7, 9–12; 1993. № 2–3.

*Насыйри К.* Календарь. 1881 елга. Б. 34.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: ТЭИ, 2002. 830 б.

Татарстан Республикасы Милли архивы. 204 ф. 177 тасв. 157 а эш.

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
*lyalyamur@mail.ru*

УДК 372.8

***Н.К. Туктамышов***

# БИЛИНГВАЛЬ УКУ ШАРТЛАРЫНДА СТУДЕНТЛАРДА МАТЕМАТИКА ӨЛКӘСЕНӘ КАРАГАН СӨЙЛӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕНЕҢ ФОРМАЛАШУЫ

Языковая среда в Республике Татарстан является двуязычной. Ведущей функцией речи является коммуникативная функция. В работе выделены базовые составляющие коммуникативных качеств математической речи: правильность (лингвистическая составляющая), точность, логичность. Цель работы состоит в том, чтобы выяснить уровень сформированности базовых коммуникативных качеств математической речи студентов в условиях билингвального обучения. Проведенные эксперименты позволяют предположить, что изменение языка обучения математике приводит к ухудшению базовых коммуникативных качеств математической речи у большинства студентов.

**Ключевые слова:** математическая речь, математика, правильность математической речи, логичность, точность речи, билингвальное обучение.

Татарстан Республикасында белем алучы яшьләрнең 82% ка якыны татар һәм рус телен белүне зарури дип тапты (2012 елда оештырылган сорау-җаваплар нәтиҗәсе буенча). 2012 елда үткәрелгән тикшеренүләрдән мәгълүм булганча, татар яшьләренең 38,5% ы һәм рус яшьләренең 0,2% ы өйдә татар телендә сөйләшә, ә 2001 елда бу күрсәткеч 36,1% һәм 0,6% ка туры килә иде. Бүгенге көндә татарларның 37,5% ы һәм русларның 1,4% ы ике телдә дә (рус һәм татар) сөйләшә (2001 елда бу күрсәткеч 37,1% һәм 1,2% ка туры килә).

Татарстанда парадоксаль ситуация туды. Бер яктан, математиканы мәктәптә татар телендә өйрәнгән укучылар Бердәм дәүләт имтиханнарын рус телендә бирергә мәҗбүри (аның нәтиҗәләре буенча югары уку йортларына кабул итәләр), икенче яктан, аларның шактый өлеше, югары уку йортына кергәч, татар телендә белем алырга тели. Рус мәктәпләрен тәмамлаган укучылар арасында да югары уку йортында татар телендә белем алырга теләүчеләр бар. Тик бер үк студентлар төркемендә татар телен белү дәрәҗәсе төрлечә була. Нәтиҗәдә, кайбер студентлар, еш кына татар сүзләренең мәгънәсен төгәл белми, бирелешнең татарча да, русча да мәгънәнәсенә төшенми, татар телендәге математик фразаларны аңламый, математик терминологияне начар белә. Шулай итеп, укытучы алдында татар һәм рус телләрендә укыту стратегиясен сайлау проблемасы туа.

Бу тикшеренүнең теоретик нигезен Б.В. Гнеденко (2006), А.Я. Хинчин (2006), А.А. Столяр (1969) хезмәтләре тәшкил итә. Алар математика укыту процессында фикерләү культурасының формалашуын тел үсеше белән

тыгыз бәйләнештә өйрәнгәннәр. Без дә, шулай ук, математиканы укытканда тел факторының тәэсирен тикшергән чит ил галимнәренең эшләренә таяндык [Ellerton, Clarkson, 1996; Austin, Howson, 1979]. R. Barwell, J. Moschkovich, S. Staats (2008) эшләрендә «академик тел» төшенчәсе математикада тикшерелә һәм төгәлләнә, шулай ук алар тарафыннан «гибрид тел» дә өйрәнелә. Бу телдә профессиональ математиклар киң массаларга математик идеяләрен җиткерергә тырышалар. Кьюминсның «Бусагалар теориясе» буенча икетеллелекнең интеллектуаль яктан уңай тәэсир итүе өчен индивидның билингваль компетенциясе формалашырга тиеш [Cummins, 1991, p. 70–89; 2000, p. 235–240]. Cummins [Cummins, 2000] икенче телдә ике дәрәҗәне аерып алырга тәкъдим итә: көндәлек тормыш телендә сөйләшә белү (BICS) һәм аннан югарырак, ягъни белем алу процессында икенче тел белән файдалану (CALP). Без, шулай ук, галимнәр төркеме [National Council of Teachers of Mathematics, 1989], тәкъдим иткән модельгә таянабыз. Ул модель буенча укучының математик телен көндәлек тормыш теленнән «математик яктан күбрәк структураланган» тел аша, академик математик телгә кадәр үстерергә тәкъдим итәбез. Ләкин алдагы тикшеренүләрнең бер катлаулылыгы бар: ул да булса, «математик яктан күбрәк структураланган» телнең билгеләмәсе китерелмәгән һәм андый телнең формалашу критерийлары һәм күрсәткечләре эшләнмәгән [Salekhova, Tuktamyshov, p. 136–141].

Телнең, нигездә, сөйләмдә генә кулланылуын истә тотып, укучыларга тәкъдим ителә торган «математик яктан күбрәк структураланган» телнең төп характеристикалары түбәндәгеләр: төзеклек, төгәллек, логикага нигезләнү. Бу – математик телнең минималь коммуникатив төркеме, аның буенча «математик яктан күбрәк структураланган» телнең дәрәҗәсе формалашу турында фикер йөртеп була [Шармин Д.В., 2005, б. 207]. Телнең төп хәрәкәтләндерүче функциясе – коммуникатив функция, ә аның нигезендә төзеклек сыйфаты ята. Математик тел белән сөйләгәндә, язганда математик терминнар, символларның математика теленә хас булган билгеләр белән дөрес итеп файдаланылуын төзеклек дип исәплэрбез. Шул ук вакытта татар теленең әдәби нормаларын саклауны, дөрес итеп график сызуны, дөрес итеп рәсемнәрне һәм сызымнарны укый белүне дә истә тотарга кирәк.

Төгәллек оптималь рәвештә фикерләү эчтәлеген чагылдыра, аның төп идеясен ача һәм ул фикерне ачык, конкрет һәм шул ук вакытта язма һәм сөйләм телен тулы итеп бирүдә чагыла. Шулай ук төгәллек текстта язулар, сызымнар, рәсемнәрнең пөхтә һәм рациональ эшләнүе белән , график сурәтләренең торышы белән аерылып тора.

Логикага нигезләнү язма һәм сөйләм теленең җөмләдә логик структурасын ачык аңлаешлы итеп бирүдә күренә, математик

фикерләүдә, фикерләр арасында бәйләнеш урнаштыруда һәм ул материалны каршылыксыз һәм эзлекле фикер йөртү, текстларны мәгънәви структурага туры китереп төзи белүдә күренә.

Математик телнең алда әйтелгән төп характеристикаларын киңәйтеп була, ләкин без әйтелгән өч төп характеристика (төзеклек, төгәллек, логикага нигезләнү) белән чикләнәбез.

Бу фәнни-тикшеренү эшенең эмпирик нәтиҗәләре Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында алынды. Экспериментта төзелеш факультетының 18 студенты катнашты, эмпирик материалларны эшкәрткәндә интерпретацион ысул файдаланылды.

Математик мәсьәләләрне чишкәндә студентларның татар телендә фикерләү дәрәҗәләре тикшерелде. Нәтиҗәдә, «татар телендә уйлыйбыз» дип 12 студент җавап бирде, 4 студент рус телендә уйлауларын; 2 студент татарча да русча да җиңел фикер йөртүләрен әйттеләр. Студентлар төркеме өч яңа төркемгә бүленде. Төркемнәргә аерганда бүлү критерие итеп тел белү дәрәҗәсе алынды. Беренче «Т» төркеменә татар мәктәпләрен яки татар гимназияләрен тәмамлаган студентлар кертелде, алар 11 ел монолингваль рәвештә татар телендә белем алган. Икенче «Б» төркеменә унынчы сыйныфка кадәр татар телендә белем алган студентлар керде. Алар 10 һәм 11 сыйныфларда рус телендә укуга күчкән. Башлангыч мәктәптә генә татар телендә укыган студентлар өченче «Р» төркеменә кертелде. Әлбәттә, куелган сораулар күзлегеннән карасак, «Р» һәм «Б» төркемнәре иң зур фәнни кызыксыну уята.

Тикшеренү предметы булып бу очракта студентларның язма эшләре, телдән җаваплары, репликалары хезмәт итте. Биредә P(n) – «Р» төркеменнән n номерлы студент, Т(n) – «Т» төркеменнән алынган n номерлы студент, Б(n) – «Б» төркеменнән алынган n номерлы студент.

Алда әйтелгәнчә, телнең сыйфат ягыннан характеристикаларын өйрәнү – катлаулы мәсьәлә, чөнки алар, гадәттә, һәр бирелештә бер-берсе белән бәйләнештә тора, шуңа күрә һәр аерым биремдә теге яки бу сыйфатның башка сыйфатлардан өстен булуы таләп ителде. Тикшеренү максатыннан чыгып, өч дәрәҗәле бәяләү шкаласын сайлап алдык («югары» – ю, «уртача» – у, «түбән» – т).

Студентларның математик телендәге төгәллекне тикшерү өчен параллелограмм, квадрат, ноктадагы чыгарылма билгеләмәләрен бирергә, шулай ук һәр адымны дәлилләп, язма формада геометрик мәсьәләне татар телендә чишәргә тәкъдим ителде. «Р» төркемендә 3 очракта параллелограмм билгеләмәсе рус телендә генә бирелде, фәкать бер сынауда гына билгеләмәне татар телендә бирү омтылышы булды, ләкин ул ялгыш булып чыкты.

«Б» төркеме студентлары барлык сорауларга татар телендә җавап бирделәр, Б (1) студенты параллелограмм билгеләмәсен рус телендә дә китерде. Нәтиҗәләр 1 нче таблицада бирелә.

Студентларның сөйләшүендә логик нигезләрне ачып бирү өчен аларга математик-логик конструкцияләр белән эш итә алуны таләп итүче биремнәр тәкъдим ителде. Студентларга билгеле булган билгеләмәләр, теоремалар бирелде. Аларның бу биремнәрдән гади искәрмәләр чыгара алуы тикшерелде. Укучыларга скаляр һәм вектор тапкырчыгышының билгеләмәләрен бирергә һәм шуннан гади искәрмәләрне чыгарырга тәкъдим ителде. Студентларның математик теленең логик нигезләрен тәшкил итүче нәтиҗәләр 3 нче таблицада күрсәтелгән.

«Б» һәм «Р» төркемнәрендәге студентларның фикерне логик яктан дөрес итеп бирә белү дәрәҗәсен ачыклау аерым кызыксыну уята. Моны ачыклау өчен аларга мәктәп курсыннан гади планиметрик мәсьәлә бирелде: тигезьянлы өчпочмакта түбәдәге почмак һәм мәйдан бирелгән. Өчпочмак нигезенең озынлыгын табарга.

Р (1) студенты мәсьәләне чишә алмаган, ул хәтта мәйданны исәпли торган формуланы да китерә алмаган. Бу – студентның, гомумән, телдән һәм математикадан белем дәрәҗәсе түбән булуын күрсәтә. Р (2) эзлекле рәвештә

1 нче таблица

| № | Бирем | Башкару нәтиҗәләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Б (1) | Б (2) | Р (1) | Р (2) | Р (3) | Р (4) |
| 1 | Параллелограмм билгеләмәсен бирергә | у | т | т | т | ю | у |
| 2 | Квадрат билгеләмәсен бирергә | у | у | т | т | у | ю |
| 3 | Чыгаралма билгеләмәсен бирергә | т | у | т | т | т | у |
| 4 | Геометрик мәсьәләне чишәргә | ю | у | у | т | у | у |

2 нче таблица

**Студентларның математик теле төгәллеген табу нәтиҗәсе**

| Дәрәҗә | Б төркеме | Р төркеме | Т төркеме |
|---|---|---|---|
| ю | 12,5%, | 12,5%, | 41,7%, |
| у | 62,5%, | 37,5%, | 35,4%, |
| т | 25% | 50%. | 22,9%. |

3 нче таблица

**Студентларның математик телләренең логик нигезләре**

| Дәрәҗә | Б төркеме | Р төркеме | Т төркеме |
|---|---|---|---|
| ю | 0% | 0% | 50% |
| у | 100% | 40% | 33% |
| т | 0% | 60% | 17% |

материалның язылышында авырсына, үзенең эшен сүзләр белән файдаланып дәлилләмәгән, чишелеш өчен мөһим булмаган исәпләүләрне китермәгән, рәсемнәрне бик вак һәм аңлаешсыз ясаган. Мәсьәлә чишелмәгән. Р (3) студенты аңлаешлы рәсем китергән, фикер йөртү эзлекле, ләкин мәсьәлә ахырына кадәр чишелмәгән. Р (4) студенты мәсьәлә чишелешен ахырына кадәр җиткерә алмаган һәм аның логика белән проблемалары бар. Мәсьәлә чишү процессында, ул һәрвакыт яңа аргументларны вак почерк белән өстәп, алдагы фикерләргә әйләнеп кайта, ягъни студент һәр этапта мәсьәләне тирән итеп фикерли алмый, аның чишелеш юлын эзлекле рәвештә күз алдына китерә алмый. Р (1), Р (2) төркем студентлары логик яктан түбән нәтиҗә күрсәттеләр, Р (3), Р (4) төркемнәр – уртача нәтиҗә, ягъни логик яктан рус телендә сөйләшүче студентларның эшләре татар телендә сөйләшүчеләрнекенә караганда яхшырак. «Б» төркеменә игътибар итсәк, Б (1) студенты мәсьәләне оптималь юл белән эшләми, үзенең фикерләрен язып бирә белми. Б (2) студенты формулалар чылбырын дөрес итеп төзи, тик дәлилләвен ахырда гына китерә. Шулай да Б (1) студентының логик фикерләү дәрәҗәсе уртача, ә Б (2) студентының – югары дәрәҗәдә. Гомумән алганда, «Б» төркемендә логика нигезләрен «Р» төркеменә караганда яхшырак беләләр. Шулай итеп, татар телендә белем алган студентларның логик фикерләү дәрәҗәсе югарырак дип әйтә алабыз.

Төзек математик телнең лингвистик өлешен тикшергәндә, студентларга татар һәм рус телләрендә терминологик диктант тәкъдим ителде. Бу диктантның максаты – терминнарны икенче телгә күчерү (диктант рус телендә булса, шул ук терминны татар теленә тәрҗемә итәргә кирәк һәм киресенчә). Рус телендә 8 термин әйтеп яздырылды, татар телендә – 6 термин. Студентлар бу терминнарны язып алып, алар ярдәмендә математик төшенчәләрне татар телендә язарга тиеш иде. Укучыларның математик телләренең дөрес булуы аларның язма эшләрен караганда да тикшерелде. Студентларның математик теленең лингвистик яктан дөрес булу дәрәҗәсе 4 нче таблицада китерелгән.

Димәк, «Р» төркеме студентлары математик терминологияне татар телендә начар беләләр. «Т» төркеме студентларының эш нәтиҗәләре математик телдәге лингвистик өлешләрнең төрле булуын ачыклады. Шулай да, «Т» төркемендә татар телен түбән дәрәҗәдә белүчеләр саны «Р» төркеменнән 3,2 мәртәбәгә кимрәк.

Математик телнең логик нигезләрен анализлау «Р» төркеме студентларының 25%ының логик фикерләү дәрәҗәсе уртача, ә 75% ының логик фикерләү дәрәҗәсе түбән булуны күрсәтте. «Б» төркемендә барлык студентлар (100%) уртача дәрәҗәдә эш итәләр булып чыкты. Ниһаять, «Т» төркеме студентларының 56% ы югары дәрәҗәне, 33% ы – уртача, 17% ы – түбән дәрәҗәне күрсәтте.

4 нче таблица

**Студентларның математик теленең дөреслеге нәтиҗәләре**

| Дәрәҗә | Б төркеме | Р төркеме | Т төркеме |
|---|---|---|---|
| ю | 50% | 0% | 41,1% |
| у | 50% | 20% | 33,9% |
| т | 0% | 80% | 25% |

Математик телне белү сыйфатларының кумулятив эффектын ачыклау өчен математик телнең сыйфатлар ягыннан формалашуын ранглы шкала белән билгелибез («югары» – 3 балл, «уртача» – 2 балл, «түбән» – 1 балл). Математик көтелешне исәпләгәндә һәр төркемдә үткәрелгән экспериментларның нәтиҗәләре аерым күрсәтелә (2–4 нче таблицалар). Математик көтелешнең кыйммәтләре түбәндәгечә: М(Т)=0,74, М(Б)=0,71, М(Р)=0,45.

Татар һәм билингваль төркемнәрдә математик көтелешләр бер-берсенә якын, шуңа күрә билингваль студентлар өчен укыту теле алмашыну математик телнең төп коммуникатив сыйфатларына нык тәэсир итмәде дип фараз кыла алабыз.

Бу хезмәттә «югарырак математик структураланган телнең» төп коммуникатив характеристикаларын белү өчен, әйтеп үтелгәнчә, дөреслек, төгәллек һәм логикага нигезләнү кебек критерийлар тәкъдим ителә. Бу коммуникатив сыйфатларның минималь төркеме, аның буенча студентларның математик телләренең формалашуын бәяләп була. Тикшеренүләр укыту теленең алмашынуы әйтелгән коммуникатив сыйфатларның начарлануына китерә дип фаразларга җирлек тудыра. Шулай итеп, рус төркемендә укыган студент-билингвларның (алар башлангыч мәктәптә математиканы татар телендә укыганнар) калган ике төркем студентларыннан («Б», «Т» төркемнәре) әйтеп киткән төп коммуникатив сыйфатлар формалашу ягыннан артта калуы ачыкланды.

Хәзерге көндә мәкаләдә китерелгән фаразларны тикшерү дәвам итә.

**Әдәбият**

*Гнеденко Б.В.* О математике. М.: УРСС. 2002. 203 с.

*Икрамов Дж.* Математическая культура школьника. Ташкент. Укитувчи. 1981. 278 с.

*Столяр А.А.* Педагогика математики. Минск: Вышейшая школа. 1969. 363 с.

*Хинчин А.Я.* Педагогические статьи. М.: КомКнига. 2006. 208 с.

*Шармин Д.В.* Формирование культуры математической учащихся в процессе обучения алгебре и началам анализа: дис. … канд. пед. наук. 2005. 207 с.

*Austin J. and Howson A.* Language and mathematical education // Educational Studies in Mathematics. 1979. № 10. P. 161–197.

*Barwell R, Moschkovich J., Staats S.* Teaching and learning mathematics in multilingual classrooms // Proceedings of the 32st Conference of the International Group for the Psychology of Mathematics Education, July 17–21 2008. Morelia, Mexico. Vol. 1. P. 202.

*Barwell R.* Hybrid discourse in mathematicians' talk: the case of the hyper bagel // Proceedings of the 32st Conference of the International Group for the Psychology of Mathematics Education, July 17–21 2008. Morelia, Mexico. Vol. 2. P. 129–136.

*Clarkson P.C.* Language and mathematics. A comparison of bilingual and monolingual students of mathematics // Educational Studies in Mathematics. 1992. № 23(4). P. 417–429.

*Clarkson P.C. and Dawe L.* NESB migrant students studying Mathematics: Vietnamese students in Melbourne and Sydney // Proceedings of the 21st Conference of the International Group for the Psychology of Mathematics Education July 14–19, 1992. Lanti, Finland, 1992. Vol. 2. P. 153–160.

*Clarkson P.C.* Mathematics Teaching in Australian Multilingual Classrooms: Developing an Approach to the Use of Classroom Languages // Multilingualism in mathematics classrooms. Bilingual education and bilingualism / Series Editors: Nancy H. Homberger and Colin Baker. Edited by Richard Barwell. 2009. P. 145–160.

*Cummins J.* Interdependence of first – and second-language proficiency in bilingual children. // In E. Bialystok (ed.) Language Processing in Bilingual Children. Cambridge: Cambridge University Press, 1991. P. 70–89.

*Cummins J.* Language. Power and Pedagogy: Bilingual Children in the Crossfire. Clevedon, England: Multilingual Matters. 2000. P. 386.

*Ellerton N. and Clarkson P.C.* Language factors in mathematics teaching and learning // International Hahdbook of Mathematics Education / A. Bishop, K. Clements, C. Keitel, Kilpatrick and C. Laborde (eds). Dordrect: Kluwer Academic Publishers, 1996. P. 991–1038.

*Moschkovich J.* A situated and sociocultural perspective on bilingual mathematics learners // Mathematical Thinking and Learning. 2002. № 4 (2–3). P. 189–212.

National Council of Teachers of Mathematics (NCTM). Curriculum and Education Standards. Reston, VA, 1989: NCTM.

*Pimm D.* Speaking Mathematically: Communication in Mathematics Classrooms. London. 1987. Routledge. 456 p.

*Salekhova L.L., Tuktamyshov N.K.* Bilingual mathematics teaching in conditions of higher educational establishment // Proceedings of the ICMI study 21 conference: mathematics education and language diversity, 16–20 September. 2011. Aguas de Lindoia, Sao Paolo state, Brazil. 2011. P. 136–141.

*Secada W.C.* Race, ethnicity, social class, language and achievement in mathematics // Handbook of Research on Mathematics Teaching and Learning / D.A. Grows (ed.). New York: MacMillan. 1992. P. 623–661.

*Setati M.* Researching mathematics education and language in multilingual South Africa // The Mathematics Educator. 2002. № 12 (2). P. 6–20.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Туктамышов Наил Кадыйр улы,***
*педагогика фәннәре докторы, профессор,*
*Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының*
*югары математика кафедрасы мөдире*

УДК 745

*Л.М. Шкляева*

# ЗЕМФИРА БИКТАШЕВАНЫҢ РУХИ МОҢЫ

Статья посвящена творчеству мастера татарской вышивки З.Н. Бикташевой. Работы художника воспроизводят самобытные орнаментальные мотивы и традиционные техники, олицетворяют национальную культуру, воплотившуюся в определенных композиционных приемах, ярком полихромном решении и плоскостной манере исполнения.

**Ключевые слова:** З. Бикташева, вышивка, декоративно-прикладное искусство, художественный прием.

Хәзерге вакытта татар чигү сәнгате ике юнәлештә үсүен дәвам итә. Аның берсе, хатын-кызлар шөгыле буларак, халыкта буыннан буынга күчеп килгән һәм вакыт тарафыннан сайланып калган эстетик нормаларны чагылдыра. Икенчесе – һөнәри сәнгатькә нигезләнгән, һәм практик-рәссамнар иҗатын колачлый. Алар арасында Казан остасы Земфира Нәкый кызы Бикташева (1955 елда туган) эшләре аерылып тора.

З.Н. Бикташева күренекле татар рәссамы, СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, портретчы Нәкый Бикташев гаиләсендә туган. Ул иҗади атмосферада үсә һәм татар мәдәниятенең асыл үрнәкләре белән кечкенәдән үк таныш була. Алты яшендә Земфира П.Т. Сперанскийның «Татарский народный орнамент» альбомы белән таныша, андагы бизәкләргә кыз хәйран кала һәм шундый ук чәчәкләр, яфраклар һәм чәчәк бәйләмнәре ясарга өйрәнүне төп максатына әйләндерә. Шуннан башлап ул хатын-кыз кул эшләренең төрләре белән кызыксына һәм анда татар осталары тарафыннан чигеп эшләнгән традицион сюжетларны гәүдәләндерү омтылышы уяна. Ә ун елдан инде уналты яшьлек Земфира үзенең «Татар чәчәге» дигән беренче декоратив панносын тәмамлый, анда ул аппликацияләр, тамбурлы җөй һәм элмәкләп чигү техникасы кебек җентекләп эшләүне таләп итә торган алымнар куллана.

1974 елда З. Бикташева, Казандагы сәнгать көллиятен тәмамлап, әтисенең остаханәсендә эшли башлый, һәм 1984 елга кадәр әтисе кул астында үзе сайлаган һөнәрнең бөтен нечкәлекләрен өйрәнә. Милли тематиканы чагылдырган натюрмортлар иҗат итә. Аның тукымаларында татар түбәтәйләре, башмаклары, чүлмәкләре, тукылган һәм чигелгән әйберләр сурәтләнә. З.Н. Бикташеваның әсәрләре республикада, регионнарда һәм Россиякүләм оештырылган күргәзмәләрдә урын ала. Яр Чаллы шәһәрендә (1995, 1998, 2000 елларда) шәхси күргәзмәсе уздырылды.

1996 елда З.Н. Бикташева Татарстан Республикасы Рәссамнар берлегенә кабул ителә, ә 1999

һәм 2011 елларда халык традицияләрен саклау өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Рәссам, сынлы сәнгать остасы З.Н. Бикташева һөнәри күнекмәләргә ия булган хәлдә татар халык сәнгатенең яңа баскычларына мөрәҗәгать итә, татар чигү ысуллары – тамбурлы җөй, аутентик элмәк техникасын һ.б.ның стиль үзенчәлекләрен һәм төрләрен тирәнтен үзләштерүгә алына.

Рәссам декоратив паннолары белән үзебезнең илдә оештырылган халыкара (Казан, Мәскәү, Түбән Новгород) һәм чит ил (Төркия) күргәзмәләрендә катнаша. 2002 елда ул «Россия Рәссамнар берлеге»нең Татарстан Республикасындагы Бөтенроссия иҗади иҗтимагый оешмасына да, ЮНЕСКОның Халыкара сынлы сәнгать ассоциациясенә дә әгъза булып кабул ителә. 2005 ел З.Н. Бикташева өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстаным минем. Минем Дөньям» конкурсында Бакый Урманче исемендәге премиягә лаек булуы белән истәлекле. 2006 елда рәссам Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев турындагы «Йөрәгең алтын синең» китабының тышлыгы күренешен ясады һәм 2010 елда Франциядә уздырылган Россия мәдәнияте көннәрендә катнашты (аның «Россия чәчәкләре» әсәре Каннаның Россия мәдәнияте павильонына куелды). 2017 елда З.Н. Бикташева Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесенә лаек булды. Бүген З.Н. Бикташева милли декоратив иҗатны дәвам итеп үстерүчеләрнең берсе, ә алар күп түгел.

Рәссамның әсәрләрен сүзе-моңы тәңгәлләшкән һәм үзенчә башкару манерасына ия халык җыры белән чагыштырырга була. Аның панноларыннан, автор рухын чагылдырып, татарның милли аһәңе бөркелә, ул онытылмас кыйммәтләр, капма-каршылык бердәмлеге башлангычы, яшәешнең вакытлы һәм цикллы булуы хакында сөйли. Әйтик, авторның «Болгар чәчәге» әсәрендә Идел буе бакчаларында лепердәгән язгы ак таҗ яфракчыклары, көзге имәннәрнең алтын яфралары һәм җәйге болын чәчәкләре образлары гәүдәләнгән. Гаҗәеп гүзәл мизгелләр тупланган. Әлбәттә, боларны көндәлек тормышта очрата алмыйсың, ә менә рәссам дөньяны ул ничек яратылган, шул яссылыкта күрә. Автор бу дөньяда үзенең дә барлыгын белдереп, алма-чияләрнең ак яки нәфис ал чәчәкләргә төренгән ботакларын да кушып җибәрә, чөнки ул үзе май аенда туган. Шулай итеп, З.Н. Бикташева һәр эшенә үз «имзасын» сала. Рәссам иҗатында үсемлек, чәчәк һәм кош образлары флора һәм фауна күренешләре буларак кына түгел, ә төрки дөньяда гомум кабул ителгән символик мәгънәләргә бәйләп тә гәүдәләндерелә. Имәннең яфрагы һәм чикләвеге, шулай ук үрдәк, мәсәлән, аның панноларында болгар мәдәнияте образлары буларак сурәтләнә. Борынгы

күчмә халыкларда тукранбаш дала ләләсен ассоциацияләгән, яшәештә яңаруга омтылышны раслаучы буларак кабул ителгән. Күптаҗлы чәчәк бизәкләре төрки халыкларның чиксез күгендә бердәнбер саналган Тәңре гәүдәләнеше саналган. Ә җиләк-җимешләре уңышны һәм нәселнең дәвамлылыгын символлаштырган. Шулай итеп, З.Н. Бикташеваның һәр эше күңелгә игелеклелек мәгълүматы өсти, автор моңа узган гасырлардагы осталар кулланган визуаль формалар үрнәгендә ирешә. Гомумән, З.Н. Бикташева әсәрләре беркайчан да кыш булмаган, муллык ташып торган, үзендә яшәүчеләрне җил-давыллары белән куркытмый торган тылсымлы җәннәт бакчасын хәтерләтә. Аның рәсемнәрендәге очып йөрүче таҗ яфраклары, «Яз кошы»ның («Птица-весна», 2003) җиңел каурыйлары яки су тамчылары аша йомшак җил яки җылы яңгыр күзаллана.

З.Н. Бикташеваның кайбер тукымаларында авыл идиллиясе – яшеллек белән әйләндереп алынган буаның зәңгәр өслеге, суда йөзеп йөрүче мәгърур кыяфәтле аккошлар, «Аккош күле» («Лебяжье озеро», 2013), суга баручы яшь кенә татар кызы сурәтләнә. Земфира Бикташева балачагында бу күренешләрне аз күзәтмәгән. Иҗатында да ул аларны балачакта күңеленә сеңгән хатирәләренә төреп бирә. Аның хисләре җилкәсенә чиләкләр эленгән көянтәсен куеп суга баручы кыз образына һәм нәфис башлары чәчәк аткан алмагач ботаклары белән бизәлгән кошлар кыяфәтенә дә күчкән. Сюжетта хатын-кызларның кул эшләре белән баетылган авыл мәдәнияте чагылышы тасвирланган.

Рәссамның башка әсәрләрендә сарай осталары, шәһәрдәге һөнәри үзәкләр сәнгатенең киң таралыш алган «вазадагы чәчәкләр» сюжеты йогынтысы сизелеп тора. З.Н. Бикташеваның «Казан чәчәкләре» («Цветы Казани», 2004), «Татарстан чәчәкләре» («Цветы Татарстана», 2008) һ.б. эшләрендә алтын һәм көмешне хәтерләткән металл җепләрдән тукып эшләнгән савытларның төрле формалары гәүдәләнеш алган. Элек мондый затлы чүлмәк-вазаларны дәрәҗәле затлар гына куллана торган булган. Рәссам эшләнмәләре чәчәкләр белән, элмәкләп чигү техникасын оста кулланып, нәкышьләнгән. Рәссам үз иҗатында аксөякләр өстенлек биргән төрле төс сирпеп ялтыраган асылташларны чагылдырырга омтыла. Панно үзәгендәге тыгыз бизәкләр белән фигуралап эшләнгән áрка контуры элекке югары дәрәҗәле персоналар гына ия була алган фарсы миниатюралары сыман ассоциацияләнә. Бизәкләрне болай мул төшереп эшләү мотивы атаклы төрки хакимнәр һәм аларның якыннары яшәгән корылмалар интерьерын бизәп торган данлыклы азәрбайҗан келәмнәрен тукуда кулланылган.

Рәссам тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрдән бәйрәм рухы һәм чынбарлыкта очрамый торган зиннәтлелек бөркелеп тора. Әмма табигый камиллек – аны Бар кылучы кодрәтендә генә, шуңа күрә күп кенә рәссам-

нар аңа иярүдән аңлы рәвештә баш тарталар. Фани дөньяда беркемнең дә үз әсәрләренең тулы камиллегенә омтылырга хакы юк, ул хакта хыялланырга гына мөмкин. З.Н. Бикташева, әлеге язылмаган канунга буйсынып, үз эшләренең композициясенә аны җанландырып җибәрүче «төгәлсезлекләр» өсти.

Симметриясезлек – татар сәнгатенә хас сәнгати сурәтләү үзенчәлекләренең берсе санала. З.Н. Бикташева исә аны симметриялелек белән оста итеп үрелдерә белүче рәссам. Симметриясезлек табигый тәртипне бозып гәүдәләндерә. Ул, бер яктан, гомере буе, яшәешенең әледән-әле кардиналь үзгәреп торуы сәбәпле, шуңа яраклашырга тырышучы татар халкының тарихи язмышын чагылдырса, икенче яктан, гомум үсешнең спиральсыман тотрыксызлык халәтен яктыртырга ярдәм итә. Симметрия тормыш агымын тигезләштерә, тотрыклылык һәм тынычлыкны гәүдәләндерә; аның күп тапкырлар кабатлануы исә репродуктив мәгънә өсти. Бу ике капма-каршылыкның бердәмлеге дөньяны төрки халыкларга хас дуалистик кабул итүне аңлата, һәм З.Н. Бикташева аны үзенең төп композицион принцибы итеп очраклы сайламаган.

Рәссамның композицион төзелеш элементлары, нигездә, сурәтләү манерасы киңлегендә симметрияле урнаштырыла, алар өчүлчәмле реаль күзаллауны кире кага торган үзенчәлекле төрки сәнгатьнең этик нормаларына тәңгәл килә. З.Н. Бикташева, XIX гасырда мөселман аксөякләре өчен намазлыклар чиккән осталар традициясенә ияреп, төп фон өчен караңгы төсләрне сайлый. Тукыма өслегендә ачык һәм контраст төсләр белән чигелгән сурәт контуры күзгә бәрелеп тора, рәссам, декоратив җөйләрнең контуры өчен төсләрнең төп предметныкына караганда җетерәкләрен кулланып, бизәкләрне бер-берсеннән аерып торган сызыкларның эффектын көчәйтә. Төсләргә бай палитра өстендә, нигездә, зәңгәр, яшел, ал һәм ак төсләр урын ала. З.Н. Бикташева әсәрләрендәге симметриялелек, яссылык, ачык контрастлылык күңелләргә бәйрәм тантаналылыгы рухы өсти.

Рәссамның үзенчәлекле орнаменталь мотивлар һәм традицион техника ярдәмендә иҗат ителгән һәр әсәре милли мәдәниятнең үзенчәлекле композицион алымнарын, яссылык өслегендә күптөрле ачык төсләр белән эшләү манерасын чагылдыра.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 72

*З.А. Камалова*

# ТАТАРСТАНДАГЫ ТӨЗҮ ОБЪЕКТЛАРЫНДА ТАТАР МИЛЛИ СТИЛЕН ҺӘМ КОЛОРИТЫН ТОРГЫЗУ ҺӘМ САКЛАП КАЛУ

В статье рассматриваются способы возрождения и сохранения татарского национального стиля и колорита в архитектуре Татарстана.

**Ключевые слова:** архитектура, национальный стиль, национальный колорит, Татарстан, Казань.

Заманнан, тормыштан артта калмас өчен һәр халык киләчәккә багышлаган өметләрен, максатларын, үсеш юлларын билгеләргә, аларга гомуми юнәлеш бирергә, булган мөмкинлекләрне исәпкә алырга һәм алга карап хәрәкәт итәргә тиеш.

Шуны яхшы аңлаган чын татар зыялыларының күңел түрендә туган теленең көченә һәм киләчәгенә ышаныч, аны саклау һәм үстерү , алдынгы телләр сафына кертү, татарча укыту һәм югары белем бирү, рухи, матди һәм фәнни эшчәнлек алып бару, татарларның тарихи билгеләнешен дәвам итү теләге беренче урында тора.

Татарстан – илебезнең йөзек кашына тиң республика. Татарлар җир йөзендәге бик күп милләтләрдән үзенчәлеклелеге белән, уникальлеге белән аерылып торалар: милли киемнәр, камиллеккә ирешкән бай тел, кулинария өлкәсе, мәдәният һәм башкалар. Нинди генә юнәлешне анализласак та, татарларның алдынгы позицияләрдә икәнен күрәбез.

Безнең халыкның башкаларныкына охшамаган архитектура традицияләре бар. Ул Идел буе Болгары, Казан ханлыгы һәм Алтын Урда кебек Ислам цивилизациясе яшәгән чорда ук урнашкан. Татар сәнгатенең Болгар һәм Алтын Урда сәнгатьләре белән дәвамчан бәйләнешен татар сәнгатенә нигез салучы Вәлиев Фуад Хәсән улы язган китаплар дәлилли.

Татар халкының йорты элек-электән үк аерылып торган. Челтәрләр, зәвык белән эшләнгән тәрәзә йөзлекләрен, кәрнизләрен, капкаларны, йортларны зәңгәр, яшел һәм башка төскә буялган бизәкләр аеруча ямьләп тора. Йортларны кош сурәтләре белән матурлау да татар архитектурасында гадәткә кергән. Агачны бизәкләп эшләү – татар халык иҗатының традицион һәм аеруча үзенчәлекле өлкәсе. Бик күп гасырлар буена агач өй төзү, җиһаз, савыт-саба, кирәк-ярак ясау өчен җирле чималдан файдаланганнар. Бизәкләү өчен төрле мотивлар кулланылган. Төсләр сайлауга да зур игътибар биргәннәр. Татар халкының яраткан төсләре – яшел, зәңгәр, кызыл төсләр. Заманча төзү материаллары арасында хәзер төсле материаллар бик зур урын алып торалар. Татарстан-

дагы җирле чималлардан табигый минераль пигментлар җитештереп була (акбур, чәртәп, тимер суригы, глауконитлы ком, охра һ.б.). Шулай ук төзү өлкәсендә органик пигментлар да (сары пигмент, алсу пигмент, кызыл пигмент, зәңгәрсу пигмент, ясалма сандал һ.б.) киң кулланыла. Хәзер инде төсле цемент, төсле бетон җитештерү ысуллары да бар. Әмма без, кызганычка каршы, һаман төзсез, соры бетоннан йортлар төзүне дәвам итәбез. Шулай ук бүгенге көндә заманча төзү материаллары бик зур урын алып торалар, алар арасында бизәкле калын пыяла аеруча киң кулланыла, аңа татар бизәкләре төшереп куллану мөмкинлеге дә бар. Төзелешләрдә арматуралы бизәкле пыяла, стемалит (эчке яклары керамик эмальга буялган, термоэшкәртелгән яссы пыяла) файдаланалар. Хәзер 27 төрле төстәге стемалит чыгарыла, ул биналарның диварларын тышлау өчен кулланыла. Шулай ук заманча төзү материлларыннан фибробетон, пыялафибробетон зур кызыксыну тудыралар. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгы урнашкан бинаның фасады заманча материал – пыялафибробетон белән бизәлгән. Бу эшләнмәләрнең сыйфаты һәм ныклыгы югары булу белән бергә, материалның азрак тотылуы, зәвыклы эшләнеше дә зур әһәмияткә ия, алар төзелеш чыгымнарын да киметә. Заманча материалларны төзү объектларында куллану милли татар стилендә төрле төстәге яңа биналар төзү мөмкинлекләрен ача.

Заманча төзү материалларын җитештерү, куллануга кертү белән беррәттән, аларны биналарның тышкы кыяфәтләрен зәвыклы итеп, татар милли орнаментлары белән бизәп эшли белү дә зур әһәмияткә ия. Күңелсез, соры бетон төсендәге элегрәк төзелгән йортларны милли стильгә якынлаштырып тышлау да сизелерлек нәтиҗә бирер иде.

Кызганычка каршы, кешеләр тарихны, милли традицияләрне, борынгыдан формалашып килгән, башка халыкларга охшамаган архитектураны саклап калуны үзләренең бурычларны итеп куймасалар, киләчәктә татар биналарына хас үзенчәлекләр югалырга мөмкин. Бүгенге көндә татар архитектура элементлары авылларыбызда гына кала бирә. Тарихыбызга кагылышлы бер генә бизәкне дә без югалтырга тиеш түгел. Алар безнең әбибабайларыбыздан мирас итеп калдырылган байлык бит. Әлбәттә, архитектура төрле социаль шартлар, яңа материаллар барлыкка килү, технологик процесслар үзгәрү нәтиҗәсендә яңарыш кичерә. Заман таләпләреннән чыгып, Татарстан Республикасында соңгы елларда төзелгән биналарның бизәлеше архитекторларыбызның кызыклы һәм гадәти булмаган фантазияләре белән баетыла. Шуңа күрә дә, элек эшләнгән биналарның тышкы күренешен кабатламыйча, гореф-гадәтләребез чагылышына, татар милләтенә, үзебезнең халыкка гына хас булган бизәкләрне заманча архитектурада куллану төп максат булырга тиеш.

Борынгы заманнардан ук орнамент тышкы күренешне иҗади матурлау ысулының төп чарасы

булган. Бу шулай ук архитектура корылмаларының тышкы күренешен матурлауга да кагыла. Татар орнаментының стилена Алтын Урда чорында ук нигез салынган. Аның үзенә генә хас сыйфатлары һәм бизәкләренең мотивлары элеккегечә сакланып калуын без хәзерге заманда да күзәтә алабыз. Әнә шулар үрнәгендә без татар гореф-гадәтләренең халык күңеленә тирән үтеп керүенә, мәдәни рухыбызның көченә инана алабыз.

Хәзерге заман татар архитектурасында гореф-гадәтләрне саклап калу һәм әлеге юнәлешне үстерү проблемасы аеруча кискен тора. Әмма аны тирәнтен ачык күзалламый торып, әлеге юнәлешнең үсешенә ирешү мөмкин түгел. Стиль һәм форма барлыкка килүнең гомуми кануннарын, шулай ук элеккеге заманда татар биналарының тышкы күренешен матурлаганда кулланылган архитектур чараларны белмичә, милләтнең мәдәни байлыгы турында ялгыш күзаллау барлыкка килергә мөмкин. Орнамент архитектурада милли үзенчәлек бирүнең иң төп чараларының берсе, мәдәни гореф-гадәтнең үзенә генә хас бренды булып санала.

Хәзерге вакытта Республикабызда төзелеш сәнәгате киңәйгәннән-киңәя бара, бер сүз белән әйткәндә, төзелеш – заманчалаша. Шәһәрләребез һәм авылларыбыз архитектурасы төрле ил стильләре чагылышларын алалар.

Үзебезнең татар халык стилен дә онытырга ярамый, корылмаларны һәм биналарны татар орнаментлары белән ешрак бизәргә кирәк.

90 нчы елларда Республикада яңарыш башлангыч, татарча укыту, шул исәптән татар телендә һөнәри белем бирү теләге белән Казан төзелеш инженерлары институтында (хәзер Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты) ике татар төркеме оештырылды. Максат итеп Татарстанның ике дәүләт телендә дә эш алып барырлык белгечләр әзерләү куелды.

Менә 26 ел дәвамында Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты (КДАТУ) татар телендә югары белем бирү һәм төзү материаллары фәнен укыту нәтиҗәсендә татарларның төзү өлкәсендәге тарихын өйрәнгән, ике телне дә яхшы үзләштергән белгечләр әзерләнде.

Республикабызның, халкыбызның, милли татар стилебезнең киләчәге – татар мохитендә милли тәрбия алып, татарча укып үскән студентларыбыз кулында. Аларга бу юнәлештә эшләргә ярдәм итсәк, идеяләрен, уйфикерләрен, планнарын гамәлгә ашырырга мөмкинлек тудырсак, бу мәсьәлә, һичшиксез, чишелү юлын табачак.

КДАТУның төзелеш кафедрасында татар төркеме студентлары белән күп еллар дәвамында үткәрелгән фәнни-эзләнү эшләре нәтиҗәсендә түбәндәге тәкъдимнәр барлыкка килде. Аларның һәрберсе уникаль, кызыклы һәм игътибарга лаек. Алар Республикабызның башкаласы Казан урамнарыннан башлап, авыл урамнарында, өй интерьерында халкыбызның милли мохитен булдыру, күтәрү, саклауга юнәлтелгән. Төрле юнәлешләрдәге

идеяләрне анализлап тупласак, татар милли стилен саклап калу мәсьәләсенең системалы чишелешен күрәбез. Әлеге бурычны динамик рәвештә, тиз арада башкарып чыгу мөмкинлекләрен ачыклау белән беррәттән, берничә еллык зур проектлар да карала. Аларны сезгә дә тәкъдим итәбез.

Татар стилен куллануның иң җиңел юлы булып биналарның тышкы якларына һәм декор элементларына татар орнаменты мотивларын кертү санала (төсле кушымтадагы рәсемнәрне карагыз).

Татарча орнамент бинаны тагын да матуррак итеп күрсәтә. Әлеге ысулның уңай ягы – аз чыгымнар белән тиз арада тиешле нәтиҗәгә ирешү. Элегрәк төзелгән бина фасадларын да бизәсәк, шәһәр урамнарында халкыбызның милли рухы чагылачак.

Бу эшләрне шәһәр үзәгендә һәм заманча төзелгән биналарда башкарып була, бу безгә зур мөмкинлекләр тудыра (төсле кушымтадагы рәсемнәрне карагыз).

Биналарга орнаментларны, бизәкләү элементларын заманча төс үзгәртүче, караңгыда яна торган материаллар кулланып пыялага ябыштыру, тентлар тарттыру, кичен яктырту ысуллары белән урнаштырып була.

Кайбер биналарны нәкъ менә шундый орнаментларга урын калдырып эшләнгән диярсең. Заманча бизәкләп җибәрсәң, алар күпкә ямьләнә. Күңелсез, биналарны бозып торучы реклама эленмәләрен дә милли орнаментларга алыштыру урынлы булачак.

Бөтен дөньяга танылган биналар үзләренең архитектур чишелешләре белән генә түгел, ә искиткеч матур милли орнаментлары белән дә бөтен кешене таң калдырыр иде. Татар мохитен тудыруда бу иң нәтиҗәле юл дияргә була.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов теләктәшлеге белән башланып киткән эш – Иске Татар бистәсен торгызу да уңышлы бара, инде Яңа татар бистәсе яңарыш юлына аяк басты. Казанда 2013 елда узган студентларның халыкара җәйге Универсиадасына әзерлек кысаларында, Каюм Насыйри урамындагы дистәгә якын тарихи йорт элеккеге рәвешендә яңартылды.

Бистәнең тәүге кварталын төзекләндергәндә, бер кунакханә һәм бер ресторан урын алган иде. Хәзер Каюм Насыйри урамында гына да туристлар өчен алты бина барлыкка килде.

Ләкин, кызганычка каршы, башкарылган эшләр көтелгән нәтиҗәгә китермәде: биналарның экстерьеры элекке тарихи рәвешен югалткан, аларда татар милли стилен чагылдыручы орнаментлар һәм бизәкләр юк диярлек. Әлеге эшләрне башкаруның максаты, иске татар бистәсен күтәрүдән тыш, халкыбызның милли стилен формалаштыру һәм булганын саклап калудан гыйбарәт.

Заманча реставрация бик күп детальләрне юкка чыгарган. Татар бистәсе төсләргә бай мохит булган. Ул XIX гасыр ахырында аеруча матур балкыган, чөнки йортларның алгы якларын тыгыз, якын итеп салу таләп ителгән вакытларда төс милли үзенчәлекне күрсәтә алырдай бердәнбер

чара булып саналган. Таш мәчетләрдә буяу фасадның пластик элементлары белән берлек хасил итеп, декоратив детальләрне ассызыклаган. Агач төзелеш сәнгатендә исә фасадларны Урта Азия традицияләренә якын рухта буяу киң тарала, бу очракта төс форманы ассызыкламый, киресенчә, аны җимерә яки ваклый. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, биналарның диварларын, аларда агач тышламасы яки штукатуркасы булу-булмауга карамастан, буяганнар.

Бу заманга килеп җиткән барлык өйләрдә дә, аларның гомуми халәте әлегә түзәрлек булуга карамастан, күп нәрсә җитешми: витражлар, төтен юлларының чүкеп ясалган өске каплавычлары, яңгыр суы торбалары юк. Шунлыктан бүгенге бистә элекке кебек түгел, үз йөзен ярым-йорты гына саклаган хәлдә.

Шушы күренешләрдән нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә була: күтәрелгән биналарның фасадларын татар милли стилендә бизәү, әлеге тарихи урамга уникаль биналар өстәп, аларны халкыбыз стиленә генә хас элементлар белән бизәп, бу урамда татар милли мохитен тудыру. КДАТУда татар төркемендә укып чыккан белгечләрне эшкә, ә татар төркемендә төрле курсларда укыган студентларны төзү объектларына практика үтүгә җәлеп итү Татар бистәсен торгызуда, һичшиксез, шактый зур нәтиҗәләр бирер иде.

Яңа Татар бистәсендә милли орнаментлар белән бизәлгән уникаль биналар төзү мөмкинлеге бар. Әлбәттә, аларны күп кеше, күпчелек туристлар йөргән җирләргә урнаштыру мәслихәт.

**Конгресс үзәге** – Бөтендөнья татар конгрессы үтә торган бина. Ул 1500 кеше сыярлык ике залдан гыйбарәт булып, бу заллар арасындагы дивар ачылып, 3000 мең кеше сыярлык зур бер зал хасил була ала. Аның проекты да эшләнде (төсле кушымтадагы рәсемнәрне карагыз).

Әлеге бина бөтендөнья татарларын җыеп, кунакларны кабул итеп, кирәкле дәрәҗәдә яшәү шартлары тудырып, берләштереп, конгресс уздыру, халкыбызның каршында торган төп мәсьәләләрне хәл итү үзәге булачак.

Конгресс үзәгенең төп үзенчәлеген фасадында башкарылган челтәрле татар милли бизәге һәм бинаның отышлы урнашуы тәшкил итә. Килгән кунаклар Казансу елгасы буйлап теплоходта республиканың тарихи урыннарына сәфәр кыла алалар.

Алдагыларга өстәп, шуны әйтергә була, бина яки корылманы татар стилендә төзергә теләсәк, ул татар халкының нинди дә булса бер милли үзенчәлеген чагылдырырга тиеш. Кем белә, бәлки киләчәктә самавыр, чәйнек, тәлинкә формасында да корылмалар һәм биналар барлыкка килер.

Татар халкы чәй эчү гадәтенә дә аерым игътибар бирә. Шуңа күрә, уникаль төзелешләр рәтенә чәйнек, самовар һәм чынаяк формасында башкарылган биналарны кертергә була.

Әлеге чәйханәгә кереп сәфәргә чыккан милләттәшләребез гореф-гадәтләрен искә алып, күңелләрен юатып чәй эчеп чыга алачак.

Касә формасында төзелгән ресторан – Яңа гына никахлашып чыккан парларга туй мәҗлесен татар милли стилендә, гореф-гадәтләрне саклап үткәрү өчен менә дигән бина! Яңа тормышка аяк баскан парларның күңелләренә, кайнар татар чәе сыман, гомер буена җитәрлек җылылык бирер иде ул.

Шулай ук Яңа татар бистәсендә милли стильдә театр бинасы төзү бик отышлы булыр иде. Аның проекты да әзер инде. Белгәнебезчә, татарлар өчен театр милли сәнгатне саклап торучы объетларның берсе булып санала. Һәр милләтнең театры ул милләткә кагылган гореф-гадәтләрне, традицияләрне чагылдырырга тиеш. Һәм бу максатка ирешүдә театрда уйнаган артистларның, куелган спектакльләрнең генә түгел, аның архитектур үзенчәлекләре дә, тышкы фасад күренеше дә зур роль уйный.

Тырпаеп торган багана башларын, стенадагы буш урыннарны бөтен татарларга да таныш булган татар халык әкиятләре геройлары образлары, скульптуралары белән бизәү фасад күренешен баетып җибәрер иде. Яңа бина шундый вак элементларга да игътибар итеп ясалырга, һәрбер «почмагы» белән милли татар стилен күрсәтеп торырга тиеш.

Төзү урынына килгәндә театр бинасын Яңа Татар бистәсендә урнаштырсаң кулаерак булыр кебек. Театрга керер алдыннан яки аннан чыккач та тамашачылар татар сәнгатенең спектакль белән генә тамамланмавын, ә урамнарның да, йорт-ишек алларының да татар стилендә эшләнүен күрергә тиеш. Фасадта заманча материаллардан күптөрле тәрәзәләр, витраж урыннары куллану тәнәфес вакытларында бина эченнән Татар бистәсен күзәтергә мөмкинлек бирер иде.

Ике яклап кулланылган витраж урыннарында түбә дә үтә күренмәле итеп эшләнергә мөмкин. Моның өчен калын һәм чыныктырылган яисә бизәкле калын пыяла яки үтә күренмәле материаллар кулланырга мөмкин.

Алда күрсәтелгән биналарда татар халкының тарихи хәтере чагылыш ала. Аларны Татар бистәсендә төзү бик отышлы булачак.

## Йомгаклау

Татарстан милли стильне характерлаучы үрнәк объектларны туплаган мәйдан булырга тиеш. Еraклардан сагынып кайткан милләттәшләребезнең күңелләрен сыендырырлык милли мохит тудыру мөһим бурычыбыз. Моңа, беренче чиратта, архитектур корылмаларны татар стилен саклап төзү ярдәмендә ирешергә мөмкин.

Киләчәктә дә үзебезнең милли юнәлешләребезне сакларга телибез икән, туристларны җәлеп итеп торасыбыз килә икән, нәкъ менә элеге проблеманы хәл итү – республикабыз төзүчеләре һәм архитекторларының игътибар үзәгендә булырга тиеш! Алдынгы Көнбатыш илләр тәҗрибәсен куллану белән беррәттән, гореф-гадәтләрне, бары татарларга гына хас стильне саклау да мәслихәт, чөнки «тарихы булмаган халыкның – киләчәге дә булмый» диләр бит.

Татар милли архитектурасын үстерү урамнарыбызда безнең халкыбызга гына хас, үзенчәлекле милли мохит тудырырга ярдәм итәчәк: бөтен дөньяга танылган биналар төзелеп, аларның фасадлары татар сәнгате рухында бизәлсә, милләтебезнең дәрәҗәсе күтәреләчәк, Татарстаныбыз туристлар җәлеп итеп торучы үзәккә әверелер иде. Бөтен милләттәшләребез дә республикабызның динамик үсешен күреп, көчәюен, танылуын, күтәрелүен күзәтеп куаныр иде. Әлбәттә, болар әлегә хыялда гына. Шулай да бу мәсьәлә яшь буынның игътибар үзәгендә тору күңелгә юаныч кертә. Бүген аларга эшләү мөмкинлеге тудыру зарур.

**Әдәбият**

*Бикбов А.Р., Файрушин Р.Р, Камалова З.А.* Нанотехнологияне пыяла корылмаларында куллану // Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 елларда). Казан: КДАТУ, 2017. Б. 161–164.

*Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С.* Декоративное оформление сельского жилища в казанском Поволжье. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 127 с.

*Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 188 с.

*Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 203 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 104 с.

*Дьячков И.В., Арютина В.П., Камалова З.А.* Физико-химические и технологические аспекты получения железооксидных пигментов различных цветов из местного сырья // Вестник Волжского регионального отделения Российской академии архитектуры и строительных наук. Н. Новгород, 2000. № 4. С. 7–100.

*Дьячков И.В, Камалова З.А.* Железоокисные пигменты Республики Татарстан // Разведка и охрана недр. 1996. № 2.

*Камалова З.А.* Югары уку йортларында татар телендә укыту – телне саклап калуның төп шарты һәм мөмкинлеге // Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 елларда). Казан: КДАТУ, 2017. Б. 69–74.

*Камалова З.А., Бикбов А.Р.* Казан үзәге биналарын милли орнаментлар белән бизәп, татар мохитен тудыру (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 391.

*Камалова З.А., Вәлиев А.И., Гыйльманов Б.Р.* Бизәкләрдә халкым киләчәге (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 391.

*Камалова З.А., Гатауллина И.И.* Эволюция роста татарской архитектуры и производства строительных материалов (тезисы) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 9.

*Камалова З.А., Гатауллина И.И.* Борынгы бизәкләрне хәзерге заман орнаментлары белән берләштерү (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 390.

*Камалова З.А., Рәхимов Р.З., Шакирҗанов Р.Ә.* Төзү материаллары: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Новое знание, 2012. 312 б.

*Минхаҗев А.И., Минхаҗев И.М., Камалова З.А.* Композицион портландцемент // Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 елларда). Казан: КДАТУ, 2017. Б. 168–174.

*Халит Н.Х., Альменова-Халит Н.Н.* Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

*Халит Н.Х., Альменова-Халит Н.Н.* Стили и формы татарской архитектуры Казани середины второй трети XVIII – начала XX в.: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 391 с.

***Камалова Зәһирә Абдулла кызы,***
*техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты доценты*

УДК 069:09 (045)

*Н.В. Герасимова*

# 1920 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАН МУЗЕЙЛАРНЫҢ СӘНГАТЬ КОЛЛЕКЦИЯЛӘРЕ: МАКСАТЫ, ФОРМАЛАШУ ПРОЦЕССЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ИРЕШЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

В статье рассматриваются процессы расширения художественных коллекций музеев Казани и развития сети музеев с художественными отделами в Татарстане в 1920-е годы. Выявляются основные направления собирательской деятельности, определяется роль государства в указанных процессах. Акцентируется внимание на значительном вкладе Казанского отдела по делам музеев в формирование художественных коллекций музеев Татарской, Чувашской и Марийской республик.

**Ключевые слова и фразы:** музей; художественные коллекции; выставка; Государственный музейный фонд; Отдел по делам музеев и охраны памятников искусства, старины и природы; Народный комиссариат просвещения ТАССР.

1917 елгы инкыйлабтан соң музейлар ачу һәм аларның коллекцияләрен туплау ил тарихында беренче мәртәбә дәүләткүләм бурычларның берсенә әверелә. Казан губернасында музейлар оештыру 1919 елның сентябрендә Казан губерна Мәгариф халык комиссариаты каршында оештырылган музейларны һәм сәнгать һәйкәлләрен, борынгылыкны һәм табигатьне саклау эшләре бүлегенә йөкләнә. 1919–1920 елларда Казан губернасының Козьмодемьянск, Алабуга, Тәтеш шәһәрләрендә музейлар ачылып, аларда аерым сәнгать бүлекләре эшли башлый. ТАССР оешкач, элекке губернаның көнбатышында урнашкан музейлар Казан музейлар бүлегеннән аерыла, һәм республиканың кантон тибындагы Зөя (Свияжск) һ.б. шәһәрләрендә музейларның яңа челтәрен төзү бурычы килеп баса.

Казан музей бүлеге хезмәткәрләре, 1919 елдан башлап, губернадагы хуҗалары калдырып киткән һәм национальләштерелгән кыйммәтле әйберләр белән тулыландырылган музей фондын тәртипкә китерә башлыйлар [Первая государственная…, 1920, с. 58–62]. Тупланган экспонатлар Татарстандагы төрле музейларга таратыла һәм 1930 ел ахырына хәтле алар урнаштырылып бетә [Национальный архив…].

Бу чорның иң мөһим саналган бурычларыннан берсе Республика Үзәк музеенда сәнгать коллекциясен формалаштыру була.

Коллекцияне тулыландыру берничә юнәлештә алып барыла. Беренче чиратта музей бүлеге әгъзалары, республикадагы сәнгать әсәрләрен һәм борынгы эшләнмәләрне музейга тапшыруларын сорап, халыкка мөрәҗәгать итәләр. Нәтиҗәдә,

П.М. Дульский язганча, музейга «ворвался целый поток пожертвований и предметов, взятых по охрану музея» [Дульский, 1920, с. 35]. Алар арасында И.Е. Репинның «Читающая девушка» дигән әсәре аеруча игътибарга лаек [Национальный архив…, д. 7, л. 13].

Тупланмаларның икенче бер төркемен сатып алынган әсәрләр тәшкил итә. Әйтик, Казан рәссамнарыннан Ф.И. Фешин, П.А. Радимов, А.Р. Платунова, Н.М. Сапожникова һ.б.ның эшләре шул юл белән алына [Национальный архив…, д. 7, л. 13–14; д. 162, л. 27 об.]. «Мир искусства») берлеге рәссамнары Н.К. Рерих, Б.М. Кустодиев, П.И. Львов, А.Н. Бенуа, Д.И. Митрохин әсәрләре коллекциясе А.Ф. Мантельдән сатып алына [Национальный архив… д. 7, л. 14]. Музейның 1919 елгы хисабында Ф. Гойядан офортлар альбомы, Л.О. Пастернакның офортлары һәм литографияләре сатып алынуы теркәлгән. 1928 елда Казан графигы И.Н. Плещинскийның эшләре сатып алына [Национальный архив…, д. 1539, л. 62].

Музейга губерна музее фонды сәнгать әсәрләре – скульптура, фарфор әйберләр, көмеш һәм пыяла эшләнмәләр, XVIII–XIX гасырларга караган сынлы сәнгать әсәрләре тапшырыла [Национальный…, д. 7, л. 14; д. 114, л. 72–73; д. 1539, л. 4, 5, 64].

Музей коллекциясенең тагын бер чыганагын Казан духовный академиясе музее, университетның Борынгы әйберләр һәм нәфис сәнгать әсәрләре музее, Көнчыгыш-педагогика институты музее ябылгач, алардан килгән әсәрләр тәшкил итә [Национальный…, д. 163, л. 365]. 1928–1929 елларда бу музейга Борынгы әйберләр һәм сәнгать музееның Г.И. Мешков тупламасындагы Европаның XV–XIX гасырларда эшләгән 8 мәктәбенә мөнәсәбәтле 50 гравер эшләнмә һәм 1 рәсем [Вербина, с. 10–18], Ф.П. Толстойның 1812 елгы сугыш темасын сурәтләнгән барельефлы әсәре һәм патшалар портретлары [Национальный…, д. 116, л. 37], антик һәм болгар культурасы әсәрләре [Национальный…, д. 116, л. 38–41] тапшырыла. Көнчыгыш-педагогика институты фондындагы инкыйлабка кадәр О.С. Александрова-Гейнс туплаган 37 картина да Татарстан үзәк музеена килеп ирешә [Национальный…, д. 116, л. 47].

Республикада ябылган чиркәү һәм монастырьлардагы сәнгати әһәмияткә ия әйберләр дә шушы музейга тапшырыла. 1929 елда, мәсәлән, Кафедраль соборның гыйбадәт өчен кирәкле әйберләр саклана торган бүлмәсеннән XV гасыр Евангелиясе һәм XVI гасыр плащаницасы (мәетне зиратка озатканда өстенә яба торган җаймә) бирелә. 1928 елда Кафедраль собордагы, Казанның Варвара һәм башка чиркәүләрендәге көмеш әйберләр музейга китерелә [Национальный…, д. 1540, л. 3 об.].

Үзәк музейның оешуына (ул 1894 елда төзелә) 25 ел тулу уңае белән 1919–1920 елларда музейга борынгы дәверләрдән башлап, 1900 елларга кадәр вакыт аралыгында төрле юнәлешләрдә һәм стильләрдә (реализмнан

башлап авангардка кадәр) иҗат иткән күп кенә рәссамнарның эшләре тапшырыла. Алар арасыннан Новгород язмаларының тугыз иконадан торган «Деисусный чин»ын, Ф.В. Васильев, С.Ю. Жуковский, И.Е. Репин, К.А. Коровин, М.В. Ларионов, Н.С. Гончарова, А.А. Осмеркин һәм башка сынлы сәнгать осталарының әсәрләрен аерып күрсәтергә була [Национальный…, д. 14, л. 8-9]. 1920 елда Дәүләт музей фондыннан Көнбатыш Европа граверларының В.В. Перцовта, Румянцев музее һәм Эрмитаж коллекцияләрендә сакланган әсәрләре [Вербина, с. 13–18] һәм В.Д. Фалилеевның 15 офорты [Дульский, с. 42–43] шушы музейга тапшырыла.

Шул ук елда музейга Губерна музей фондыннан С.А. Бахрушин белән Е.Д. Мясниковның шәхси коллекцияләреннән 100 әсәр китерелә: алар – XX гасыр башы рәссамнары К.А. Коровин, А.Н. Бенуа, Л.С. Бакст эшләре [Национальный…, д. 14, л. 3–4; д. 14, л. 1–2].

Шулай итеп, Казан музеена йөздән артык сынлы сәнгать әсәре тапшырыла. XX гасыр башында оештырылган «Мир искусства», «Союз русских художников», «Голубая роза», «Бубновый валет» кебек иҗат берлекләренә аерым игътибар бирелә. О.Л. Улемнова ассызыклаганча, алар сәнгатьтә авангардлык юнәлешен пропагандалыйлар һәм Казанда сынлы сәнгать әсәрләре музее оештыру максатын күздә тоталар [Улемнова, с. 12].

Музейга китерелгән эшләр Казанда беренче мәртәбә уздырылган Дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсендә күрсәтеләләр [Первая государственная…], күргәзмәдә гамәли сәнгать, борынгы һәм халык сәнгате предметлары [Денике, с. 50–59], җирле рәссамнарның 400 дән артык рәсем сәнгате һәм график әсәрләре тәкъдим ителә. Күргәзмә тәмамлангач, андагы экспонатларның күп өлеше музей фондында калдырыла.

Бу вакыйгаларның әһәмияте шунда: музей танылган рәссам-авангардчыларның рәсемнәре һәм график эшләре белән баетыла. Шул ук вакытта музей коллекциясен Казан рәссамнарыннан К.К. Чеботарев, А.Г. Платунова, И.Н. Плещинский, Ф.Ш. Таһиров һ.б.ның да әсәрләре тулыландыра [Улемнова, с. 6–19].

1920 еллар ахырына, «сул агымнар» белән көрәш нәтиҗәсендә, музей коллекциясендә рәссам-реалистлар иҗатына зур урын бирелә башлый. 1927 елда, мәсәлән, Казан музеена Третьяков һәм Цветков галереяларыннан, Яңа Көнбатыш сынлы сәнгате һәм Румянцев музейларыннан, Строгановлар көллиятеннән барлыгы 39 данә сынлы сәнгать әсәре кабул ителә [Национальный…, д. 78, л. 43–44]. Алар арасында И.А. Айвазовский, В.Г. Перов, В.Д. Поленов, В.Е. Маковский, М.В. Нестеров, В.А. Серов, С.Ю. Жуковский, И.И. Левитан эшләре зур урын били.

1930 елның февралендә Дәүләт музей фондыннан Автономияле Татреспублика Үзәк музеена XIX–XX гасыр башында иҗат ителгән, Рус музее фондында сакланган әсәрләрдән

Н.И. Альтман, Н.П. Крымов, Н.Д. Мелиоти, В.А. Серов, Н.К. Рерих һ.б. рәссамнарның эшләре китерелә [Национальный..., д. 114, л. 162].

Шунысы да мөһим, Татреспублика Үзәк музее үз коллекциясен республика шәһәрләрендә урнашкан музейлардагы экспонатлар хисабына да киңәйтә. 1929 елның окрябрендә, мәсәлән, Чистай туган якны өйрәнү музеennан Д.Д. Бурлюкның «Пейзаж с домом» әсәре, Тәтештән С.Ф. Галактионов, А.Г. Ухтомский, И.Д. Телегин рәсемнәре китерелә [Национальный..., д. 1185, л. 50].

Шулай итеп, 1920 елларда Автономияле Татреспублика Үзәк музее коллекциясе сынлы сәнгать үсешенең борынгы чорыннан башлап, XX гасыр башында барлыкка килгән яңа агымнар кысаларында иҗат ителгән әсәрләр хисабына формалаша, тулылана. Һәм Казанда барлык чорлардагы халык сәнгате әсәрләре урын алган, сынлы сәнгать культурасы музеен төзү идеясе өлешчә тормышка ашырыла [Искусство...].

1920 елларда дәүләт ирекле сәнгать остаханәләре – Архумас (инкыйлабка кадәр – Сәнгать мәктәбе) музей фондлары да яңа әсәрләр белән тулыландырыла. Остаханәләр директоры Ф.П. Гаврилов, музейны фәнни-тәрбияви учреждениегә үзгәртеп коруны күздә тотып, анда студентларның конкурс эшләрен урнаштыра һәм, вакытлыча, Татреспублика Үзәк музее фондындагы Л.С. Попова, А.М. Родченко, В.Ф. Степанова, О.В. Розанова әсәрләрен дә китертә [Национальный..., д. 14, л. 6]. Әмма 1925 елда, андагы музей ябылу сәбәпле, бу башлангыч туктатыла. Соңыннан андагы әсәрләрнең бер өлешен янгын юкка чыгара, калган эшләр кире Үзәк музейга кайтарыла.

1920 елларда Казанда яңа музейлар оештырыла. Шуларның берсе – Шәрык халыклары мәдәнияте музее [Выставка...]. Аның экспонатлары арасында болгар һәм татарларның керамик савытлары һәм зәркән бизәкләре, мордва, чирмеш һәм чувашларның чигүле эшләнмәләре, гольдлар орнаментлары, кытай фарфорлары, фарсы кулъязмалары була. Әмма 1922 елда, бина булмау сәбәпле, Татарстан Мәгариф халык комиссариаты Академүзәге карары белән ул Үзәк музейга кушыла һәм аның коллекциясе Үзәк музей бүлекләренә таратыла [Национальный..., д. 948, л. 81].

Казан губернасындагы башка шәһәрләрдә урнашкан музейларның сәнгать әсәрләре коллекциясен формалаштыруда Татарстан Мәгариф халык комиссариатының музейлар бүлеге зур роль уйный, аның ярдәме белән алпавыт утарларыннан, чиркәү һәм монастырьлардан, шулай ук аерым сатып алучылардан национализацияләнгән сәнгать әсәрләре музейларга тапшырыла.

Губернада беренче тарих-сәнгать музее А.В. Григорьев тырышлыгы белән Козьмодемьянскида оештырыла. Аның тупламасындагы сәнгать әсәрләре берничә чыганактан алына. 1918 елда эшли башлаган

Идел-Кама күчмә күргәзмәсе экспонатлары, Казанны А.В. Колчак гаскәрләре басып алу сәбәпле, Козьмодемьянскида калган була, һәм андагы Казан рәссамнарының, коллекционерларының 40 әсәре шушы шәһәр музеена бирелә. Икенче чыганакны А.М. Кокарев, Г.К. Лукомский, Д.И. Митрохин һ.б. рәссамнарның картиналарын, рәсемнәрен сатып алган А.Ф. Мантель коллекциясе тәшкил итә. Өченчесе – «Картиналар, этюдлар, эскизлар, рәсемнәр һ.б.ның беренче Козьмодемьянск күргәзмәсе» экспонатлары. Алар 1920 елда Казан губерна музее фондыннан, Казанда уздырылган «Беренче дәүләт күргәзмәсе»ннән һәм А.В. Григорьев, Н.Ф. Нейгебауэр кебек җирле рәссамнардан алынган була. Шулай итеп, 1921 елда Музейның сәнгать коллекциясендә 305 сынлы сәнгать әсәре, 11 әвәләп ясалган, 197 фарфор эшләнмә исәпләнә [Национальный..., д. 313, л. 54].

Татарстан районнарындагы музейлар арасында Тәтеш шәһәрендәге җирле туган як музееның сәнгать коллекциясе иң эреләрдән санала. Монда музейны төзүдә катнашкан рәссам һәм коллекционер А.Ф. Мантельның өлеше гаять зур. Ул музейга үз тупламасындагы «Мир искусства» рәссамнарының әсәрләрен дә тапшыра [Корнилов, с. 20]. Нәтиҗәдә бу музейда сәнгать әсәрләренең үз заманы өчен әһәмияткә лаек коллекциясе барлыкка килә, Б.М. Кустодиев, А.Ф. Гауш, Д.И. Митрохин һәм башка рәссамнарның кече формадагы график эшләре аеруча зур урын ала [Национальный..., д. 1178, л. 67–68].

Сәнгать әсәрләренең икенче төркемен XVIII–XIX гасырларга караган портретлар тәшкил итә: дворян Сазоновларның Людоговкадагы утарыннан национализацияләнгән әсәрләр (алар арасында Г. Дау тарафыннан эшләнгән Ф.В. Сазонов портреты игътибарны аеруча җәлеп итә). Өченче төркемдә Казан рәссамнары Н.И. Фешин, П.М. Дульский, А.Ф. Мантель, В.П. Соколов һ.б.ның әсәрләре [Национальный..., д. 491, л. 94–97] – алар Казан музейлар бүлегенең сәнгать фондыннан китерелгән. Коллекцияне декоратив-гамәли сәнгать предметлары – фарфор эшләнмәләр (савыт-саба, немецлар тарафыннан һәм Россия заводларында җитештерелгән сыннар), чигелгән әйберләр, кытай һәм японнарның декоратив-гамәли сәнгать предметлары, скульптура әсәрләре һ.б. белән тулыландыру дәвам итә [Национальный..., д. 121, л. 3. 4. 7]. 1923 ел уртасына Тәтеш музеенда 632 экспонат булып, шуларның 266 сын тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре тәшкил итә [Национальный..., д. 491, л. 81].

Алабуга җирле туган як музеенда да сәнгать коллекциясе туплана. Музей директоры язмасыннан аңлашылганча, ул җирле буржуазиядән тартып алынган әйберләрдән оештырыла һәм, әйтергә кирәк, бу музей сирәк очрый торган һәм затлы әйберләргә бай [Национальный..., д. 719, л. 11]. Музей анкетасында, коллекцияне тулыландыру

чыганагы буларак, Казан губерна үзәк китапханәсе, халык мәгарифе кантон бүлеге склады һәм әйберләрен музейга тапшырган җирле гражданнар исемлеге дә теркәлгән. Музейның сәнгать тупламасы 56 картинадан, Третьяков галереясы рус сынлы сәнгате әсәрләре альбомнарыннан, фарфор һәм бәллүр эшләнмәләрдән (барысы 80 данә), бронза статуэткалардан гыйбарәт [Национальный…, д. 719, л. 11]. Музейда И.И. Шишкин әсәрләре булуы да мәглүм [Национальный…, д. 491, л. 120].

1920 елда Дәүләт музейлар фондындагы 60 сәнгать әсәре Чистай шәһәрендәге Кантон туган як музеена бирелә. Алар арасында И.И. Машков, П.П. Кончаловский, В.В. Рождественский, Н.В. Мещерин, В.А. Гальвич һ.б.ның эшләре дә бар [Национальный…, д. 14, л. 1–2]. Әмма полотноларны «Беренче дәүләт күргәзмәсе»ндә катнашу өчен Казанга җибәрәләр. Күргәзмәдән соң аларны кире Чистайга кайтарганнармы-юкмы – әлегә кадәр билгесез. Шунысы мәгълүм: ул әсәрләрнең күп өлеше Татарстан Республикасы дәүләт сынлы сәнгать музее коллекциясендә исәпләнә.

Зөя (Свияжск) кантон музееның сәнгать коллекциясе Казан музее фондыннан китерелгән фарфор һәм бронза әйберләрдән, бер өлеше җирле кантон тарафыннан сатып алынган һәм национализацияләнгән әйберләрдән тупланган [Национальный…, д. 121, л. 1–2]. Архивта борынгылыкны һәм сәнгать һәйкәлләрен саклауның Казан бүлекчәсе музей фондыннан бирелгән предметларның исемлеге саклана. Анда язылганча, музейга китерелгән 107 данә предметның күбесен декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре – фарфор һәм пыяла савыт-сабалар, вазалар, сыннар, бронза статуэткалар, шәмдәлләр, таш һәм гипс эшләнмәләр, шулай ук 25 картина тәшкил итә. Картиналар, нигездә, билгесез рәссамнар тарафыннан башкарылган сынлы сәнгать әсәрләре, рәсемнәр, декоратив тукымалардан гыйбарәт; шулар арасында, И.И. Левитанның акварель белән ясаган пейзажы да бар.

Шулай итеп, 1920 еллар Татарстан Республикасы тарихына музейлар төзү чоры булып кереп кала. Нәкъ менә шул елларда музейлар эшчәнлегендә җирле тасвирый сәнгать әсәрләре туплау төп юнәлеш булып кереп кала. Татарстан Республикасы Үзәк музеен экспонатлар белән баетуда төп чыганакны Дәүләт музейлар фонды, ә кантоннардагы музейларда – Губерна музейлар фонды тәшкил итә.

ТАССР оешканнан соң республикадагы кайбер музейлар Чуваш һәм Мари автономияле республикаларына күчә, ягъни Казан губернасы музей эшләре һәм сәнгать, борынгы әйберләр һәм табигать һәйкәлләрен саклау бүлеге, Татарстандагы гына түгел, Идел буеның башка республикаларындагы музейларның коллекцияләрен туплауга да зур өлеш кертә.

**Әдәбият**

*Вербина О.Г.* К истории формирования коллекции графики Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан в 1920-е годы // Первые Казанские искусствоведческие чтения. Материалы научно-практической конференции 10–12 сентября 2009 года. Казань: Мир дизайна, 2011. С. 10–18.

Выставка культуры народов Востока: путеводитель по выставке. Казань: Первая государственная типография, 1920. 137 с.

*Денике Б.П.* Художественная выставка 1920 года в Казани // Казанский музейный вестник. 1920. № 5–6. С. 50–59.

*Дульский П.М.* Новые приобретения художественного отдела Казанского Губернского музея // Казанский музейный вестник. Казань, 1920. № 1–2. С. 35–46.

Искусство коммуны. 1918, 15 декабря.

*Корнилов П.Е.* Собрание художественных произведений казанских мастерских. Казань: Полиграфшкола им. А.В. Луначарского, 1927. 32 с.

*Корнилов П.Е.* Художественное собрание Тетюшского музея (краткий обзор) // Записки Тетюшского музея: Музей местного края при Педтехникуме. Казань, 1927. № 1. С. 19–20.

Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 2021. Оп. 1; Ф. Р–3682. Оп. 1.

Первая государственная выставка искусств и науки в Казани. Каталог. Казань: Первая государственная типография, 1920. 63 с.

Первая Козмодемьянская выставка картин, этюдов, эскизов, рисунков и проч. Каталог / автор вст. ст. А.В. Григорьев. Козмодемьянск: Государственная типография, 1920. 31 с.

*Улемнова О.Л.* АРХУМАС – мастерская художественного авангарда Казани // АРХУМАС. Казанский авангард 20-х. Каталог выставки. М.: Скорпион, 2005. С. 7–18.

*Улемнова О.Л.* Казанский авангард // Казанский авангард. 1910–1930-е годы: Художественные сокровища Татарстана: Собрание Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан. Казань: Заман, 2013. С. 6–19.

*Статья подготовлена при финансовой поддержке РФФИ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 17-14-160022*

*Мәкалә Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 17-14-160022 номерлы фәнни проект кысаларында әзерләнде*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 745

*О.Л. Улемнова*

# Л.Г. ФӘТТАХОВНЫҢ КИТАП ГРАФИКАСЫ

*Рәссамның тууына 100 ел тулу уңаеннан*

Статья посвящена малоизученной стороне творчества одного из ведущих живописцев Татарстана второй половины XX века. В книжной графике Л.А. Фаттахова автор выделяет основные направления, связанные с национальной темой, которая раскрывалась им как в иллюстрациях к большим романам татарских писателей, так и к татарским и восточным народным сказкам. Рассматривается широкое разнообразие технических и выразительных средств, которыми пользовался художник, видоизменения индивидуальной художественной манеры. Творчество художника рассматривается в контексте развития советской книжной графики двух послевоенных десятилетий.

**Ключевые слова:** книжная графика, иллюстрация, военная тема, национальная литература.

Лотфуллла Габделмән улы Фәттахов (27.09.1918, Түбән Новгород губ., Сергач өязе – 17.06.1981, Казан) – күренекле татар рәссамы, тарихи һәм тематик картиналар иҗат итү остасы, ТАССР һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), РСФСРның халык рәссамы (1980). Л.Г. Фәттахов үзенең «Сабантуй» (1957), «Яңа буралар» («Свежие срубы», 1959) һ.б. әсәрләрендә милли геройларның характерын беркемдә кабатланмаганча ачуга ирешә. 1940–1950 елларда аның иҗатында төп урынны графика били, һәм график хезмәтләре белән тамашачылар игътибарын яулый, рәсми дәрәҗәдә хөрмәт казана (1958 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була). Шуның белән бергә, Л.Г. Фәттаховның бу юнәлештәге эшчәнлеге, нигездә, сәнгать белгечләре игътибарыннан читтә кала. Совет чорындагы рәсем сәнгате өлкәсенең күренекле белгечләре Н.В. Черкасова [Черкасова, с. 41–47], А.Б. Файнберг [Файнберг, с. 42–47], С.М. Червонная [Червонная, с. 199–200], Э.Я. Зарипов [Зарипов, с. 170–172] үз хезмәтләрендә Л.Г. Фәттаховның график иҗатына бик аз тукталалар, фәкать Л.Я. Ельковичның рәссамга багышланган монографиясендә генә аның китап графикасына киңәйтелгән характеристика бирелә [Елькович, с. 41–52].

Л.Г. Фәттахов 1935–1939 елларда Казан сәнгатъ училищесында белем ала, әмма, үз чорының башка рәссамнары кебек, берничә еллар республиканың рәсем сәнгате тормышыннан читтә яши. Армиядә хезмәт итү, сугыш хәрәкәтләрендә катнашу, әсирлек еллары аның өчен кырыс сынаулар чоры һәм бай тормыш тәҗрибәсе туплау дәвере була. 1946 елда, демобилизацияләнеп, Казанга кайткач, Л. Фәттахов Сәнгать фондында эшли

башлый. 1948 елда Татарстан китап нәшриятының сәнгать редакциясе җитәкчесе Б.М. Әлминов, талантлы яшь рәссамнардан яңа коллектив туплау нияте белән, бу эшкә Л. Фәттаховны да җәлеп итә.

Фронтовник-рәссамнарга сугыш тәҗрибәләрен яңабаштан кичереп, үз тәэсирләрен укучыга-тамашачыга җиткерү өчен менә дигән мөмкинлек туа. Аның нигезен 1940 елларның икенче яртысыннан актив басыла башлаган хәрби әдәбият тәшкил итә. Башта алар басмаларның формасын һәм форматын (зур булмаган китапчыклар яки брошюралар) билгеләүче кечкенә хикәяләр һәм повестьлардан гыйбарәт була, әмма, һәркайсы диярлек, текстның башында яки ахырында, яисә һәр биттә сериялəп урнаштырылган рәсемнәр белән бизәп бастырыла.

Л.Г. Фәттаховның китап графикасы ул чорда сәнгати ачышлары белән әллә ни аерылып тормый, ул еллар аның өйрәнү, сугыш вакытында аерылып торган шушы һөнәргә әйләнеп кайту, профессиональ күнекмәләр, алымнар һәм методлар үзләштерү чоры була. А. Әхмәтнең «Солдат балалары» (1948), Ф. Кәримнең «Разведчик язмалары» (1949), Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» (1949) һәм башка китапларга ясалган реалистик рухтагы иллюстрацияләре каләм һәм тушь белән штрих техникасында башкарылган, рәссам аларны язучы текстына җитди якын килеп, эчтәлеккә тәңгәллек белән, үзе кичергән хәрби тормыш чынбарлыгын дөрес чагылдырып сурәтли. Л.Г. Фәттаховның ул еллардагы график иҗатын бәяләп, Л.Я. Елькович, рәссамның иллюстрацияләре китапның эчтәлеген баетмый, чөнки иллюстрацияләрнең роле сюжет сызыгын кабатлауга, повестьның маҗаралы эчтәлеген чагылдыруга гына кайтып кала, дип яза [Елькович, с. 41–42]. Әмма бу хәл сугыштан соңгы вакыт өчен әдәби әсәрләрне рәсемнәр белән бастыруның закончалыклы һәм зарури этабы булган күрәсең. Китап бизәлешенә болай якын килү авторның шәхси теләге чагылышы да, әдәби әсәрне кабул итү һәм аның хакында фикер йөртү дәрәҗәсе дә, укучылар даирәсенең ихтыяҗы да булырга мөмкин. 1950 еллар уртасына, Россиядәге кебек үк, Татарстанда да әдәби вазгыять алышына – китап графикасына үзгәрешләр кертүне таләп итә торган зур романнар барлыкка килә. Ул еллардагы китап продукциясе каты тышлыклы калын-калын китаплардан гыйбарәт була. Китап бизәлешенең классик методлары торгызыла, иллюстрацияләр, Сталин дәверендәге тыныч тормышка хас, «зур стильдәге» социалистик реализмның гомум тенденцияләрен чагылдырган китап текстларын баету белән турыдан-туры бәйләнмәгән, үз мөстәкыйль картина буларак кабул ителә башлый.

Китап рәссамнары даирәсе үзгәреп, рәссам-бизәүчеләр, рәссам-иллюстраторлар барлыкка килә. Беренчеләре – китапның тышлыгын, титул битләрен, шмуцтитулларны эшләү белән шөгыльләнә, китап исеме һәм мәкалә башлары өчен шрифтлар

уйлап таба, вак декоратив элементларны, китапны бүлекләргә аеруны башкарса, икенчеләре – нигездә китап текстына кушымта рәвешендәге иллюстрацияләр ясый. Л.Г. Фәттахов исә, табигый ки, рәсем сәнгате белгече буларак, иллюстраторлар сафында санала. Аның шул заман татар классикларыннан К. Нәҗминең «Язгы җилләр» (1952), Г. Бәшировның «Намус» (1954), Г. Гобәйнең «Маякчы кызы» (1956) романнары өчен кара акварель техникасы белән иҗат иткән иллюстрацияләр сериясе әсәрнең эчтәлеген әдәби текстка параллель рәвештә үзенчәлекле итеп гәүдәләндерү үрнәге санала. Алар шул чор иллюстраторларының күпчелеге өчен хас манерада эшләнсәләр дә, рәссамның гадәттән тыш төгәллеге, милли гореф-гадәтләрне, татар халкының көндәлек тормыш рәвешен белүе Л.Г. Фәттаховка әсәрләрен зур ышаныч белән башкарырга ярдәм итәләр. Аның рәсемнәре – зур осталык үрнәге, аларга язучы тудырган образларның психологиясен тирәнтен аңлап гәүдәләндерү хас. Н.В. Черкасова билгеләп үткәнчә, тушь ярдәмендә җиңелчә күләгәле күчешләр белән эшли белүе рәссамның иҗатына карата «эчкерсезлек һәм ышандыру» хисләре өсти [Черкасова, с. 42].

Фәттаховның китап графикасындагы «сәнгать»ле сызыкларның кульминациясе аның 1950 елларда татар халык экиятләре өчен иҗат иткән иллюстрацияләренең өч сериясендә – 1952 елда «Гөлчәчәк» экиятләр җыентыгында (1953 елда Таткнигоиздатта басылып чыга), СССР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм тарих институтының Казан филиалы тарафыннан 1956 елда әзерләнгән «Татар халык экиятләре»нең II томында, 1958 елда «Татар халык экиятләре»нең I томында (ул 1956 елда иллюстрацияләрсез генә нәшер ителгән була) чагылыш таба. (Соңыннан бу иллюстрацияләр төрле җыентыкларга кертелеп һәм аерым папкалар рәвешендә берничә мәртәбә басылып чыга.) Татар экиятләренең академик басмаларына Л.Г. Фәттахов белән Х.Г. Якупов бергәләп эшләгән иллюстрацияләр өчен, бу ике рәссамга 1958 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Л.Г. Фәттахов маҗаралы экият дөньясына күмелә. Әлбәттә, ул шаян яки сатирик рухтагы рәсемнәрен дә чынбарлык белән, үз халкына хас характерлы сыйфатлар белән тыгыз бәйләнештә сурәтли. Рәссам халык иҗатында урын алган юморны, экият персонажларының характерларын һәм рухи кичерешләрен дөрес аңлап эшли. Һәм тагын да яңарак тасвирлау чаралары эзләвен дәвам итә. Экиятләргә катгый бер төстәге акварель белән ясаган иллюстрацияләрен Л.Г. Фәттахов күп төсле палитрага алыштыра. Аның композицияләре төрледәнтөрле һәм үзенчәлекле, ракурслары көтелмәгән, линияләре төгәл һәм мәгънәви, төсләр байлыгы да я контрастка көйләнгән, яисә төсләрнең гармоник чиратлашуы кебек нюанслардан гыйбарәт. Л.Г. Фәттахов һәр героен аңа гына хас характеры белән

гәүдәләндерә белә, шул ук вакытта ул аның хисләре һәм эмоцияләре байлыгын да сурәтләүгә ирешә.

Ул эшләгән еллардагы полиграфик мөмкинлекләр чикле булганлыктан, автор образларын һәрвакыт үзе күзаллаганча тасвирлый алмаган, ул аның Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музеенда сакланган иллюстрацияләренең оригиналларыннан да ачык сизелә. Л.Г. Фәттахов халык әкиятләре һәм Көнчыгыш риваятьләре темасы өстендә 1940 еллар ахырына кадәр эшли. Бу өлкәдә аның А. Нәвоиның «Фәрхәд белән Ширин» поэмасына эшләгән иллюстрациясе аеруча уңышлы килеп чыга, ул бизәлеше ягыннан сугыш чоры һәм сугыштан соң тыйнак кына рәсемнәр белән нәшер ителгән басмалардан тыныч тормыш «муллыгы»н чагылдыруы белән аерылып тора. Күн тышлыкка, әйтерсең, борынгы манускриптлардан күчереп бастырылган орнаментлар, гарәпләрнең бормалы язуын хәтерләткән шрифтлар, китапның һәр бүлегендә сюжетка бәйле 40 кушымта, күпсанлы орнаменталь бизәкле концовкалар һ.б. – барысы да борынгы Көнчыгыш атмосферасы тудыра. Рәсемнәрнең төгәл график эшләнеше, тәэсирле фигуралар, геройларның эмоциясе ачык чагылуы да укучыны битараф калдырмый.

Л.Г. Фәттаховның «Мең дә бер кичә» әкиятләренә ясаган рәсемнәре дә басмаларда кат-кат (1948, 1950, 1951) нәшер ителә. Әлеге иллюстрацияләрдә графиканы күптөслелек (полихромия) алыштыра, бизәкләрнең композицион төзелеше декоратив келәмнәрнекенә охшатыла, персонажларның характеры гротеск рәвешендә сурәтләнә, аларны декорацияләр фонында гәүдәләндерү әсәргә театраль характер өсти.

Л.Г. Фәттаховның шартлы графика теленә, әдәби әсәрне үзе укып һәм үзе аңлаганча сурәтләүгә омтылышы аның иҗатының башлангыч чорында ук, ягъни сәнгатьтә 1950 еллар ахырына таба совет җәмгыяте тормышындагы зур үзгәрешләр белән бәйле яңа дәвер башланганда ук уянган була. 1950 еллар ахыры – 1960 еллар башындагы «җепшеклек» процессы рәссамнарга үз фикерләре буенча иҗат итү өчен чагыштырмача ирек бирә, аларның сәнгати юнәлешләрен индивидуальләштерергә, яңа формалар һәм тасвирый чаралар эзләргә мөмкинлек тудыра, әлегә кадәр яшерелеп килгән мәгънәви эчтәлеккә, графикада лирик-эмоциональ юнәлеш формалаштыруга юл ача. Китап рәссамнары нәшер ителә торган басмалар киңлегендә үз мөстәкыйльлекләрен аңлап, сюжетка ияреп түгел, аны тулыландырып һәм киңәйтеп иҗат итәләр, үз интерпретацияләрен өстәп, параллель сюжет барлыкка китерәләр.

Бу тенденцияләр Л.Г. Фәттахов иҗатында да ачык чагыла, ул аның инде аерым әсәрләргә эшләп өлгергән иллюстрацияләреннән үк (мәсәлән, 1958 елда Г.Әпсәләмов җыентыгында) күренә. Л.Я. Елькович бу хакта бик дөрес итеп, рәссам язылган әсәрнең күчермәсен генә гәүдәлән-

дерми, аны график сәнгатьнең образлы чаралары ярдәмендә тулыландыра, ди [ Елькович, с. 52].

Л.Г. Фәттаховның китап бизәлешенә яңача якын килүе Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1959) әсәре буенча иҗат иткән иллюстрацияләрендә ачык күренә. Анда рәссам, графика өчен хас булган шартлы алымнарны кулланып, кара һәм ак төсләр белән хисләрне кузгатырлык һәм фаҗигале вакыйгаларны күз алдына китерерлек экспрессив образлар тудыра. Китаптагы образларның кичерешләрен сурәтләүдә рәссамга фашистлар әсирлегенең бөтен авырлыгын үз башыннан уздыруы, анда күргәннәре ярдәм итә.

Шулай итеп, Л.Г. Фәттаховның 1940–1950 еллар китап графикасы рәссам иҗатының мөһим чорын тәшкил итә. Ул елларда Л.Г. Фәттахов, рус совет китабы сәнгате үсешенең гомуми закончалыкларын чагылдыру белән бергә, шул заман татар җәмгыятенең яшәү рәвешен реалистик методлар белән гәүдәләндерүне дә яхшы үзләштерә һәм аны тормышка ашыруда үзеннән лаеклы өлеш кертә. Моңа ул татар халкының тарихи үткәнен тирәнтен өйрәнү, узган гасырларда ук инде Урта Азиянең китап бизәү үрнәкләренә (ул революциягә кадәрге татар китапларына да кагыла), халык иҗаты традицияләренә мөрәҗәгать итү аша ирешә.

**Әдәбият**

*Елькович Л.Я.* Лотфулла Фаттахов. М.: Советский художник, 1960. 73 с.

*Зарипов Э.Я.* Художники книги // Здравствуй, книга! / сост. и общ. ред. М.С. Глухова. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. С. 161–179.

*Файнберг А.Б.* Народный художник // Лотфулла Фаттахов. Живопись. Графика. [Альбом] / сост. и ред. К. Миннибаев. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. С. 34–78.

*Червонная С.М.* Искусство Советской Татарии. Живопись. Скульптура. Графика. М.: Изобразительное искусство, 1978. 296 с.

*Черкасова Н.В.* [Вступительная статья] // Изобразительное искусство Советского Татарстана / под ред. С. Ишмуратовой. Казань: Таткнигоиздат, 1957. С. 3–46.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы хезмәткәре*

УДК 82-1/-9

***Гыйрфанзадә***

# ДУСТЫМА

Письмо классика татарской литературы, государственного и общественного деятеля, видного ученого, публициста Галимджана Ибрагимова адресовано своему другу. Через воспоминания он анализирует те события, которые произошли с ними в годы учебы в медресе. В нем раскрывается внутренний мир, душевное состояние автора.

Письмо было опубликовано 17 марта 1909 года (№ 64) в газете «Аль-ислах» под псевдонимом «Гирфанзаде».

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, «Гирфанзаде», татарская литература, публицистика.

Сөекле Кәрим! Хәтереңдәме, бу кадәрле еллар дәвам итеп, дәһернең *(заманның, чорның)* җан өзгеч агырлыклары эчендә сүнми, югалмый, үзенең вөҗүдене саклап килгән синең белән минем арадагы «дустлык»ның иң беренче ноктасы кай заманда башланды? Минем бу көнге кеби күз алдымда тора: син дә минем кебек юаш, оялчан, йомшак бер бала иденң.

Мәдрәсәдә, икемез дә яңа килгәнгә, иске шәкертләр безне бик кага, читсенәләр иде. «Апаңны бирәсеңме?», «Каенишем буласыңмы?» дигән сүзләр белән икемезне дә рәнҗетәләр иде. Әниемезне, өемезне сөйләп, «Яшь кенә башыңыз белән ничек сагынмыйсыз, ничек егъламыйсыз? дип, безне егълаталар иде. Икемез дә яңа килгәнгә, кыенлык та уртак булганга, һәр икемез дә гайн *(тулысынча)* бер золым белән җәберләнгәнгә, безнең күңелемез бер-беремезне якын күрә иде.

Бер атна кичтә Закир, Шакир вә Галимнәр, бездән дүртәр тиен акча алып, үзләренең пешергән боткаларына безне дә куштылар. Күптән бирле аш ашаган булмаганга, безгә бу бик тәмле тоелды. Без бик сөендек. Шатлана-шатлана бергә ашап, ахырдан табак-савытларны да икәү бергә юдык. Менә шуннан соң безнең күңелләремездәге якынлык, берлек тышка да чыгып, без икәү дуст кушылып киттек. Арамызда мәгъсуманә *(керсез)* бер дустлык башланды.

Ул вакытка хәзер инде ун еллар үтеп китте. Һәм шул көннән бирле арамызда берлек, дустлык, бер тән, бер җанлылык дәвам итте. Арадагы бәгъзы вакыйгалар сәбәпле дустлык җебе өзелсә дә, ул вакытлы гына булды. Без тагы берләшеп, бу көнгәчә мөхиббанә *(дусларча)* яшәп килдек.

Мин үземнең зиһенемдә сакланган «яшьлек вә шәкертлек заманымның хатирәләрене» актарып карый башласам, үткән гомеремне күз алдына китерсәм, һәммәсендә дә синең катышлыгың, уртаклыгың булганлыгы күренә. Әллә нинди сагынмалыклар, мәгъсумиятләр *(эчкерсезлекләр)* очрыйдыр.

Кыен булмаса, синнән дә шул хатирәләрне күз алдыңа китерергә үтенер идем. Без бигрәк бергә, бигрәк мөхиббанә яши идек. Сарыф *(морфология)* укыганда, игъламы идгамларны *(авазларның охшашлануын аңлатуны)*, тәркиб *(кушма җөмлә)* укыганда, фарсыларча озын тәркибләрне, кафия *(рифма)* укыганда, мәтеннәрне *(текстларны)* бик тырышып, бергәләп ятлый идек. Син укыганда, мин тыңлый идем, мин укыганда, син тыңлый идең. Шуның аркасында һичбер аңламаган нәрсәләрне дә зиһенгә ала идек. Икемез дә дәресләрне тизрәк белеп, аның өстенә теге Ногман Фәйзъларга игътираз *(фикернең дөреслеген дәлилләү)* өчен никадәрле шәрехләр дә карый идек.

Хәлфә беремезгә йомыш кушса, самавыр куярга, яхуд *(яки)* керче хатыннан керләр китерергә әмер итсә, без «хәлфә безне ярата, шуның өчен йомышка йибәрә» дигәндәй, шатланашатлана икәүләп чаба идек. Җен, пәридән саклану өчен төнлә тышка чыкканда да гел икәү бергә чыга идек.

Мәдрәсәдә бер-бер нәрсә хакында низаг, сугыш чыкса, без һәрвакыт икемез бер яктан сөйли идек. Тик «Башкортмы, мишәрме артык?» мәсьәләсе тикшерелә башланса, шул вакытта гына мотлак, мишәрләрне мактап, башкортларны яманлый идең. Аларга әллә никадәрле кабахәтләр иснад кыла *(аудара)*, аларның кара богдайда йөзгәнлегене, торнага табынганлыгыны сөйләп, караларга тырыша идең. Моңарга каршы мин дә тик тормый идем: мишәрләрнең юлда табылган алтын сәгатьне аждак *(аждаһа)* дип, куркып, күсәк белән кыйнауларыны, аларның умарта кортыны намаз, дип, сатып алганлыкларыны берәм-берәм саный идем. Ничек тә башкортны үз халкымыз булган өчен өскә чыгарырга, мишәрне аста калдырырга тырыша идем.

Аннан соң губерналар белән мактанышканда да без бергә кушылып бетми идек. Син үзеңнең губернаңны, андагы ишаннар, хәзрәтләрнең күблегене, мәсҗедләрнең зурлыгыны әйтеп, мактана, моңа каршы мин дә үз губернам өчен арып беткәнче талаша идем. Аннан кала мәдрәсәдәге бүлмәләр хакында низаг булганда да, син үз тора торган бүлмәңезне, мин үзем торганны мактый идем. Менә шундый мәсьәләләрдән башка да без даимән бер яклы, бер юлда идек. Аерылмый, таралмый, мотлакан *(шиксез)*, бергә бара идек. Мәдрәсәдә кизү чираты беремезгә килсә, аны икәүләп кәтә, чүпләрне бергәләп түгеп, хәляәны *(бәдрәфне)* да бергә тазарта идек. Боларга башка урыннарда да гел бергә идек. Хәтме зиярәт кеби һәркем үзе өчен генә тырыша торган урыннарда да без берберемезне онытмый идек.

Онытмадыңмы? Бервакыт шулай мәсҗедтә Коръәнне хәтме тәмам булып, акча өләшә торган көндә мин кайда утырырга белмичә аптырап йөри идем. Алгы сафлар шәкерт белән тулы, беркая да урын калмаган иде. Син ничек булса да кысылдың, тыгызландың да яныңа мине сыйдырып, мин өч сумны эләктердем.

Синең бу яхшылыгыңны мин тәкъдир итеп, зиярәттә сиңа кайтардым: хәзрәтләргә якын тирәдә һәммә сафлар тулганга, син кайда утырырга белми йөри идең. Мин яныма сыйдырдым да, син Гыйльман байның бер сумыны суктың.

Хәтме зиярәт кеби урыннарда да без менә шулай һәр заман яклаша, ярдәмләшә идек. Бер бунда гына түгел, һәр эштә шулай идек. Әллә нинди мәгънәви җепләр безнең икемезне бик нык бергә баглаган иде. Безнең дустлык көннән-көн көчәя, хөлусый *(ихлас)* вә самимилана бара иде. Үзенең вөҗүдене саклап, тәрәккый итә иде. Хәтта мантыйк укучы ике шәкертнең сердәш вә чын дуст булуы һичбер күрелмәдеге хәлдә, без икемез «Исагуҗи»ны чыкканчы әүвәлгечә хөлусый вә самимилы дустлар булып яшәдек.

Бу вакытлардагы моназарә *(бәхәсләшү)* генә безне аера алмады. Моназарә соңында сугышып китү сәбәпле, бер-ике үпкәләшеп йөрсәк тә, тагы дустлаша, тагы бер-беремезнең кочагына атыла идек. Ләкин бөтен укучыларны бер-беренә дошман ясап бетергән «мантыйк һәм моназарә» үзенең явыз тәэсиренә безне дә мәхкүм итте *(хөкем итте)*. Бара торгач җиңде. Моназарәләр ешайган саен сугышу күбәйде, үпкәләшү күбәйде. Үпкәләр бара-тора берәр көндә генә бетми, унар көнгә сузыла башлады. Бу үпкәләр бара торгач, үзенең сафлыгыннан чыгып, дошманлыкка әйләнде. Ниһаять, арамыздагы дустлык җебе өзелеп, безнең арада салкынлык, дошманлык, икенчемезне мәгълүб *(аста)* вә түбән калдырырга тырышучылык башланды. Моңарчы бер-беремезгә мәхәббәт, ихтирам хисе белән тулган күңелләрдә нәфрәт, тәкъбих *(начар сүзләр әйтү)* дәртләре йирләште. Һәр эштә бер-беремезне яклап, ярдәмләшеп килгән ике мәгъсум *(гөнаһсыз)*, үземезә тарафдарлар җыйнап, икенчемезне изәргә, шәкерт күзеннән төшерергә, үч алырга йөри башладык.

Әй, дустым! Башымыздан үткән бу кара вә пычрак нокталарны зикер кылу *(искә алу)* бик авыр, бик уңгайсыз булса да, ачы хакыйкать булгач, зикер итми дә китә алмыйм.

Икенчемезнең зарарына ни нәрсә эшли алсак, һәммәсене дә чирканмадык, эшләдек. Әллә нинди начарлыкларга, җәбер вә золымга мөртәкиб *(гөнаһ кылучы)* булып беттек. Җиде-сигез ай буенча бер-беремезгә сүз дәшми йөрдек. Бу салкынлык, дошманлык, мантыйк, моназарәгә мәхәббәт вә иҗтиһад *(тырышлык)* белән мөнасибән *(яраклашып)* тәрәккый итеп, үзенең кәмаленә *(бөтенлегенә)* ирешмеш иде. Ниһаять, бездә, иске тәрбиягә, иске мәдрәсәгә нәфрәт итеп, яңалык тарафына мәел *(кызыксыну)* башланды. Шуның белән бергә, арада салкынлык кимеп, борынгы дустлыкның кайту өмидләре кузгалды. Без икемез дә, дошманлыкны бетереп, дустлыкны яңартырга тели идек. Фәкать канга сеңешкән әхлаксызлык каршы тора иде.

Ниһаять, бу табигать, әхлаксызлык белән көрәшә-көрәшә, аны мәгълүб итеп *(җиңеп)*, чын дуст булып киттек.

Безнең бу соңгы дустлыгымыз әүвәлгесенә караганда бераз башкача булып, әүвәлгесе мәгъсуманә исә, бунысы гали иде. Күңел берлеге өстенә мәсләк, фикер берлеге кушылып, киләчәктә әллә ниләр кылмак, үземезнең хезмәтемез белән дөньяны нурга чумдырмак була иде.

Бер заманнар фәлсәфәи диния, фәзаиле исламия гашыйкы булып, ислам вә мөселманнарга хезмәт, дәһер вә миссионерлара җавап бирмәк өчен әзерләнә идек. Аннан соң дәхи азрак алышынып, мәзлумнар *(кыерсытылганнар)*, бичаралар өчен җан бирү дәрәҗәсендә хезмәтләр вәгъдә кылып йөри башладык.

Киләчәктә әллә ниләр кылмакчы, күккә чыкмакчы, бөтен дөньяга сәгадәт кояшы тугдырмакчы идек. Безнең уйлар бик гали, хыяллар бик югары. Фаразлар бик тирән иде. Хиссиятемез бөтен кызулыгы белән күңелгә урнашып, үзенең ялкыныны һәр заман сача иде. Әй соң, күңелле иде бу чаклар...

Көннәр кичте. Дөньялар алышынды, тормыш үзенең явыз тырнагы белән эләктереп алып, сине бер якка, мине икенче якка ыргытып бәрде. Бөтен уйларны, бөтен хыялларны җимерде. Ул гали хисләр, вәгъдә кылынган хезмәтләр, ул матур киләчәкләр мәгыйшәт диңгезенең каты дулкыны эчендә һәммәсе югалып бетеп, син һәм мин вә башка иптәшләр – һәммәмез дә «наөмид» *(өметсез)*, күңелсез калдык.

Син дә үз башың, үз кайгың белән кысылдың. Мин дә һәм башкалар да шулай булдык. Һәммәмез дә харап булып, табигатьнең биргән фәзаилене *(яхшылыкларын)* җыеп, мәрхүм калдык.

Никадәрле тырышсак та, һичберемез уйлаган ноктасына барып җитә алмады.

Менә хәзер кулымда тора Сәлимнең мәктүбе: ул үзенең надан калуыннан, ачлыгыннан зарлана. Тәгълим кыла *(укыта)* торган урыныннан да байы ачуланган да куып йибәргән. Бичара Сәлим халыкның һөҗүменнән тик чак үзе котыла алган.

Кичә генә Гыйльманнан да хат бар иде. Ул да үзенең тормышыннан сыкрана. Ни укырга рәт юк, ни башкача тормышны төзеп булмый, ди.

Менә өстәлдә ята синең дә мәктүбең: син дә тормышыңнан риза түгелсең! Укучы татар яшьләренең аяныч хәлене тасвир кылып киләсең дә, ахырда сүзне үз тугрыңа китереп: «Иптәш! Бөтен уйлар юкка чыкты. Бөтен хисләр сүнде. Һәммә өмидләр очты. Планнар җимерелде. Ни гыйлем алып булмады, ни бер һөнәр табылмады. Инде хәзер «ни эшләргә?» дә аптырадым.

Хәят минем өчен күтәрү мөмкин булмаган агыр йөк кабиленнән күренә. Күңелем тынычсыз, үзем өмидсез вә фәүкылгадә мозтарибмен *(гадәттән тыш аптырауда калганмын)*. Болардан котылу өчен һичбер тарафта юл юк. Мәгәр тар вә караңгы кабер генә бардыр», – дисең. Минем үз хәлем сезнең һәммәңезнекеннән дә аянычрактыр: бөтен сәгатьләрем үземнең яшь гомерем, кувә вә истигъдадымның *(көч һәм булдыклылыгымның)* әрәм булуына күз яше түгеп, киләчәгемнең ямьсез, тәмсез вә караңгы

һәм өмидсез булуыннан курку белән үтәдер.

Киләчәгем шул дәрәҗәдә өмидсез вә изгеч күренә ки: мин аны өстемә җимерелеп төшеп, үземне изәргә, җанымны алырга торган тау-таш кеби күрәм. Бунардан котылу, истикъбалемне *(киләчәгемне)* яктырту өчен никадәрле талпынсам да, муаффәкъ була алмыйм *(булдыра алмыйм)*. Кире егылам, һаман үземнең рухымны газаплый торган эшләргә очрыйм. Хәлсез канатым мине үзе генә алып китә алмавына ышанам. Тормыш мине изде. Һаман изә, киләчәктә дә изәчәге күренәдер.

«Ни эшләргә?» Никадәрле уйласам, тырышсам да, мин бу сөальнең җавабыны хәл кыла алмыйм. Башка берни әйтергә белмәгәч: «Мин һәм иптәшләрем! Без барыбыз да татар инкыйлабының корбаннары инде», – дип егъларга керешәм. Шулар гына минем җыелып килгән гайре мөнәтаһи *(чиксез)* кайгы агуыны җыеп ташлыйлар.

Дустым Кәрим! Хәзер инде минем өчен ләззәт бетте. Өмид киселде. Тик шул яшьлек хатирәләрене актару, күз яше түгүдән башка бернәрсә дә калмады.

Хуш, иптәш. Хәзергә сау бул!

24 февраль. ***Гыйрфанзадә.***

*«Әлислах» газетасы,*
*1909 ел, 17 март (№ 64)*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*фәнни хезмәткәре* ***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы*** *әзерләде*

УДК 82-94

***Г. Ибраһимов***

# КАЗАНДА ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ЙОРТЫ АЧАРГА КИРӘК

Данная статья классика татарской литературы, видного ученого, публициста, государственного и общественного деятеля Галимджана Ибрагимова (1887–1938 ) была написана 1926 году и напечатана в газете «Кызыл Татарстан». После образования Татарской АССР наряду с другими национальными вопросами, затрагивающими общественную жизнь татар, поднимается вопрос о необходимости создания единого татарского культурного центра. По мнению Г. Ибрагимова, этот центр необходим для развития национальной культуры.

**Ключевые слова:** Г. Ибраһимов, публицистика, татарская литература, история, татарская культура.

Пролетариат диктатурасы нигезендә татар мәдәнияте киң сулыш алды, төпләнеп, тамырланып үсә башлады. Мәдәниятебезнең төрле тармаклары аз бер заман эчендә сабакланып, чәчәкләнеп килгәнен күрәбез. Боларга принцип буенча юлбашчылык кылу чаралары тиешле учреждениеләрдә оештырылган булса да, көндәлек гамәли эшләрдә таркау көчләрне бергә туплап, киң бер коллектив рәвешендә җыйнап алып утырган бер урын тудыра алмады әле. Менә шул хакта уйлый башларга вакыт җитте, дип беләм.

Башка җөмһүриятләрдә совет ярдәме белән җирле мәдәниятләр өчен мондый үзәк урыннарны мәдәният йортлары исеме астында оештырдылар. Төрки көнчыгыш өлкәләрдән бу эшнең иң яхшы куелганы байлыклы азәрбайҗанда булса кирәк. Аларда бу «Төрек мәдәнияте йорты» дип атала.

Азәрбайҗанның зур көтепханәсе, төрле гыйльми җәмгыятьләре шунда урнашканнар. Гыйльми, әдәби диспутлар өчен җыйнак, әйбәт, матур залы бар. Мәдәниятчеләр шунда гөж килеп кайнашалар. Төрле профессиядә, төрле эштә, башкача таркау булган көчләр шунда мәдәниятчеләр (культурниклар) коллективы ясап эшләп баралар.

Бездә мондый урынның юклыгы байтак уңайсызлыклар ясый. Кайбер иптәшләр, баштарак, бәлки татар театры бинасы шундый урын булып китә алыр дип өмидләнгәннәр иде, булмады.

Игеннәр дә үсеп, төзү заманы эчендә барганга күрә, хәзер безгә инде моның өчен татар мәдәнияте йорты дип аерым мәсьәлә буларак кузгалырга кирәк.

Белоруслар безгә караганда санда, мәдәни куәттә күп алда булмасалар да, байтактан бирле үзләренең «Белорус мәдәнияте институты»н асрап киләләр. Миңа ирешкән мәгълүмат яңлыш булмаса, үткән елгы бюджетта гына бу оешманың өлеше 50000 (илле мең) иде. Безнең финанс хәлебез андый

зур планнарга хәзергә ирек бирмәс әле. Ләкин юрганга күрә аяк сузып, кечерәк күләмдә булса да, татар мәдәнияте йорты ачу мәсьәләсен менә шул мәгънәләр буенча аңларга кирәк. Татарстан хөкүмәте бу эшкә, әлбәттә, яхшы карап, мөмкин булган дәрәҗәдә булышлык итәр дип ышанабыз. Моның иң үткен җире, әлбәттә, өлкә бюджетын төзегәндә бер статья итеп кертеп җибәрү һәм гамәлгә кую моментыдыр. Татар мәдәнияте йорты мәсьәләсен күтәргәндә, аны шул рәвештәрәк алга китерергә була.

Минемчә, бу учреждениянең татар күпчелеге торган якта булуы тиешле. Таки *(әмма)* ул турыдан-туры татар хезмәт халкы массасының үзәгендә, хезмәт татар зыялылары эчендә булсын.

Моңарчы тавык кетәге кебек кечкенә, тәбәнәк, аз һавалы ярым караңгы ике-өч бүлмәдә яшәп килгән «Үзәк татар көтепханәсе» әле күптән түгел Совнарком *(Совет народных комиссаров)* һәм Наркомпрос *(Народный комиссариат просвещения)* тарафыннан кабул кылынып, яңа туып килгән «Татарстан китаплар палатасы», шулай ук моңарчы Гыйльми үзәк бүлмәләрендә яшәп килгән «Татарны өйрәнү җәмгыяте» кебек оешмалар, өлкәне тикшерүгә, гыйлемгә, әдәбиятка гаид *(караган)* түгәрәкләр һәммәсе хәзерге җир белән күк арасындагы хәлләрдән чыгып, шунда төпләнерләр, моның аркасында мәдәниятчеләребез арасында коллектив рәвешендә эшләп баруга юл ачылыр.

Болар өстенә, әлбәттә, бер клуб булуы кирәк. Моны байтак иптәшләр күптән кузгаталар, Гыйльми үзәккә бу хакта тәклифләр *(әмер итүләр)* дә булды, ләкин ул клуб әнә шундый бер урынга багланса гына реаль мәгънәсе чыгачак, татар хезмәт массасы белән якыннан багланган зыялыларыбыз, гыйльми-әдәби көчләребез, журналистларыбыз, укытучыларыбыз, яшьләребез, композитор, әдип һәм шагыйрьләребез һәммәсе шунда кайнарлык, хәзерге таркау хәлдән чыгып коллективизациягә юл ачылачак.

Шунда әдәби кичәләр, гыйльми-әдәби диспутлар, түгәрәк җыелышлары оештырырга мөмкин булачак.

Әлбәттә, үзеннән-үзе мәгълүм, бу эшләрнең һәммәсендә баштан ук советның, партиянең юлбашчылыгы тәэмин кылынган булырга тиешледер.

Җәй үтте. Ял итүләр бетеп, эшкә тотыну башланды. Өлкә бюджеты кебек гыйльми-мәдәни чараларга ныклап тотыну кебек эшләрнең вакыты җиткәнлектән, минемчә, әлбәттә, «Татар мәдәнияте йорты» кебек бер үзәк тудыру чарасын күрергә бик вакыт килде.

Хәзер моны башларга кирәк.

**Галимҗан Ибраһимов**

*«Кызыл Татарстан» газетасы,*
*1926 ел, № 19 (26 август).*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре* ***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы*** *әзерләде*

# ТУКАЙ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП

## [Бәяләмә: Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886–1907). – Казан, 2018. – 448 б.]

XX йөз башы татар әдәбияты күгендә якты йолдыз булып балкыган Г. Тукай яңа заман шигъриятенең нигез ташларын сала, халыкның моңлы җырчысына, аның рухи таянычына әйләнә. Алдагы буыннарга мирас булып калырлык әсәрләрендә үзен фәлсәфәче, олы гуманист, милләтвәрвәр шәхес итеп таныта. Тукай иҗаты бүген дә көч, илһам биреп кенә калмый, яшәеш сорауларына җавап табарга, киләчәккә өмет-ышаныч белән карарга ярдәм итә.

Милләт яшәеше символына әверелгән бөек Тукайның тормыш сәхифәләре, иҗат баскычлары һәрдаим зур кызыксыну уятып килә. Бу юлда инде зур эш башкарылып, бай мәгълүмат тупланды. Әдип турындагы истәлекләрдә, фәнни тикшеренүләрдә, вакытлы матбугатта чыккан язмаларда аның тормыш юлы, иҗаты шактый тулы күз алдына бастырыла. Ә.Х. Алиева, Ф.И. Ибраһимова тарафыннан төзелгән «Г. Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы» (2003) китабы шагыйрь яшәешен бер системага салып һәм туплап бирүнең уңышлы үрнәге булып тора. Ә инде әдип белән бәйле фәнни эзләнүләрнең уңышлы нәтиҗәсе рәвешендә 2016 елда «Тукай энциклопедиясе» дөнья күрә. Шуның белән бергә, ачыклык кертәсе, тулыландырасы сорау-мәсьәләләр әле байтак: «Әдип тормышында ул үзе булган, яшәгән урыннар нинди роль уйный?», «Шагыйрьнең нәселнәсәбе белән рухи бәйләнеше нәрсәдә чагыла?», «Тукай нинди шартларда әдәби иҗатка килә?», «Әдип иҗатында чагылыш тапкан тема-мотивларның реаль җирлеге нидән гыйбарәт?»

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан әзерләнеп, 2018 елда З. Рәмиев, М. Ибраһимов редакцияләвендә басылып чыккан «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907)» китабы югарыдагы сорауларга җавап эзләү рәвешендә язылган. Хезмәтнең «Кереш» өлешендә искәртеп кителгәнчә, Тукайның тормышы һәм иҗатына бәйле мәгълүматлар, нигездә, аерым кешеләр шәрехләве аша килеп ирешкәнгә, алар субъектив бәяләүдән котыла алмый. Шуңа да төрле мәгълүматларны бергә җыю, туплау аша Тукай тормышын һәм иҗатын төрле ассылыкларда укучыларга тәкъдим итү чор таләбе булып тора. Ике томнан торачак китапның безнең кулдагы беренче томы Тукайның Казан артында үткән балачагы һәм Уральск шәһәрендәге тормыш һәм иҗат хроникасын күз алдына бастыра.

*«Ходай шунда җан иңдергән, / Мин шунда туган...»* дип аталган беренче бүлекчәдә

кечкенә Габдулланың, туганнан алып, 6 яшькә кадәрге тормыш сәхифәләре яктыртыла. Әдип иҗатына ачкыч табасың килсә, аның туган җиренә кайтырга кирәк, дигән фикер яхшы билгеле. Әдәбиятны өйрәнүдә «биографик метод»ны яклаучылар карашынча, туган җирнең табигате, тарихи сәхифәләре, булачак әдипнең әйләнә-тирәсе, туганнары, якыннары һәм аларның эш-гамәлләре – болар барысы да яшь күңелдә тирән эз калдырып, соңрак, гадәттә, тема-мотивлар буларак, әдәби әсәрләрдә киң чагылыш таба. Хезмәт авторлары да моны яхшы аңлап эш итә. Тукай туып үскән Казан арты төбәге татар халкы тормышында гаять мөһим урын алып тора. Бигрәк тә XVIII–XIX гасырларда ул үзенең мәдрәсәләре һәм аларда укып бөтен мөселман дөньясында танылу алган Г. Курсави, Ш. Мәрҗани кебек шәхесләре белән танылa. Шуңа да Тукайның балачагы белән бәйле Казан артындагы авыллар тарихы, Тукайның әти-әнисе, туганнары турындагы бай мәгълүмат әлеге чорны күз алдына бастыра. Иң мөһиме, төрле истәлекләрне, документларны бергә туплап бирү, аерым кешеләр шәрехләвендәге фикер-карашларны башка яктан карап бәяләү мөмкинлеге бирә. Белгәнебезчә, Тукайның бала чагын «Исемдә калганнар» автобиографик әсәрендә язылганча гына күзаллау киң таралган. Күпләр Габдулланың бик яшь булып, ул елларны хәтерендә сакламавын яисә бик томанлы гына белүен, ә әсәрнең исә авылдашлары, якыннары сөйләгәннәр буенча гына язылуын искә алмый. Шуңа да Габдулланың әтисе Мөхәммәдгариф нәселе яисә әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла мулланың атаклы Кышкар мәдрәсәсендә белем алып, шагыйрь буларак та танылу алуы, балалары, шул исәптән оныгы Габдулла турында кайгыртуы турындагы истәлекләр, бер-берсен тулыландырып, әлеге шәхесләргә, вакыйгаларга карашмөнәсәбәтне баетып җибәрә. Без шуны ук «Тукаев» фамилиясе килеп чыгышы яисә Габдулланың Казанда Мөхәммәтвәли һәм Газизә тарафыннан тәрбиягә алынуы турында да әйтә алабыз. Әйтик, Тукайның фантазиясе аша гына әсәренә килеп кергән «Асрарга бала бирәм, кем ала?» дип кычкырып йөрү күренешен күпләр әлегәчә реаль чынбарлык итеп күз алдына китерә.

*«Дөньяга иң элек күзем ачылган урыным»* дип аталган бүлекчәдә Тукайның Кырлай авылы белән бәйле сәхифәләре ачыла. Кырлайга килгәндә Габдуллага инде 6 яшь. Аның дөньяга күзе ачылып, күп нәрсәне аңлый, белә башлаган вакыты. Авылның матур табигате, кешеләре, яшьтәшләре белән уеннары, шактый мул тормыш, крестьян хезмәте – боларның берсе дә булачак шагыйрьнең игътибарыннан читтә калмый. Нәкъ менә Кырлайда Габдулла беренче тапкыр мәдрәсә ишеген ачып, белем дөньясына аяк атлый. Аның инде характер сыйфатлары формалашып, ул сүзгә тапкыр, юморга бай, яхшы укучы малай булып үсеп килә. Кырлай белән бәйле вакыйгаларлар киләчәктә аның әдәби

иҗатында үзенчәлекле тема-мотивлар, халыкның яшәү рәвешен чагылдырган сыйфат-билгеләр рәвешендә киң урын алачак.

Хезмәтнең икенче бүлегенә Тукайның Уральск (Җаек) шәһәрендәге тормышы белән бәйле сәхифәләр туплап бирелгән. Бүген инде Казакъстан дәүләтенә кергән шәһәрдә Г. Тукай 12 елдан артык гомерен уздыра, үз чоры өчен әйбәт белем ала, төрки халыклар һәм Шәрык әдәбияты белән таныша, рус мәдәниятенә якыная һәм үзе дә әдәби иҗатка килә. Шуңа да китапның төп өлешен алып торган материаллар дүрт өлешкә бүленеп, яшүсмер Габдулла яшәгән мохитне, аңа йогынты ясаган шартларны, кешеләрне төрле яссылыкта карау, бәяләү мөмкинлеге бирә. Билгеле булганча, XVIII–XIX гасырларда Оренбург төбәге татар җәмгыятенең мәдәни үзәкләреннән берсе була. Татар сәүдәгәрләре салган Каргалы авылы – Сәет бистәсе даны еракларга тарала. Оренбургтан чагыштырмача ерак булмаган Уральск (Җаек) шәһәре дә, авторлар билгеләп үткәнчә, «татар халкының бер мәдәни үзәге булып, монда яшәүче татарлар шәһәрнең һәм төбәкнең икътисади, иҗтимагый һәм мәдәни тормышында зур роль уйнаганнар» (45 б.). Бу төбәкнең тарихына, күптөрле бәйләнешләргә караган материаллар чор рухын, халык тормышын күз алдына бастыра. Татар, рус, казакъ телләрендә дөнья күргән хезмәтләрдән, истәлекләрдән Уральскиның кайнап торган тормышы күзаллана. Әлеге шәһәрдә руслар, татарлар, казакълар күмәкләшеп яши, сәүдә эше алга китеп, төп урынны татар сәүдәгәрләре алып тора. Мәчетләр, мәдрәсәләр салына, мәдәни тормыш җанлана. Сәүдәгәрләр Садыйк Әмиров, Мортаза Гобәйдуллиннар тарафыннан салынган «Казан» миһманханәсе Уральск мөселманнары өчен мәдәни үзәккә әйләнә. Монда очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә. Әлеге чараларда казакъ яшьләре дә күпләп катнаша.

Авторлар билгеләп үткәнчә, «Тукай, шагыйрь буларак, төрле мәдәниятләрне үзенә сыйдырган Уральскида формалаша». Яшь егеткә әйләнә-тирәсе, якыннан аралашкан кешеләр зур йогынты ясый. Шуңа да Габдулланы чакырып китергән Газизә апасы (әтисенең сеңлесе), аның ире Галиәсгар Госманов, рус теле укытучысы Әхмәтша Сираҗетдинов, әтисе Мөхәммәдгариф белән бер мәдрәсәдә укыган, «Мотыйгия» мәдрәсәсенең мөдәррисе Мотыйгулла хәзрәт, аның улы, Уральскида татар вакытлы матбугатын оештыручы, Тукайдан журналист «ясаучы», соңрак беренче татар профессиональ җырчысы буларак танылу алган Камил Мотыйгый турындагы мәгълүматлар кызыксынып укыла, Тукай даирәсе турында бөтенлекле күзаллау тудыра.

Күп төрле мисаллар, фактлар, истәлекләр белән эзлекле һәм максатчан танышу – моңа кадәр калыплашкан фикерләрне чорга һәм вакыйгаларга бәйле субъективлыктан арындырып карарга, бәяләргә, нәтиҗәләр чыгарырга ярдәм итә. Бигрәк тә мәдрәсәдәге мохит, Шәрык

дөньясыннан, шул исәптән аның әдәбиятыннан мәгълүматлы хәлфә Камил Мотыйгый һәм яшь төрекләр хәрәкәтендә актив катнашканы өчен Россиягә качарга мәҗбүр булган, төрек һәм француз әдәбиятларын яхшы белгән Габделвәли Әмрулла кебекләр Тукайга гаять зур йогынты ясап, беренче чор иҗатының төп юнәлешләрен билгеләргә ярдәм итәләр.

Уральскида милли-мәдәни тормышның алга китеше, милләт гаме белән яшәгән кешеләр калкып чыгу, татар вакытлы матбугаты үсеп китүгә дә юл ача. Рус революциясе нәтиҗәсендә яулап алынган матбугат ирегеннән файдаланып, 1906 елның 15 октябрендә беренче татар журналы «Әлгасрелҗәдид» чыга башлый. Аерым чыганаклар күрсәткәнчә, журнал чыгаруга әзерлек алдан алып барыла. Мәдрәсә мөдәррисенең улы, Тукайның хәлфәсе Камил Мотыйгый тырышлыгы белән мәдрәсә шәкертләре 1903 елда ук кульъязма «Әл-мәгариф» газетасы, соңрак «Әлгасрелҗәдид» кульъязма журналы чыгара. Тукайның беренче әсәрләре дә «Әлгасрелҗәдид» аша беренче тапкыр укучыларга килеп ирешә. Патша хөкүмәте рөхсәте белән чыга башлаган «Әлгасрелҗәдид» журналы, Уральск шәһәре белән генә чикләнмичә, Урал һәм Идел буе мөселман дөньясында, казакълар арасында да тарала. Анда сәяси һәм иҗтимагый мәсьәләләргә, мәгариф һәм әдәбиятка караган материалларга киң урын бирелә. Журналның күп саннарына ясалган күзәтү, язмаларга бәйле шәрехләүләр, истәлекләрдә чагылган фактлар чор рухын тулы чагылдырып, Тукай әдәби иҗатка килгән дәверне тоемларга ярдәм итә. Журналда, танылып килүче язучылар Ф. Кәрими, Г. Гафуров-Чыгтай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакыйлар белән бергә, рус әдәбияты үрнәкләре дә дөнья күрә. Әнә шундый шартларда Тукайны бөтен татар дөньясына таныткан шигырьләре – «Алла гыйшкына», «Сорыкортларга», «Пар ат», «И каләм» һ.б. – журнал битләрендә урын ала.

«Әлгасрелҗәдид» журналы белән бергә, Г. Тукай «Фикер» газетасында да актив басыла башлый. Авторлар язып үткәнчә, К. Мотыйгый наширлегендә һәм редакциясендә чыккан «Фикер» газетасы битләре яшь әдипнең актив җәмәгать эшлеклесе дә булып җитешүе»нә (...) юл ача. Күпсанлы истәлекләрдән, газета төпләмәләреннән мәгълүм булганча, Тукай редакторлык вазифасын да башкарган һәм иң актив авторларның берсе саналган. Монда аның «Мужик йокысы», «Хөррият хакында», «Государственный думага», «Яз галәмәтләре» кебек шигырьләре басылып чыга. Публицистик язмалары Тукайны оста журналист, милләтпәрвәр шәхес, ачы телле тәнкыйтьче итеп таныта. Редакциянең сәяси-иҗтимагый һәм социаль-милли мәсьәләләрдә кыюлыгы, актив позициясе газетаның киң танылуына китерә. Шуңа да аның битләрендә танылган шәхесләрдән Зариф Бәшири, Нәҗип Думави, Фазыл Туйкин, Ризаэддин Фәхретдин һ.б.ның әдәби әсәрләре, публицистик яз-

малары урын ала. Шунысы да игътибарга лаек, газетада казакъ бүлеге булып, аны Батырҗан Каратаев җитәкли. Тугандаш халыкның тормыш-көнкүреше, иҗтимагый хәрәкәткә тартылуы да басма битләрендә чагылыш табып, аның казакълар арасында да таралуына китерә. Китапның тагын бер үзенчәлеге шунда, анда бәхәсле мәсьәләләргә караган материаллар да урын ала һәм укучыга нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирелә. Мисал өчен, Уральск сәүдәгәре М. Гобәйдуллин, хәйрияче буларак, шәһәрнең татар җәмгыятенә, шул исәптән мәчет-мәдрәсәләргә даими булышып тора. Тукай исә аерым фактка таянып, «Матбага белән уйнаган бер байга» шигырендә аны төрлечә кимсетә, хисләренә таянып, субъектив бәя бирә.

*«Шаярсаң күрсәтер «Уклар» / Яңак төптән утларны»* дип аталган бүлекчәдә Тукайның «Уклар» журналы белән бәйле тормышына, иҗатына караган материаллар урын ала. Фәнни хезмәтләрдәге, шул чор вакытлы матбугатындагы мәгълүматлар, истәлек язмалары аша әлеге журналның оешуы, мәйданга чыгуы, эчтәлеге, максат-бурычлары күз алдына бастырыла. Тукай бу басмада да редакторлык вазифасын башкара, актив язышa. Күп төрле чыганаклар шуны күрсәтә – журналның авторлары аз булганлыктан, шагыйрь фельетон һәм памфлетларларны күп язып, еш кына, төрле тәхәллүсләр куллана. Бу исә аларның авторын төгәл ачыклауны бермә-бер кыенлаштыра. Журнал үзенең төп юнәлешен эзлекле саклый һәм татар җәмгыяте үсешен тоткарлап торган һәртөр искелекне усал тәнкыйтьли. Авторлар ассызыклап үткәнчә, «журналның күп сәхәифәләрендә татар халкын искелеккә ябышып ятмаска, башка милләтләрдән гыйбрәт алып, алга карап эш итәргә өйдәүләр чагылыш таба» (104 б). Шунысын искәртик, журналдагы эшчәнлеге Тукайның әдәби иҗатына бай материал бирә, алар сатирик образлар, алым-чаралар рәвешендә чагылыш таба.

Хезмәтнең *«Җырлап торам, торган җирем тар булса да...»* дип аталган бүлекчәсендә Тукайның Уральск чоры поэзиясенә күзәтү ясалып, бәя бирелә. Уральскидагы тормышының соңгы 3 елында шапгыйрь актив иҗатта була. Аның «Уральск чоры шигърияте ул – (...) кыска гына вакыт эчендә һәм бик яшь килеш табигать биргән сәләтнең, әдәби тәҗрибә баскычын узып, зур талантка әверелү вакыты» (111 б). Әлеге үзенчәлекне ачыклау максатында Тукай шигырьләре әдипнең шул чор әдәби мохитенә нисбәтле эзләнү юнәлешләрен билгеләү, фәлсәфи-эстетик тирәнлеген, сыйфатын һәм үсеш-үзгәреш юлларын ачыклау рәвешендә тикшерелә. Тукай, беренче чиратта, күпгасырлык татар әдәбияты традицияләрендә формалаша. Моны иҗатында киң урын алып торган уртак образлар, халык иҗатыннан килүче халыкчан сурәталымнар дәлилли. Шагыйрь суфыйчылык әдәбиятын да яхшы белә. Аның иҗатындагы Коръән мотивларында, дини эчтәлектә суфыйчылык традицияләре ачык

тоемлана. Р. Харрасова билгеләп үткәнчә, Тукайга гарәп-фарсы һәм төрек әдәбиятлары да зур йогынты ясый. XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башында төрек әдәбиятының күпләп тәрҗемә ителүе дә эзсез калмый билгеле. Шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында төрек теленең күп урын алуы да шуның белән аңлатыла. Тукайның башлангыч чор әсәрләре сәнгати планда йомшаграк, теле дә авыр, әмма аларда, Тукайга хас үзенчәлекләр буларак, детальләр төреслеге, капма-каршылык алымы, прототиплардан файдалану һ.б. урын ала. Шагыйрь өйрәнү дәверен тиз арада үтеп, татар тормышын торгынлыктан чыгаруны алга куйган тема-мотивларга мөрәҗәгать итә. Милли тормышны бөтен каршылыгында чагылдыру максатында йокы һәм наданлык, яшь каһарман һәм каләм кебек мотивлар бер әсәреннән икенчесенә күчә барып, кайберләре тотрыклы лейтмотив булып формалаша.

Бу чорда әдип фольклордан, урта гасырлардан килүче традицияләрне заман рухы белән бәйләп, мәгърифәтчел эчтәлек белән сугарып, милләт язмышы мәсьәләсен алга куя. Язма авторы искәртеп үткәнчә, гомум милли мәнфәгатьнең шәхси теләкләрдән өстенлеге фикерен татар укучысына тәкъдим итеүе белән ул өр-яңа сүз әйтә. Хезмәттә әдипнең мәхәббәт темасына, пейзаж сурәтләренә, яшәеш фәлсәфәсенә караган шигырьләре дә этрафлы бәяләнеп, сыйфат-билгеләре ачыклана. Рус әдәбиятына таянып язылган шигырьләре дә шагыйрьнең сәнгати эзләнүләрен, үсеш-үзгәрешен аңларга ярдәм итә. Уральск чоры иҗатыннан күренгәнчә, Тукай Яңарыш дәвере казанышларын үзләштерә барып, милләт гаме белән яшәүче шәхес булып күтәрелә һәм халыкчан шагыйрь булып таныла.

Шулай итеп, «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907)» җыентыгы (төзүчеләре – З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов, Г.М. Ханнанова, Ә.Х. Алиева, Н.Ш. Насыйбуллина, Р.Ф. Харрасова, А.И. Әхмәтова) Тукай яшәгән чорны, аның әйләнә-тирәсен, шәхес һәм әдип буларак формалашуга китергән мохитне бөтенлекле күз алдына бастыра, байтак сорауларга ачыклык кертә. Китапның татар һәм рус телләрендә булуы да укучылар даирәсен бермә-бер киңәйтеп җибәрә һәм аларны бөек шагыйрьнең әдәби дөньясына якынайтуга хезмәт итә.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*

# ГАРӘП ТЕЛЕ – КОРЪӘН ТЕЛЕ
## [Бәяләмә: Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек / төз. Ринат Сәфәр. – Казан, 2016. – 652 б.]

Татар теле материалы нигезендә әледән-әле яңа сүзлекләр эшләнә, басыла тора. Ләкин күп кенә очракларда андый сүзлекләрнең төрле нәшриятларда һәм аз тираж белән басылып чыгуы хезмәтне үз вакытында киң катлам укучы игътибарына тәкъдим итүдә аерым кыенлыклар тудыра: күпләп сатуга чыгарылмаганлыктан, үзәктәге китап кибете киштәләрендә андый сүзлекләрне очратып булмый диярлек.

Мәкаләбездә шундый яңа хезмәтләрнең берсе – «Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек» (Казан, 2016, 652 б.) турында бәян итәргә ниятлибез.

Соңгы елларда милләттәшләребез арасында дин белән кызыксынучылар саны арткханнан-арта бара. Мәчет-мәдрәсәләр каршында тел курслары ачыла, дин нигезләре укытыла, төрле телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, җомга вәгазьләре яңгырый. Илаһият өлкәсендә югары белемле булырга теләгән кешегә Россия төбәкләре арасында беренче булып Казанда оештырылган Россия ислам институты эшләп килә. Изге Болгар җирендә Ислам академиясе сафка бастырылды. Академия каршында магистратура, аспирантура дәрәҗәсендә дини һәм дөньяви белем алу мөмкинлекләре җайга салынып килә.

Гарәп телен үзләштереп, Коръән серләренә төшенергә теләүчеләр өчен махсус әдәбият, һәртөрле уку-укыту әсбаплары нәшер ителә тора. Шунысы әһәмиятле: басылган ярдәмлекләрнең шактый өлеше гарәп телендә булган дини эчтәлекле беренчел чыганакларны туган тел аша аңлатып, шәрехләп бирүгә корылган. Мондый ысул, дини тәгълимат тарату белән беррәттән, аралашу өлкәсендә телебезнең мөмкинлекләрен тулырак һәм нәтиҗәлерәк файдалану өчен дә уңай шартлар тудыра. Югарыда телгә алынган сүзлек, туган телебезгә таянып, гарәп телен өйрәнүчеләр, дин өлкәсендә белем эстәүчеләр өчен, ислам тәгълиматының төп чыганакларыннан саналган Коръәне Кәрим һәм хәдисләр, шулай ук башка дини эчтәлекле текстлар, борынгы төрки-татар әдәбияты үрнәкләре белән танышканда тагын бер файдалы ярдәмлек була ала.

Сүзлекне төзүче автор – Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә күп кенә еллар эшләп, инде тәҗрибә туплап өлгергән галим Ринат Сәфәров. Сүзлек шәригать белгече С.С. Гайнуллинның тырышлыгы һәм ярдәме белән нәшер ителгән.

Сүзлекнең максатын автор, дини эчтәлекле текстларда очрый торган гарәп сүзләренең татарчага дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен тәкъдим итү, дип билгели. Киң катлау укучылар өчен чыгарылган бу белешмәлек 14 меңгә якын гарәп сүзенең хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсен тәкъдим итә.

Мондый төр сүзлекләр, сирәк булса да, эшләнә тора. Бу бер дә гаҗәп күренеш түгел. Мәгълүм булганча, меңел дәвамында гарәп язуын куллану, шәрык телләрен үзләштереп, ислам мәдәнияте белән якыннан танышу татар халкын динле, мәгърифәтле иткән, аның телен баеткан, халык арасында кульязма, соңрак басма китап таралуга зур этәргеч биргән.

Күпсанлы фәнни хезмәтләрдә тасвирланганча, гарәп, шулай ук фарсы телләренең татар теленә йогынтысы IX–X гасырларда ук башлана. Бер яктан, бу Идел Болгарының шәрык илләре белән сәүдә, сәясәт, мәдәният өлкәсендә тыгыз багланышлар урнаштыруы белән аңлатылса, икенче яктан, гарәпчәнең Идел болгарлары теленә көчле йогынты ясавын Болгарда ислам диненең өстенлек итә башлавы белән аңлатырга кирәк. XIII–XIV гасырларда ислам Алтын Урданың рәсми дине булып киткәч, гарәп язуы, гарәп теле аеруча киң таралыш ала. XVII–XIX гасырларга иске татар телендә гарәп алынмаларының саны меңнәр белән исәпләнә. Хәтта язма телдә гомумкулланыштагы шактый күп төрки-татар сүзләре гарәпчә эквивалентларына алмаштырылган була. Шул рәвешле бу күренешнең, уңай яклары белән беррәттән, телебезне элекке чорларда чамадан тыш алынмалар белән чуарлау, аны аңлауны кыенлаштыру кебек тискәре йогынтысы да күзәтелгән.

Билгеле булганча, бу бай мирас телебездән совет чорында читләштерелә, яңа тарих битләренә милли күтәрелеш чоры буларак кереп калган 1990 елларда исә кабат кайтарыла. Күп кенә очракларда гарәп чыгышлы сүзләр рус теле аша кергән европа алынмалары белән параллель кулланыла башлый (*редактор – мөхәррир, рәис – председатель, республика – җөмһүрият, суд – мәхкәмә*), кайберәүләренең кулланылышы стиль ягыннан аерымлана (*республика* – рәсми стильдә; *җөмһүрият* – матур әдәбият, публицистика, дини стильдә); шактый күләмдә сүзләр исә искереп төшеп кала, онытыла (*абыз* – укымышлы кеше; *әбәдән* – мәңгегә, беркайчан да; *баб* – сөйләшү өчен сүз, тема; *багбан* – бакчачы; *вафасыз* – тугрылыксыз һ.б.).

Гасырлар дәвамында гарәпчә сүзләрне дөрес аңлау, дөрес куллану максаты белән төрле сүзлекләр дә төзелә килә. Урта гасыр кульязма китапларның читләрендәге аңлашылмаган сүзләргә бирелгән шәрехләмәләрне (хашияләр), аларның тәрҗемәләрен киләчәктә төзеләчәк сүзлекләрнең беренче билгеләре дип санарга була. Берничә гасыр буена татарлар Мөслихетдин Мостафа бине Шәмсетдин әл-Карахисариның «Әхтәри кәбир» исемле гарәпчә-госманлыча сүзлегеннән файдаланалар. Ул хезмәт Казанда хәтта берничә мәртәбә басылып чыга.

Эшләнеп, үз вакытында басылмыйча, кульязма шәкелендә генә калган сүзлекләргә дә тукталып узу урынлы булыр. Шундыйларның берсе – 1886 елда К. Насыйри тарафыннан төзелгән «Мифтах әл-Коръән» сүзлеге. Бу сүзлек Коръәндә очраган

25 меңләп сүз һәм сүзтезмәләрнең Коръән текстындагы битләре күрсәтелгән конкордансы, ягъни исемлеге рәвешендә төзелгән. Автор аны 1861 елда Казанда нәшер ителгән Коръән басмасына нигезләнеп башкарган. Ни гаҗәп, гасырдан артык вакыт үткәннән соң гына әлеге хезмәт 2015 елда А.Г. Хәйретдинов, Р.Ф. Шәфигуллиннар тырышлыгы белән басмага әзерләнеп нәшер ителде.

XX гасыр башында исә гарәпчәдән саф татарчага тәрҗемә сүзлекләре дә нәшер ителә башлый. Аларның саны ике дистәләп исәпләнә. Шул рәвешле, татар лексикографиясе өлкәсендәге традицияләр эзлекле рәвештә ныгый барганнар, үстерелгәннәр. Укучыга тәкъдим ителә торган яңа сүзлек тә әнә шул фәнни һәм гамәли эзлеклелекне чагылдыра. Ул шактый бай материалны колачлый. Аны төзегәндә автор үзбәк, төрек, рус һәм иске татар телләренең төрле чорларда нәшер ителгән сүзлекләренә дә мөрәҗәгать иткән, аларның уңай тәҗрибәсен эшкә җиккән. Файдаланылган әдәбият исемлегендә моннан бер гасыр элек дөнья күргән сүзлекләр дә бар. Әйтик, Г. Барудиның «Лөгать сөляс» (1897), Т. Ильясиның «Әл-Мөфид. Гарәпчә-татарча мөкәммәл лөгать китабы. Беренче кисәк» (1912) һ.б. Үз вакытында бу белешмәлекләр төрки халыклар арасында да таралган була.

Соңрак басылган лексикографик хезмәтләр дә авторның игътибарыннан читтә калмый. Мәктәп яки югары уку йорты программалары кысаларында татар телен өйрәнгән кешеләр, аеруча, тел белгечләре, мөгаен, яхшы хәтерли булыр: 1965 һәм 1993 елларда К. Хәмзин, М. Мәхмүтов һәм Г. Сәйфуллиннарның «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» басылып чыккан иде. Сүзлек, XIII йөз шагыйре Кол Галидән башлап, хәзерге чор әдипләре әсәрләрендә, телнең төрле стильләренә караган текстларда, дәреслекләрдә, элекке вакытлы матбугат битләрендә кулланылган алынма лексиканы, шул исәптән әйтем һәм мәкаль шәкелендә булган һәртөрле гыйбарәләрне туплап тәкъдим итә. Мондый хезмәт татар халкының бай тарихын һәм мәдәни мирасын иске чыганаклардан өйрәнү, гомумән, телебезнең сүзлек хәзинәсен колачлап күз алдына китерү өчен инде ярты гасырдан артык бер дигән чыганак булып тора. Әлеге хезмәтнең уңай тәҗрибәсе яңа сүзлек төзелгәндә шулай ук исәпкә алынган.

Бүген гарәп теле татар халкы арасында үзенең элекке югары урынын саклап килә, киң күләмдә өйрәнелә дип әйтә алмыйбыз. Шулай да, гарәп теле күбрәк дин өлкәсендә, югары белем алу системасында, мәдрәсәләрдә кулланыла һәм өйрәнелә. Шуны күз уңында тотып, автор бу сүзлекне нәкъ дини текстларны – иң элек Коръәне Кәримне һәм хәдисләрне укыганда һәм тәрҗемә иткәндә куллану өчен белешмәлек итеп әзерләгән. Аңа бөтен гарәп сүзләрен кертү максат итеп куелмаган.

Сүзлекне төзү принципларына килгәндә, аңа нигез итеп, В.Ф. Гиргасның беренче мәртәбә 1881 елда Казанда, аннары кабат

2006 елда Санкт-Петербургта төзәтелеп, тулыландырып бастырылган «Арабско-русский словарь к Корану и хадисам» хезмәте алынган. Россиядә шәрыкне өйрәнү фәне кысаларында, аеруча мөселман җәмгыятьләренең рухи тормышын өйрәнүдә, әлеге сүзлекнең әһәмияте бәяләп бетергесез. Аны үз сүзлегенә нигез итеп сайлау автор Р.Т. Сәфәровның бу өлкәдән яхшы хәбәрдар булуын күрсәтә.

Күптәннән килә торган традициягә туры китереп, «Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек»тә баш сүзләр, тамырларына карап, алфавит тәртибендә урнаштырылган. Тамырдаш сүзләр сызык аша баш сүздән соң теркәлгән. Мәсәлән, كَتَبَ *у* [кәтәбә] ‘язарга’ фигыле мәкаләсенә караган сүзләрдән түбәндәгеләр китерелгән: كَاتِبٌ [кәәтибун] ‘язып баручы, язучы’, كِتَابٌ [китәәбун] ‘китап, язылган нәрсә, хат’; كَتِيبَةٌ [кәтиибәтун] ‘атлылар отряды’ (493 б.) һ.б.

Сүзләрне бу шәкелдә теркәү бер тамырдан ясалган лексик берәмлекләрне бер оя эчендә бирүне тәэмин итә һәм сүзнең мәгънәсен киңрәк итеп ачарга мөмкинлек бирә.

Мондый ысул фигыльнең билгеле бер шәкелдә ясалган бабларын, ягъни породаларын, формаларын күрсәтү өчен аеруча уңайлы. Мәсәлән: سَمِعَ *а* [сәми’а] <…> ишетү, тыңлау; <…> IV أَسْمَعَ [әсмә’а] ишеттерү; әйтү, хәбәр итү; V تَسَمَّعَ [тәсәммә’а] ишетү; тыңлау; яшеренеп тыңлап тору; <…> (279 б.).

Бер үк фигыльнең формалары, мәгълүм булганча, хәзерге яки үткән заманда унбишкә җитәргә мөмкин. Бер тамырдан булуга карамастан, аларның мәгънәләре, бабына карап, кайвакыт нык аерыла. Шуңа күрә мондый очракларны автор сүзлектә тәфсилләп аңлатуны мөһим дип тапкан.

Күп кенә очракларда баш сүз янында аның мәгънәсенә якын (синоним) яки капма-каршы мәгънәле (антоним) сүз китерелә. Мондый ысул сүзнең мәгънәсен тулырак, төгәлрәк ачу өчен отышлы. Мисал өчен: سَعَادَةٌ [сә’аадәтун] бәхет, сәгадәт, хозурлык, *ант.* شَقَاوَةٌ [шәкаавәтун] (268 б.); صَفْحٌ [сафхун] кичерү, гафу; <…> уң як, йөз; ян, янтык, *син.* جَانِبٌ [җәәнибун] (323 б.); كَبِيرٌ [кәбиирун] <…> олы, зур, дәү, *ант.* صَغِيرٌ [сәгыйрун] (492 б.) һ.б.

Сүзлек авторы Коръәндә, шулай ук башка дини әчтәлекле чыганакларда еш кулланылган кеше, кавем исемнәрен, географик атамаларны да терки. Андый исемнәр белән таныш булмаганда, аларның ялгызлык исемнәргә караганлыгын чамалау шактый кыен. Шунлыктан андый берәмлекләрнең биредә урын алуы, гәрчә мондый төр сүзлек өчен ул гадәти алым булмаса да, сүзлекнең мәгълүматлылыгын, кулланылу даирәсен киңәйтә торган тагын бер отышлы ягы дип әйтеп була: سَمْهَرُ [сәмһәру] Сәмһәр, *Хәбәшстандагы шәһәр исеме, шуннан сөңгеләр кайтарылган яки шуннан сөңге кайтаручы кешенең исеме* (280 б.); سِنْجَارُ [синҗәәру] Синҗар, *шәһәр* (281 б.) شَاذِى [шәәзи] Шази, *ир-ат исеме* (310 б.); الشَّامُ [әш-шәәму] Шам, Сурия (311 б.) һ.б.

Баш сүз (вокабула) буларак теркәлгән исем яки сыйфатның грамматик билгеләре, ягъни *мөзәккәр* формасы (мужской род) янына *мөәннәс* формасы (женский род), еш кына *икелек* һәм *ватык күплек* саны, җыйма предметларны белдергән исемнәрнең бер данәсе мәгънәсендәге формалары күрсәтелгән. Мисал өчен: دُرٌّ [дәррун] *күп.* دُرَرٌ [дүрүрун] *җый.* энҗе; *берс.* دُرَّةٌ [дүррәтун] энҗе бөртеге (187 б.); سَعِيدٌ [сә’иидун] *мнс.* ة *күп.* سُعَدَآءُ [су’дәәү] бәхетле, уңышлы, шат күңелле (268 б.); يَدٌ [йәдун] *ик.* يَدَانِ [йәдәәни] *күп.* أَيْدٍ [әйдин] *күп.* أَيَادٍ [әйәәдин] 1) кул; алгы аяк (*хайваннарда*) <…> (646 б.)

Шул ук вакытта, әлеге сүзлекне төзүгә бәйле аерым мәсьәләләрне хәл итүгә башкачарак якын килергә дә булыр иде. Әйтик, фигыльләрне татарчага *-ырга* инфинитив формасы белән тәрҗемә итү, безнең карашка, аларның гарәпчә фигыль һәм масдар, ягъни исем фигыль формаларын сүзлекнең татарча өлешендә төгәлрәк итеп тасвирлау өчен отышлырак булыр иде. Чагыштырыгыз: كَتَبَ *у* [кәтәбә], *масд.* كِتَابٌ [китәәбун], كِتَابَةٌ [китәәбәтун] *язу, язып кую*; كِتَابٌ *язу, китап, язылган нәрсә, хат*. Баш сүз буларак алынган гарәп фигылен *язарга, язып куярга* формасында биреп, масдарны һәм шул ук форма нигезендә ясалган исемне *язу* шәкелендә тәрҗемә итү кулланучы өчен уңайлырак булыр кебек.

Соңгы елларда чыккан татарчага тәрҗемә сүзлекләрнең абсолют күпчелегендә фигыль исем фигыль аша бирелә. Нәтиҗәдә, әйтик, рус. *плавать* ‘йөзәргә’ һәм *плавание* ‘йөзү’ сүзләре бер шәкелдә – *йөзү* сүзе белән генә бирелә. Безнеңчә, мондый алым телебезнең сүзлекләрдә чагылырга тиешле лексик байлыгын берникадәр чикләүгә китерә. Киләчәктә төзеләчәк татарчага тәрҗемә сүзлекләрдә фигыльнең инфинитив формасы аша бирелешен эзлекле нигездә гамәлгә кертергә кирәк.

Аерым очракларда гарәп сүзе бер-берсеннән шактый ерак торган мәгънәләрне белдерә. Сүзлектә аларны рәттән түгел, ә саннар белән аерып күрсәтү максатка ярашлырак булыр иде. Мисалга, قَافِلٌ [каафилюн] сүзе *сәфәрдән кайтучы; тиресе кипкән* (*ат*) дип тәрҗемә ителгән (480 б.). Күренеп торганча, мәкаләнең татарча өлешендә нокталы өтер аша бирелгән сүзләр төрле төшенчәләрне белдерә. Аларны, һичшиксез, аерырга кирәк.

مَجْنُونٌ [мәҗнүүн] сүзе *мәҗнүн, җенләнгән, акылсызлык, тилелек* (107 б.) дип тәрҗемә ителгән. Татарча тәрҗемәсе һәм сыйфат, һәм исемгә караганлыктан, укучы берникадәр югалып калырга да мөмкин. Тәрҗемәдә мондый очракларга тәфсиллерәк тукталу хәерлерәк булыр кебек.

Сүз мәкаләсе эчендәге иллюстратив мисалларны курсив белән яки башкача аеру уңышлы булыр иде. Шулай булмаганда, сүзнең мәгънәләрен аңлаткан текст белән мисалга китерелгән сүзтезмә яки җөмләләр кушылып китә кебек.

Гомумән алганда, сүзлек һәр ике телдән дә шактый бай лексик материалны эченә ала, теркәлгән

сүз, аның грамматик табигате, кулланылыш үзенчәлекләре хакында киң планда мәгълүмат бирә. Әлбәттә, сүзлекнең шактый уңышлы килеп чыгуына авторның ихластан тәкъвалы зат булуы, аның ислам дине нигезләрен яхшы күзаллавы да булышлык иткәндер. Сүзлектә мәгълүмат һәм гарәпчә, һәм татарча дөрес тупланып, лексикографик яктан тулы һәм төгәл тасвирланган. Билгеле, аның аерым кытыршы яклары алдагы хезмәтләрдә исәпкә алыныр дип ышанабыз. Алга таба эшләнәсе эшләр исемлегенең башында, безнеңчә, күп еллар дәвамында ил күләмендә, хәтта аннан читтә дә киң таралган хезмәт – Х.К. Барановның «Гарәпчә-русча сүзлеге»нең татарчасын төзеп, бастырып чыгару эше торырга тиештер.

Бу гамәлләрнең барысы да, бер яклап, халкыбызны саклау, аның мәдәниятен, телен, динен ныгыту һәм үстерүгә юнәлтелгән булса, икенче яклап, ил күләмендә үзара аңлашып, аралашып яшәү, тату һәм бәрәкәтле гомер кичерү юлында төпле нигез була ала дип ышанабыз.

***Тимерханов Айнур Әхәт улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире; Россия гадел хөкем университетының Казан филиалы профессоры*

**2018 елның 2–13 июлендә** Ульяновск өлкәсе Павловка, Николаевка, Чардаклы, Яңа Малыклы торак пунктларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы экспедиция үткәрелде. Экспедициянең фәнни-тикшеренү эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар халкының милли-мәдәни мирасы өйрәнелде, тел, фольклор, сәнгать, музыка, археографика, эпитафика, шулай ук традицион мәдәният буенча бай материал тупланды.

**2018 елның 14–15 июлендә** Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә Ә.Г. Кәримуллин укулары оештырылды. Халыкара фәнни-гамәли конференциягә Төркия, Беларусь, Литва, Казакъстаннан галимнәр чакырылган иде. Укуларда Литвадан фән докторлары Галина Мишкинене һәм Елена Забарскайте, Мәскәүдән тарихчы Илья Зайцев, Казакъстаннан Анаркул Рәхимова, Кырымнан Лиля Маметова, Төркиядән Ильяс Мифтахов һ.б. чыгыш ясады.

Чара кысаларында конференция кунаклары Әбрар Кәримуллинның каберен зиярәт кылдылар һәм туган ягы – Саба районы Чәбия-Чүрчи авыл мәдәният йортында үткәрелгән чарада катнаштылар.

**2018 елның 21 августыннан 2 сентябренә кадәр** Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгында V Халыкара археология мәктәбе эшләде. Агымдагы елда Халыкара археология мәктәбе эшчәнлеге дүрт юнәлеш буенча оештырылган иде: геоархеология; археологик текстиль – реставрация, консервация, реконструкция; кремний булмаган чималдан (сөяк, мөгез, таш, металл) эшләнгән борынгы эш коралларын эксперименталь-трасологик тикшерү; палеоантропология. Чарада 100 дә артык кеше, шул исәптән барлыгы уналты илдән – Мисыр, Һиндстан, Кытай, Швеция, Хорватия, АКШ, Төркия, Беларусь, Таҗикстан, Пакистаннан һ.б. илләрдән килгән 50 дән артык яшь галим катнашты.

Әлеге укулар «Ватан тарихы» фонды ярдәме белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исем. Археология институты һәм Казан федераль университеты тарафыннан оештырылды.

**2018 елның 4–7 сентябрендә Казанда «Цивилизацияләр диалогы» дип аталган форум үтте.** Әлеге чара Татарстан Республикасында төрле милләт вәкилләренең тату тормыш алып бару тәҗрибәсен күрсәтү, милли-мәдәни мирасны саклау юнәлешендәге эшчәнлек белән таныштыру максатыннан оештырылды. Форумның оештыру комитетына Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча Комиссиясе, «Яңарыш» фонды, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты һ.б. оешмалар керә.

Форум эшчәнлегендә милли мирасны саклау өлкәсендә эшләүче 200 дән артык эксперт, шул исәптән Болгар тарихи-археологик комплексын, Зөя утрау-шәһәрчегенең

Успение соборын һәм монастырен ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертүгә зур көч куйган галимнәр катнашты.

**2018 елның 5 сентябрендә** Зөя утрау-шәһәрчегендә «Татар бистәсе» археологик агач музее ачылды. Әлеге музейны төзү эше Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исем. археология институты һәм Казан федераль университеты галимнәре тарафыннан башкарылды.

Музейда XVI–XVII гасырларда төзелгән агач корылмалар урын алган, аларның иң борынгылары 1551 елда Зөя төзелеше белән бәйле. Музей фондында барлыгы 4700 гә якын экспонат тупланган.

**2018 елның 5–7 сентябрендә** Казакъстан Республикасының Уральск (Җаек) шәһәрендә Татар мәгарифе көннәре үткәрелде. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов җитәкчелегендәге делегация составына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты О.Р. Хисамов кертелгән иде.

Татарстан делегациясе М. Үтәмисов исем. Көнбатыш Казакъстан дәүләт университетында оештырылган мәдәниятләр диалогы һәм туган телне саклау мәсьәләләренә багышлангын фәнни-гамәли конференциядә катнашты.

Моннан тыш, татар мәгарифе көннәре кысасында Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте белән Ж. Досмухамедов исемендәге Көнбатыш Казакъстан педагогика көллияте, Казанның 2 нче лицей-интернаты һәм Уральск шәһәренең Назарбаев химаялегендәге Интеллектуаль физика-математика мәктәбе арасында хезмәттәшлек турында килешүләр төзелде.

**2018 елның 6–7 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясендә татар әдәбияты классигы, танылган публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан «Гаяз Исхакый һәм XX гасыр башында татар милли яңарышы» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли конференция узды.

Конференциядә катнашу өчен 100 дән артык фәнни доклад кабул ителгән иде. Конференция эшендә чит илләрдән (Төркия, АКШ, Азәрбайҗан) һәм Санкт-Петербург, Чебоксар, Казан, Яр Чаллы шәһәрләреннән галимнәр, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары, вакытлы матбугат вәкилләре, укытучылар, китапханәчеләр һ.б. катнашты.

Пленар утырышта Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» фонды (вакыфы) җитәкчесе Түләй Дуран (Төркия), Мәрмәрә университеты профессоры, фәннәр докторы Әхмәт Канлыдере (Төркия), Мимар Синан исемендәге Сәнгать университеты профессоры, фәннәр докторы Ильяс Кемалоглу (Төркия), Эгей университеты профессоры, фәннәр докторы Хатидже Ширин (Төркия), Висконсин университеты профессоры, фәннәр докторы Юлай Шамиль-оглы (АКШ), Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясе Низами исем. Әдәбият

институтының әйдәп баручы хезмәткәре, фәннәр кандидаты Хураман Гумматова һәм башкалар чыгыш ясады.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Г. Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан конференция материаллары җыентыгы, «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» текстологик җыентыгы (5 нче чыгарылыш), «Гаяз Исхаки фотографияләрдә» буклеты нәшер ителде.

**2018 елның 7 сентябрендә** Гаяз Исхакый исемендәге «Идел-Урал» фонды (вакыфы) җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакыйның Төркиядә сакланган шәхси документларының, көндәлекләренең асыл нөсхәләрен Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына тапшырды.

Гаяз Исхакый архивы язучының әдиплек, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә, шәхси тормышына мөнәсәбәтле документлар тупламыннан гыйбарәт. Биредә 312 саклау берәмлеге җыйналган, күләме 5000 биттән артык. Алар арасында Гаяз Исхакый әсәрләренең кульязмалары, аның 1919 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр алып барылган хатирә дәфтәрләре, эш кәгазьләре, төрле оешмаларга юлланган мөрәҗәгатьләре, хатлары, фотосурәтләре һ.б. бар. Аларның күпчелеге – Гаяз Исхакыйның үз кулы белән язылган, татар, төрек, инглиз, алман телләрендәге оригинал документлар. Шулай ук биредә Сәгадәт Чагатай тарафыннан язылган 32 көндәлек дәфтәрләре дә кыйммәтле мирас буларак урын алган.

**2018 елның 4–10 сентябрендә** Казан шәһәрендә XIV Казан Халыкара мөселман киносы фестивале узды. Фестиваль Татарстан Президенты Р.Н. Миңнеханов һәм «Россия-Ислам дөньясы» төркеме ярдәме белән оештырылды.

Форумда катнашу өчен 56 илдән 967 заявка теркәлгән. Бәйге программасы кысаларында 65 фильм күрсәтелде. Татарстан Республикасы фестивальдә 16 фильм белән катнашты.

**2018 елның 12 нче сентябрендә** Казан федераль университеты бинасында «Ночь в Императорском» дип исемләнгән фәнни-популяр проект гамәлгә ашырылды.

Мәшһүр рус классигы Лев Толстойга һәм аның иҗатына багышланган бу чарада Казан федераль университетының төрле институтлары һәм Лев Толстой исеме белән бәйле музейлар катнашты.

**2018 елның 13 сентябрендә** Санкт-Петербург шәһәрендә Татарстан Республикасы көне уңаеннан мәдәни чара узды. Бәйрәм тантанасында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев, Бөтендөнья татар конгрессының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге Тулы вәкаләтле вәкиле Ренат Вәлиуллин, Санкт-Петрбургта Миграцион сәясәтне тормышка ашыру һәм милләтара мөнәсәбәтләр комитеты рәисе Олег Махно, Ленинград өлкәсенең

җирле, милләтара мөнәсәбәтләр комитеты җитәкчесе Лира Булак, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин җитәкчелегендәге галимнәр, татар оешмалары җитәкчеләре, киң җәмәгатьчелек катнашты.

Татарстан Республикасы көне Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салу белән башланып китте. Программа кысаларында «Тукай энциклопедиясе», «Армия генералы Мәхмүт Гәрәев» китаплары тәкъдим ителде. Чара кысаларында Татарстан Республикасы һәм Санкт-Петербург сәнгать әһелләре катнашында концерт оештырылды.

**2018 елның 20–21 сентябрендә** Казанда күренекле татар галиме һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуга багышланган халыкара фәнни конференция уздырылды. Конференциянең төп оештыручысы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты.

Конференциядә катнашучыларның географиясен Азәрбайҗан, Болгария, Бөекбритания, Венгрия, Иордания, Казакъстан, Сербия, Сирия, АКШ, Төркия, Үзбәкстан, Япония һәм Россия кебек илләр тәшкил итте. Конференция программасы кысаларында пленар утырыш, дүрт тематик секция һәм түгәрәк өстәл үткәрелде.

Беренче секция төрки-татарларның урта гасыр тарихына багышланган иде, ул Мәрҗани хезмәтләрендә Алтын Урда тарихы һәм мәдәнияте, Җучи олысының һәм соңрак Казан ханлыгының хокук һәм дәүләтчелеге карашлары темаларын үз эченә алды. Икенче секциядә галимнәр күренекле мәгърифәтче галимнең дини мирасы турында фикер алышты. Өченче секциядә Ш. Мәрҗанинең педагогик эшчәнлеге һәм карашлары, туган телләрне укытуның заманча метод һәм алымнары турында докладлар яңгырады. Дүртенче секциядә Ш. Мәрҗани шәхесе һәм аның фикердәшләре турында сүз барды.

**2018 елның 12–14 сентябрендә** Казанда «Державин укулары» XIV Халыкара конференциясе үткәрелде. Чарада чит илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән фәннең төрле өлкәләрендә эшләүче галимнәр, иҗтимагый оешмалар һәм иҗади берләшмәләр вәкилләре, шулай ук аспирантлар һәм магистрлар катнашты.

Конференциянең пленар өлешендә барлык түгәрәк өстәлләрне берләштерүче тема буларак, яңа цифрлы икътисад мәсьәләренә мөнәсәбәтне билгеләү турында сүз барды. Түгәрәк өстәлләрдә филология, юриспруденция, медицина, мәгълүмат технологияләре һ.б. юнәлешләрдәге актуаль фәнни проблемаларны уртага салып сөйләшү үткәрелде. Чит илләрдән килгән катнашучыларның саны елдан-ел арта баруын исәпкә алып, конференция эше рус һәм инглиз телләрендә оештырылды.

Конференция ачылышы алдыннан кунаклар Г.Р. Державин һәйкәленә чәчәкләр салды. 14 сентябрьдә Лаеш районының Сакура авылы гомуми белем мәктәбенә тантаналы рәвештә Г.Р. Державин исеме бирелде.

**2018 елның 20–21 сентябрендә** «Җәлил укулары» Бөтенроссия конференциясе булып узды. Чара Муса Җәлил музей-фатирының ачылуына 35 ел һәм балалар язучысы Абдулла Алишның тууына 110 ел тулуга багышланган иде. Укуларның беренче көне Казанда герой-шагыйрь музей-фатиры базасында оештырылды. Анда танылган татар язучылары, журналистлар, фән эшлеклеләре, чит ил кунаклары һәм Абдулла Алишның туганнары катнашты.

«Җәлил укулары»ның икенче көне Татарстан Республикасының әдәби җәмәгатьчелеге вәкилләре, дәүләт, муниципаль һәм ведомство музейлары хезмәткәрләре, югары уку йортлары укытучылары һәм студентлар катнашында Яр Чаллы дәүләт педагогика университетында дәвам итте.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2018. № 3

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 24.09.2018. Басылды: 28.09.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ, К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла